# ОЛУГ МӨХӘММӘД

*Тарихи пьеса биш пәрдәдә*

Әсәрдәге исемнәр:

Олуг Мөхәммәд хан – Казанның беренче ханы, Казан ханлыгын коручы, урта яшьтә, зур гәүдәле.

Галибирде – ханның зур кияве һәм дә беренче илчесе.

Хөсәен бәк – ханның икенче илчесе.

Хуҗа Хәсән (голямадан) – өченче илчесе.

Василий Сабакин – урыс бояры, Мәскәү илчесе.

Андрей Галитаев – урыс бояры, Мәскәү илчесе.

Айтуган – урыслар арасында шымчылык иткән углан.

Василий – Мәскәүнең олуг кенәзе.

Сәед (голямадан) – пәйгамбәр әүлядыннан берсе.

Тимер командан – Олуг Мөхәммәднең гаскәренең башы.

Көнтуган – урыс гаскәре арасындагы хан шымчысы, углан.

Кечек Әхмәд хан – Алтын Урда ханы.

Гөлбикә – Олуг Мөхәммәднең хатыны, балалары анасы.

Мәхмүд, Ягъкуб, Йосыф, Касыйм – ханның угыллары.

Алмас солтан, Күңел солтан – Олуг Мөхәммәднең кызлары.

Хөршид солтан – Ягъкубның хатыны; киленнәре.

Түрәләр, гаскәрләр, хатыннар, балалар, урыслар, Казан халкы, чувашлар, чирмешләр.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

## БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Белёв шәһәрендә. Киң бер мәйдан. Кыш көне. Әтрафны[2] кардан, боздан өйгән диварлар сарган. Арка тарафта зур бер агач өйнең башында Алтын Урда байрагы* саллана. Уң тарафында тезелеп киткән өйләрнең морҗаларыннан төтеннәр чыга. Озактарак[3] киездән корылган берничә чатыр да бар. Сул тарафта бозлы диварның бер йирендә зур бер капка. Капканың ике тарафындагы боз диварларның өстендә агачтан ике чолан корылган, алардан мәйданга таба баскыч инә,[4] бу чоланнарда гаскәрләр[5] диварның тышындагы йирләрен җентеклиләр. Капка янында да гаскәрләр нәүбәттә[6] капканы саклыйлар. Мәйданда бик күп гаскәрләр, һәммәсе дә сугыш киемендә. Иярләнгән атлар да озакларда күренә. Сәхнәнең тирәләрендә гаскәрләрнең бер өлеше су ташый, икенчеләре кардан өелгән диварларга суны сибеп, диварны ныгытып маташа. Гаскәрләр бер-берсе берлә тавышсыз гына сөйләшәләр. Сәхнәдә пәрдә ачылганда мәйданда халык болыты... Зияраттагы кеби бер тынлык.

Еpактан гына урысча кычкырышу, көлү, җырлау тавышлары ишетелә. Бу – урыс гаскәре кәеф-сафа чигә, эчә, исерә. Пәрдә ачылгач, сәхнә бераз тын тора.

Капка өстендәге каравылчы (*баскычтан инеп, сакчы гаскәрләр башлыгына сәлам бирә дә*). Илчеләребез урыслардан кайтырга чыктылар, яннарында ике урыс бояры да бар, киләләр.

Йөз башы. Урыныңны тот!

Каравылчы баскычтан чоланга таба чыга. Йөз башы чаба-чаба байраклы өйгә китә. Сәхнәдәге гаскәрләр арасында пыш-пыш сөйләшүләр, хәрәкәтләр. Тынлык. Зур өйдән өч-дүрт зур дәрәҗәле түрәләр чыгалар, капкага таба киләләр, алар берлә бергә йөз башы да. Болар килүгә гаскәрләр сәлам торалар.[7] Тынлык.

Зур түрә. Илчеләр капкага килеп җитүләре берлә көттермәенчә капканы ачыңыз!

Сакчылар янына гаскәрләр капкага таба киләләр.

Йөз башы *(гаскәрләргә).* Йиреңездә торыңыз. Дош-ман илчеләре килә, ирлегеңезне саклаңыз, куркак-лык күрсәтмәңез!

Югарыдагы каравылчы. Якынлаштылар!

Й ө з  б а ш ы. Килеп җиткәч кенә хәбәр бир, вакытыннан әүвәл сөйләмә! *(Капучыга.)*[8] Вакытыннан әүвәл капканы ачма! *(Югарыга.)* Урыс гаскәре капкага таба якынлашмыймы?

К а р а в ы л ч ы. Илчеләрне ун урыс гаскәре озата килә, башкалары йирле йирендә.

И к е н ч е  к а р а в ы л ч ы. Урыс гаскәре анда бәйрәм итә, әллә никадәресе инде исерек, ава-түнә йөри, аларның бездә эшләре юк.

Б е р е н ч е  к а р а в ы л ч ы. Килделәр!

К и л ү ч е л ә р (*тыштан капканы кагалар*). Без килдек. Без хан хәзрәтләренең илчеләре, урыс кенәзенең дә илче боярлары бергә. Капканы ачыңыз.

Б е р е н ч е  к а р а в ы л ч ы (*капучыга*). Капканы ач, гаскәрләргә сәлам тор.

Капка ачыла. Аннан өч  х а н  и л ч е с е,  и к е  у р ы с  б о я р ы  керәләр, гаскәрләр сәлам тора.

К а р ш ы  а л у ч ы  т ү р ә л ә р. Хуш килдеңез, хуш!

Урыслар башларын алалар.[9] Урыс гаскәре дә капкадан керергә тели, аларны этеп-төртеп чыгаралар.

Й ө з  б а ш ы. Беркемне кертмә, яп капканы!

Капканы ябалар. Илчеләр каршы алучылар берлә акрын гына сөйләшә-сөйләшә байраклы өйгә таба китәләр. Башка өйләрдән чыккан ирләр, хатыннар боларны карап торалар.

Й ө з  б а ш ы *(гаскәрләргә).* Ирекле!

Гаскәрләр сәлам торуны бетерәләр. Тынлык. Йөз башы баскычтан сакчы чоланына чыга.

Й ө з  б а ш ы *(әтрафына каранып).* Урыс гаскәре дә дөньяны тоткан. Урыс кенәзе кайдан бу кадәр гаскәр җыеп өлгергән?

Т ү б ә н д ә г е  б е р  у г л а н. Алла кушмаган эш булмас. Безнең бабайлар мондый гына урыс гаскәрен бозганнармы? Көл итәрмез!

И к е н ч е  б е р с е. Сөякләрен санармыз!

Ө ч е н ч е с е. Тешләрен суырырмыз!

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бүрәнәле диварлы зур бер өйнең зур бүлмәсе. Идәнгә паласлар җәелгән. Түрдә мендәргә Олуг Мөхәммәд хан утырган. Түбәнрәк ике яклап өчәр-дүртәр зур түрәләр йирләшкәннәр. Ишекнең ике ягында ике углан ялан кылыч нәүбәт саклыйлар.[10] Ханга якынрак йирдә яшел чалмалы Сәед утырган. Сәхнә ачылганда тынлык. Олуг Мөхәммәд башын кулына таяндырган. Өй эчендә тынлык. Ишектән илчеләр урыс боярлары берлә бергә керәләр. Боярларның берсенең исеме Василий Сабакин, икенчесенең Андрей Галитаев.

Илче башы. Әссәламегаләйкем!

Түрәләрнең кайберләре *(аякка калкып).* Вәгаләйкемәссәлам!

Илчеләр ханны олуглап иеләләр. Урыслар да башларын чыгарып иелеп сәламлиләр.

Олуг Мөхәммәд. Хуш килдеңез, яхшы хәбәрләр китергәнсез, иншалла.

*(Боярларга.)* Утырыңыз.

Урыслар тез чүгеп түбәнгә утыралар. Илчеләр – аякта. Олуг илче – Галибирде (ханның кияве), икенчесе – Хөсәен бәк, өченчесе – язучы Хәсән Хуҗа.

Беренче илче Галибирде. Олуг падишаһым, өстемезгә йөкләнгән дәүләт эшене Тәңренең ярдәме берлә тотырга тырыштык. Урыс кенәзе Василийның баш команданнары Димитрий Шемяканы, Димитрий Юрь-евичларны күрдек. Падишаһымызның сезгә сүзе шулдыр: «Мин үзем олуг угылым Мәхмүдне, янымдагы бәкләрем дә үзләренең угылларыны сезгә тотык (рәһен) итеп калдырамыз. Тәңре яңыдан мине падишаһ итеп таҗ-тәхетемне кайтарса, урыс йирене дошманнардан сакларга, үз гаскәрем берлә урыс иленә баскынлык итмәскә, яу җибәрмәскә сүз бирәм. Үз эшемезне эшләр өчен безне тыныч калдырсыннар, диде», – дидек.

Хәсән Хуҗа. Падишаһымыз хәзрәтләренең Мәскәү кенәзе Василийга иткән изгелекләрен дә сөйләдек. Алланың язмышы берлә иленнән аерылган, таҗ-тәхетеннән җөда булган[11] олуг падишаһымызга каршы эшләргә теләгән эшләр һәрбер дин каравыннан зур гөнаһтыр, хыянәттер, дидек, сүземезне тыңлата алмадык, падишаһым! Безнең сүзләремезгә көлеп, мыскыл итеп

җавап бирделәр. Сезнең хозурыңызда авызга алынмаячак сүзләр берлә аталарымыз, бабаларымызны сүктеләр. Озын сөйләшүдән соң, актык сүзләрене сөйләргә дип, менә шул боярларын *(урыс боярларына күрсәтә)* күндерделәр. Безнең кимчелекләремезне кичер, солтаным!

Олуг Мөхәммәд *(урыс боярларына).* Бояр Василий Сабакин, бояр Андрей Галитаев, сез ни хәбәр китердеңез?

Василий Сабакин *(ханга башын иеп).* Безнең урыс йорты сезнең татар яуларыннан бик зур авырлык-лар чикте, шәһәрләремез таланды, малымыз-туарымыз алынып, илеңезгә озатылды, ирләремез, хатыннарымыз әсир ителде. Хәзер, шул яучыларның башы кулымызга төшкәч, без ничек аның теләген тутырыйк, аңа йортымыз-да яшәргә ирек бирик?

Олуг Мөхәммәд. Сугыш эчендә булынган ике ил арасында һәрвакыт мондый эшләр була килгән. Моны без генә дөньяга чыгармадык, адәм баласы яши башлаганнан бирле бу эш шулай килә. Безнең татар иленә урысларның итдеке зыян-зарары азмы? Сезнең яуларыгыз Югары Иделдәге сату-алу көймәләремезне суймадылармы, суймыйлармы? Безнең хатыннарымыз-кызларымызны алып китеп монастырьларга китермәделәрме? Болар һәммәсе дә үткәндәге эшләр. Без – ике якымыз да шуларны онытып, ике күрше ил булып, бер-беремезгә яу җибәрмәенчә тынычлыкта яши алмыймызмы? Минем теләгем менә шул!

Андрей Галитаев. Безнең урыс халкына татарлар ул кадәр күп авырлыклар ясадылар ки, без аны оныта алмыйбыз, вакыты – форсаты килгәндә үч алудан үз-үземезне тыя алмыймыз. Сезгә илемездә яшәргә ирек бирә алмыймыз!

Олуг Мөхәммәд. Без, татарлар, сезгә һичбер яхшылык эшләмәдекме? Безнең бабаларымыз бу туп-ракларга аяк басканда сезнең һәрбер шәһәреңездә бер кенәзегез икенче шәһәрдәге кенәзегез берлә туктамаенча сугыш эчендә идеңез. Нә шәһәрләреңездә, нә авылларыңызда тынычлык бар иде. Шәһәрләр арасында нә юлыңыз, сулар өстендә нә күпереңез, нә кичүләреңез бар иде. Чит ил сәүдәгәрләре генә түгел, күрше шәһәр

кәрваннары талаудан курыкмаенча бер-берсенә мал китерә алмыйлар иде. Бабаларымыз бөтен урыс илендә тынычлык кордылар, бөтен илеңездә юллар, күперләр салдылар, юлбасарларны юк иттеләр, чит ил сәүдәгәрләре тыныч килеп китәрлек, кәрван йөрерлек хәл тудырдылар. Үзара сугышып ята торган кенәзләреңезне юлга без салдык, Мәскәү кенәзен без олуг кенәз ясадык, башка кенәзләргә Мәскәү кенәзенә муен иярга без боердык. Василийга Мәскәү олуг кенәзлеге ярлыгын мин бирдем. Минем ярдәмем берлә ул хәзерге куәткә килә алды. Һәрбер монастырьда аерым-аерым попларыңыз аерым гыйбадәт ысуллары өйрәтәләр, кырык төрле мәзһәб[12] тараталар иде. Безнең мөселман бабаларымыз, Аллага хөрмәт йөзеннән, Алла һәммәбез өчен олугтыр, бу дин башбаштаклыгын сезгә – урысларга зарарлы таптылар, бер побыңызны олуг поп-патриарх ясадык. Бөтен попларыңызга аңарга буен сынарга без куштык, патриархыңызга кенәзләр хөрмәтен без бирдек, чиркәүләреңезне, монастырьларыңызны, поп-ларыңызны, бөтен дин әһелләреңезне биргедән,[13] салымнан, олау чабудан азат итеп, без ярлыклар чыгардык, бер кенәз байрагы астына бөтен таркау, бер-берсенә дошман илләреңезне без тупладык, бер дин башлыгы янына бөтен аеры-аеры мәзһәбләреңезне без җыйнадык. Олуг, кечек арасындагы гадәләтсезлекне[14] мәхкәмәләремез берлә без бетердек. Илеңезне башбаштаклыктан чыгарып, дәүләт хәленә без китердек. Хәзер шул хезмәтләремезгә каршыдан кара гайбәт берлә авыр хәлгә төшкән ханыңыз вә аның якыннарына каршы кылырга телә гән эшләреңезне христианлыкның да Алласы начар, яман эш дип каршыламавына вә сезне җәзалаттырмавына ышанасызмы? Без – Тәңренең гаделлегенә ышанган мөселманнар – бу начарлыкларыңызның җәзасыз кичүенә инанмыймыз вә сезне дә Алланың җәза-бәласеннән коткарыр өчен арада тынычлык, дустлык ясауга өндимез.

Андрей Галитаев (*сикереп тора, ачулы тавыш берлә*). Без монда вәгазь-нәсыйхәт тыңларга килмәдек. Безнең урыс торагында татар ханлыгын яшәтергә ризалыгымыз юк. *(Байракны күрсәтеп.)* Бу байракны индереп, урыс байрагын күтәреп, безнең хөкемнәремезгә разый булыңыз, безгә

биреленеӊез. Югыйсә килеп һәрнәрсәӊезне тар-мар итәчәкмез, байрагыӊызны без индерәчәкмез, индереӊез байрагыӊызны!

Ишектәге ялан кылычлы углан алга атыла.

Олуг Мөхәммәд *(кулы берлә ишарә итә).* Син урыныӊда тор! Илчегә үлем юк, бояр үз исеменнән сөйләми. *(Боярга карый.)*

Андрей. Команданнарым исеменнән, урыс олуг кенәзе Василий исеменнән сөйлим!

Олуг Мөхәммәд *(баш өстендәге байракка күрсәтеп).* Бу байрак безнеӊ олуг бабамыз Чыӊгыз ханныӊ илемезгә багышлаган мөкатдәс байрагыдыр. Бу байракны без индерә алмыймыз, индермәячәкмез, бу илләрдә бу байрак мәӊгелек салланачактыр. Тәӊредән башка аны индерәчәк куәт юктыр, без үләрмез, без бетәрмез, байрак инмәс!

Бояр Сабакин. Хан хәзрәтләре! Без олугларымыз-дан алган бурычымызны үтәдек. Безне кичереӊез. Без ни кушсалар, шуны аӊлаттык.

Олуг Мөхәммәд. Сезгә бер сүзем юк. Команданнарыӊызга монда ишеткәннәреӊезне сөйләӊез. Минем соӊ сүзем: без сезнеӊ урыс илендә йирләшү уенда түгелмез, ялгыз[15] кышны монда үткәрергә теләдек. Тәӊре кушса, мал-туарга җим чыгу берлә татар иленә китәчәкмез. Тагы бер мәртәбә сөйлим: шул вакытка кадәр безне тыныч калдырсыннар. Әгәр инде сүзне тыӊламыйлар икән *(кылычы берлә йиргә сугып),* бу кылыч әле тутыкмаган, бу егетләр, бу угланнар әле үлмәгән, боерсыннар!

Хәсән Хуҗа. Тәӊре олугтыр.

Боярлар аякка калкалар. Чыгалар. Тынлык. Озын бер тынлыктан соӊ.

Олуг Мөхәммәд *(илчеләргә).* Дошман тупрагында ниләр күрдеӊез?

Галибирде. Мәскәүнеӊ гаскәре күп. Безгә башкалар берлә көрешергә рөхсәт бирмәделәр. Гаскәрләре утыз-кырык меӊнән ким түгел. Күбесе җәяүле, әмма атлылары да бар. Без кайтканда юлымызныӊ өстенә ике кеше асканнар иде, боларга «Татар шымчылары» дип язылган, берсен безнекеләрдән икәнен таныдым, берсе урыска охшый иде.

Бер түрә. Асылган егет озын буйлымы, кыскамы?

Г а л и б и р д е. Озын буйлы.

Т ү р ә. Айтуган углан, күрәсең.

Х у җ а  Х ә с ә н. Иле өчен шәһид китте, урыны оҗмахтадыр.

Х ө с ә е н. Безнең хезмәттәге боярлардан берсе китәр алдында, күрешеп, кулыма бер кәгазь сукты,[16] укый алыр-лык вакыт булмады. *(Чыгарып куя.)*

Х а н. Укыңыз!

Х ө с ә е н *(укый).* «Урыс гаскәре кырык мең кешедер, алты меңе атлы. Василий, ханның йә тересен, йә үлесен китереңез, дип фәрман биргән. Патриарх урыс гаскәренә вәгазь-нәсыйхәт өчен, аларны мөселманнарга каршы кыз-дырыр өчен илле поп вә монах күндергән, алар гаскәр эчендә, урыс гаскәренең күбесе сугыш күрмәгән авыл мужигы». Бетте. *(Тынлык.)*

О л у г  М ө х ә м м ә д. Бәкләр, сәедләр, түрәләр! Хәлне аңладыңыз, инде ни мәслихәт итәсез? Һәммәңез уеңызны ачык сөйләңез!

С ә е д *(яшел чалмадан).* Хан хәзрәтләре! Дәүләт эшләре Тәңренең язмышы берлә сезнең өстеңезгә йөкләнелгән, без сезнең ярдәмчеләреңез генәмез, сез ни әмер итсәңез, ул булыр. Без мөселманнармыз, Җәнабе Хак Коръән Кәримдә «Әтыйгуллаһе вә этыйгуррәсүл вә әлвалами минкем» дия хитаб[17] итмеш, ягъни Аллаһ вә аның пәйгамбәренә, үз динеңездән булган падишаһларыңызга, олугларыңызга вә түрәләреңезгә буен сыныңыз, дигән сүздер. Без Тәңренең бу әмеренә буен сынамыз. Әмереңезне көтәмез. Каршымызда кара йөрәк – урыс, дин дошманы, ил дошманы, дәүләтемез, байрагымызның дошманы. Илемезнең, ханымызның хөрмәтен саклау һәммәмезгә фарыз. Моны саклар өчен ялгыз бер куәтемез калды – кылычымыз. Сугыштан башка чара юк. Алла ярдәм бирсә, җиңсәк – илемезне коткарамыз, тарихымыз-ны җанландыра[мыз], халкымызны хөрмәтләндерәмез, җиңелсәк – шәһид китәчәкмез! *(Тына.)*

Б е р е н ч е  т ү р ә. Хан хәзрәтләре, башыңызга бер каза килсә, дәүләтемезнең хәле ни булачак? Мине шул эшләр шөбһәгә төшерә.

И к е н ч е  т ү р ә. Тагы бер илче күндерсәк ничек булыр, хан хәзрәтләре?

Олуг Мөхәммәд. Мин Олуг Чыңгызның угылымын. Мин теләнче түгелмен.

Тимер командан. Падишаһым, без хәзер дошманның гаскәре берлә дүрт ягымыздан сарылганмыз. Кан түкмәенчә, моннан котылып чыгарга һич өмет юк. Алдымызга куелган эш тә Чыңгыз баласы бөек ханымыз берлә аның янындагы биш мең кешене генә коткару түгел, бабаларымызның безгә калдырган мирасы – Чыңгыз дәүләтенең калдыгыны саклаудыр. Бу бурычыбызны үти алмасак, моннан туган эш тә илемезне дошман чабатасы астында таптатудыр, издерүдер. Безнең кечкенә башымызга язмыш шундый зур, авыр йөк йөкләде, моннан качына алмыймыз. Канымыз, җанымыз берлә дәүләтемезне, ханымызны, илемезне, халкымызны сакларга тиешмез. Аналарымыз безне мондый авыр көннәр өчен тудырды, аталарымыз, бабаларымыз шундый авыр көннәрдә эшкә ярасыннар дип безне җитештерде, бар куәтемез берлә дошманга салдырудан[18] башка юл юк, янымыз-дагы бөтен гаскәрләр дә бу уйда, әмереңезне көтәмез, падишаһым!

Тыштан бер тавыш. Эшем ашыгыч, көтәргә вакы-тым юк. Көнтуган йөз башы килде, диегез!

Ишектән бер забит[19] керә, сәлам биреп.

Падишаһым, йөз башы Көнтуган исемендә бер забит хозурга кабулыңызны үтенә, ашыгыч сүзем бар ди, хан хәзрәтләре!

Олуг Мөхәммәд. Керсен!

Һәркем ишеккә карый, ишектән урыс кыяфәтендә бер кеше керә. Бик бөгелеп сәлам бирә дә көтә.

Хан. Ни бар, угылым? Ашыгыч хәбәрем бар, дигәнсең!

Йөз башы. Олуг хан хәзрәтләре! Баш команданның боерыгы берлә урыс гаскәре эчендә киткән идем. Күземне дүрт ачып ике көн араларында калдым, күргән-белгәннәремне сезләргә белдерү бурычым дип, урыс гаскәрендә үзгәрешләр булуны күргәч тә ашыга-ашыга кайттым, шуның өчен сезне, хан хәзрәтләре, вакытсыз борчыдым, мине кичереңез!

О л у г  М ө х ә м м ә д. Сөйлә, угылым, сөйлә! Ни күрдең, ни үгрәндең, шуны аңлат!

К ө н т у г а н. Иң соңыннан башлыйм. Илчеләр моннан кайту берлә, бүген кич каламызны басу боерыгы чыкты. Урыс гаскәре төрле яктан баскынга хәзерләнә, шуны күреп мин дә ашыктым. Бүген кич баскын булачак.

Х а н. Урысларның кайсы яклардан баскын хәзерләүләрен, кай тарафтан зур көчләрен куячакларын үгрәндеңме?

Й ө з  б а ш ы  К ө н т у г а н. Моны ачык үгрәнергә ва-кы-тым булмады, хан хәзрәтләре! Боларны үгрәнеп, минем анда калган иптәшем караңгылык төшәр-төшмәс хәбәр китерәчәк, гаскәрнең хәзергә йирләшүе менә шул рәвештә.

Ханның алдына язулы-хариталы[20] бер кәгазь куя. Хан кәгазьне дикъкать берлә карый, аннары баш команданга бирә. Озын гына тынлык.

Х а н. Тагын ниләр белдең?

Й ө з  б а ш ы. Поплар урыс гаскәрен безгә каршы бик кыздыралар, дошманлыкны уятырга бик тырышалар. Төрле-төрле буяуларда бик күп тәреләр китергәннәр, тәреләрдән шәфәгать теләүче гаскәр бик күп. Урыс гас-кәренең башлыкларының күбесе исерек. Һәрбер йирдә аракы мәҗлесләре. Бертуктамаенча эчәләр, үзара берсе «мин – москвалы, син – псковлы» дип кычкырышалар. Талашлар да бик күп. Гаскәр үзе бик күп, утыз меңнән ким түгел, бәлки кырык мең дә бар. Кораллары иске. Гаскәрнең күбесе сугыш күрмәгән, атлары өйрәтелмәгән. Урыс башлыкларына Алтын Урдадан Кечек Мөхәммәд хаты – хан хәзрәтләрен тотып бирү хакында ярлык килгән, Мәскәү кенәзе шул ярлыкны тотар өчен сугыш ача, дигән хәбәрләр тараталар. *(Йөз башы сүзен бетерә. Бераз тынлык.)*

О л у г  М ө х ә м м ә д. Рәхмәт, угылым! Башыңны, җаныңны юк итүдән курыкмаенча дәүләткә, эшкә, безгә зур хезмәтләр иттең. Синең бу ярарлыгың онытылмас.

Й ө з  б а ш ы. Падишаһыма каршы, илемә каршы бурычымны үтәдем, хан хәзрәтләре!

Олуг Мөхәммәд. Рәхмәт, рәхмәт! Башка белгәннәрең булса, үзеңнең шул сугыш хакында уйларың булса, командannarың берлә күреш тә аңлат.

Йөз башы сәлам биреп чыга. Тынлык.

Хан. Моннан соң ни дисез?

Бер түрә. Хан хәзрәтләре, капкынга төшкән бүре кебек, урыс явының килеп үтерүен көтеп тормаенча, иң элек безнең салдыруымыз тиештер, Тәңре ярдәм итсә, мөселман гаскәре җиңәчәктер, командannarга сугыш планын хәзерләргә әмер биреңез, падишаһым!

Хан *(башкаларга карый).* Шулаймы?

Һәммәсе. Шуннан башка юл юк, шулай, хан хәзрәтләре, шулай!

Хан. Командannarның планнары күптән хәзер. Тәңре ярдәмчемез булсын! Минем уемча да шуннан башка юл калмады, һәммәңез шул үлем-калым сугышына хәзерләнеңез!

Һәммәсе аякка калка, сәлам биреп чыгалар. Тынлык.

Бүген Чыңгыз дәүләтенең шобагасы салына, ул йә бетәчәк, йә әүвәлгесе кебек олуг ханлык булачак. Башым китсә китсен, Чыңгызның мирасы – илемез сау калсын! Йауас, йауас!

Хатыннар тарафыннан Гөлбикә – ханның хатыны чыга.

Гөлбикә. Мин һәр сүзләреңезне тыңладым. Сугыш-тан башка юл юк. Урыс кулында бер без түгел, безнең кебекләр меңнәр, меңнәр бикәләр, кызларымыз мәсхәрә булганчы, шул карлар астында тәннәремез чересен, намусымыз югалганчы, җанымыз чыксын. Тәңре ярдәм бирсен, солтаным!

Хан. Киемнәремне, коралларымны китереңез!

Хезмәтче хатын киемнәр китерә. Хан киенә.

Гөлбикә *(ханның муенына бөти кигезә).* Бу мөбарәк бөти бабаларың хан хәзрәтләреннән калган. Моны кигән башны кылыч кисмәс, моны ташыган[21] тәнгә ук үтмәс. Тәңрегә әманәт, солтаным! *(Күз яшьләрен сөртә.)*

Хан *(киенеп бетеп).* Балалар кайда?

Гөлбикә. Бар да өйдә. Балалар! Балалар, килеңез, әтиеңез чакыра!

Ханзадәләрдән Мәхмүд, Йосыф, Касыйм, Ягъкуб, кызлардан Алмас солтан, Күнел солтан керәләр. Ирләр гаскәри киемдә.

Хан. Утырыгыз, балалар! *(Хан да, ханбикә дә утыра.)* Һәммәгез үз эченнән «Аятелкөрси» укыгыз!

Үзе дә укый. Озын гына тынлык. Бераздан хан кулын догага күтәрә, аның артыннан бөтен хазыйрләр[22] кулларын күтәрәләр.

*(Кычкырып).* Олуг Тәңре! Илемез, көнемезне, дәүләтемез, сөяләремезне,[23] халкымызны, бала-чагамызны, байрагымыз, гаскәрләремезне, мал-туарларымызны афәт-бәлаләрдән сакла! Ил, дин дошманнарының күзләрен сукыр, кулларын чулак, аякларын аксак, йөрәкләрен куркак ит, команданнарыма тугры курс, гаскәрләремә батырлык, халкыма сабырлык бир, үземне, үз янымдагыларны тугры юлдан яздырма! Амин!

Һәммәсе. Амин.

Һәммәсе йөзләрен сөртәләр. Хан аякка калка, башкалар да аякка басалар.

Хан. Мәхмүд, син уң кулга баш булачаксың! Касыйм, Ягъкуб, сез Тимер команданның кул астында булачаксыгыз! Йосыф, син каланың башы булып калачаксың! Анаң, туталарың, сеңелләрең, мондагы бөтен бикәләр, туташлар, хатын-кызларның җанын, намусын син саклая-чаксың! *(Хатыннарга.)* Һәммәгез аның әмеренә баш иегез. Без дошман берлә үлемме-калумы сугышына атыламыз. Тәңренең ярдәме берлә җиңсәк, сау калсак, тагы күрешермез, язмышның язуы берлә үлсәк, хакларыбызны бәхил итегез.

Хатыннар еглый.

Олуг абыегыз Мәхмүдне өйнең башы, Чыңгыз байрагының сакчысы, олуг ханлыкның варисы дип әйтеп таныгыз, аңа буен сыныгыз!

Гөлбикә. Аллага әманәт, солтаным. Тәңре кушса, сау-сәламәт дошман явын җиңеп кайтырсың! *(Күзеннән яшен сөртә.)*

Хан һәммәсе берлә кочаклашып күрешә. Кызлар еглыйлар. Хан акрын гына ишеккә таба атлый, аның артыннан ханбикә, угыллары, кызлары. Ишек ачыла. Тышта хәзер юл йөреше чалына.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Киң мәйданны ап-ак кар каплаган. Саф-саф тезелгән гаскәрләр, ат өстендә команданнар, забитлар хан өенең ишеге төбенә дәрәҗә-дәрәҗә тезелгәннәр. Ханны күрү берлә команданнар, гаскәрләр сәлам торалар. Хан баскан йиреннән гаскәрләрне сөзә.[24] Ике углан ханның иярле атын тотканнар, хан атка атлана, аның артыннан команданнар атланалар. Ике якка аерылган юлдан хан вә команданнар гаскәрләрнең алдына чыгалар. Ханбикә, балалары һәммәсе ишек төбендә, башка өйләрдән дә хатыннар, балалар ишек төбенә чыкканнар. Хан атын гаскәргә каршы бора, аның артында команданнар да шулай итәләр.

Хан. Төмән[25] башлары, мең башлары, йөз башлары, ун башлары, угланнар, гаскәрләр! Хәлемезне күрәсез. Без барымыз да – олугымыз, кечекемез, иремез, хатынымыз, балаларымыз-чагаларымыз – капкынга төшкән бүре кебекмез, бөтен ягымыздан яу сарган, безне юк итәргә, безне үтереп бетерергә әмер бирелгән. Хатыннарымыз, кызларымызны урысларга кәнизәк итәчәкләр, исән калган ирләремезне урыска кол итәчәкләр, илемез-йортымыз-ны юк итәчәкләр, Чыңгызның безгә мәңгелек дип биргән изге күк байрагымызны – бөтен кыпчак илләрен бергә туплаган байрагымызны ертып ыргытачаклар, бөтен халкымызны илсез, эшсез итеп, җил кебек таратачаклар. Бу капкыннан корбансыз котылырга юлымыз юк, өметемез Тәңренең ярдәмендә генә вә бабаларымыздан мирас калган шул кылычымызда.

Кылычын кыныннан чыгара, бөтен команданнар да чыгаралар.

Бу илләрне алган бабаларымызның батыр каны безнең тамырларымызда әле суынмаган. Тәңренең тугрылыгына, гаделлегенә ышанычымыз кимемәгән. Бүген без бу кылычка мал табар өчен, ил ачар өчен сарылмыймыз, илемезне, халкымызны, динемезне дошманнан саклар өчен сарыламыз, аналарымызның имиендәге сөтләр хәләл булсын өчен, аналарымыз, апаларымыз, сеңелләремез, кызларамыз, хатыннарымызны урыска мәсхәрә булудан коткарыр өчен сарыламыз. Хаклык бездә, тугрылык бездә, сүз тоту бездә.

Тәңрегә, пәйгамбәргә инану бездә. Тәңре безнең берлә, без бу дошманны җиңәчәкмез, илемезне, үземезне азатлыкка кавыштырачакмыз. Команданнарыңыз әмерене тотыңыз. Тәңренең исеме берлә алга, гаскәрләрем, алга, арысланнарым!

Зур капка ачыла, яшен ташы [кебек] атлы гаскәр капкадан чыга. Мәйдан буш кала... Хатыннар, балалар мәйданга чыгалар.

Бер карчык. Тәңре ярдәмчеңез булсын!

Хатыннар. Тәңре ярдәмчеңез булсын!

Ат аягы тавышы астында тынлык күп кенә. Йосыф янындагы карт-коры берлә капка янында.

Берничә хатын *(өйләреннән күрәндәләр күтәреп капкага якынлашалар. Йосыфка).* Сугыш мәйданында арып, әлсерәп калган батырларымызга берәр кәнди кайнар шурпа, кайнар сөт эчерермез дип уйладык, рөхсәт бармы?

Йосыф. Сугыш бик каты барачак, урыслар куа башласа нишләрсез?

Бер хатын. Нишләрмез, ни язмыш булса, шуны эшләрмез. Беренче сугыш күрмимез.

Бер бикә. Тугры, тугры, барыңыз. Алла юлыңызны җиңел кылсын!

Аларга «мин дә барам, мин дә барам» дип, хатыннар кушылалар.

Берничә бикә *(киндерләр, ак бәзләр күтәреп киләләр. Йосыфка).* Без яралыларны сарырмыз, яраларын юармыз дип барамыз, рөхсәтме?

Йосыф. Рөхсәт, рөхсәт! *(Якындагыларга.)* Хатыннарга кадәр һәммәсе сугышка катыша, мин монда буш йөрим, шундый зур көнне сугыштан калган кебек булу хурлык түгелме?

Бер карт бикә. Атаң хан хәзрәтләренең сүзене тыңлау, анаң ханбикәмезне саклау хурлык буладыр диме? Монда урыслар салдырса, безне кем саклаячак, син түгелме?

Йосыф. Анысы тугры, әмма шундый зур ил сугышында мин дә батырлар берлә бергә булса идем, ни булыр иде.

Капка башындагы нәүбәтче. Сугышка тотыштылар!

Хатыннар. Тәңрем, ярдәм ит. Тәңрем, безне урыс коллыгына төшермә! Тәңрем, кызларымызны урыслардан рисвай иттермә. Тәңрем, ярдәмче бул. Йауйас, йауйас!

Пәрдә төшә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Гайне[26] мәйдан. Бер көн вакыт үткән. Хатыннар, балалар мәйданда. Йосыф та үзенең аксак-туксак, карт-коры сакчылары берлә мәйданда.

Капка башындагы каравылчы гаскәр. Безнең атлылар бик күп урыс тоткарларын китерәләр. Капканы ачыңыз!

Түбәндәгеләр капканы ачалар. Берничә атлы татар гаскәре берничә йөз урыс гаскәрен капкадан куып кертә. Урыслар аптыраган хәлдә.

Бер татар хатыны. Урыс батырлары килде, урыс батырлары, сәлам торыңыз!

Балалар сәлам торган кебек булалар. Хатыннар көлешә.

Килгән гаскәрләрнең башы *(Йосыфка).* Әсир-ләр китердек. Хан хәзрәтләре [боларны] сак тотсыннар, дип әмер бирде.

Йосыф. Баш өсте. *(Гаскәргә.)* Хәлләр ничек?

Гаскәр. Урысларга – печән өсте! Кая барырга белмиләр, кәбестә кебек турыйбыз. Безгә рөхсәт көтәбез!

Йосыф. Иреклесез!

Татар гаскәрләре чыгалар.

Йосыф *(якындагыларга).* Җепләр китереңез, шуларның кулларын багланыз![27]

Картлар, хатыннар урысларның кулларын бәйлиләр. Урыслар һичбер тавыш чыгармыйлар.

Й о с ы ф *(урысларга).* Ни телисез? *(Һичберсе дәшми.)* Ни телисез?

Б е р с е *(алга чыгып, иелеп).* Безне үтермәңез! Безнең гөнаһымыз юк, боярлар ни кушты, без каршы килә алмадык. Безне кичереңез!

Һәммәсе дә йиргә тезләнәләр.

Безне кичереңез!

Й о с ы ф. Качарга теләмәсәңез, һичберегезнең чәче дә кыймылдамас, тыныч булыңыз. Алыңыз шуларны, шул почмакка йирләштереңез!

Әсирләрне алалар.

Капкадан унбиш-егерме т а т а р  я р а л ы с ы керә. Кайсы аксый, кайсының йөзе кан эчендә, кайсының кулы баглаган, кайсылары көчкә-көчкә генә атлыйлар. Хатыннар, зәгыйфьләрнең култык-ларына кереп, аларга ярдәм итәләр.

Б е р  х а т ы н *(чиләк берлә китергән кайнар шурпасыннан кәнди-кәнди шурпа өләшә).* Эчеңез, эчеңез, эчеңезгә йылы керер.

Яралылар эчәләр.

Б е р  я р а л ы. Рәхмәт, авызым корыган иде, кяфер башыма сукты, үзен дә җәһәннәмгә җибәрдем, әмма башым да ярылды ахрысы, кан туктамый.

И к е н ч е  я р а л ы. Мине сөңге берлә чәнчеде. Күзне ут алган, тирә-юньне күрә алмыйсың. Арттан чәнчеделәр.

Б е р с е. Атымның аягына ук керде дә, ат сискәнеп сикерде, мин дә егылдым, торып өлгерә алмадым, бер урыс кылыч берлә салдырды, ат калды, китә идек, калканымны тотып өлгердем, алай да аягыма чапты, киез итек булмаса, аяк киткән иде. Үлем ачысы берлә үзен дә муеныннан алып будым, үтердем.

Б е р с е. Минем бернәрсә юк, атым үлде дә җәяү калдым. Шул арада иңбашыма ук керде, шул гына бар, шуны чыгарып буып бәйләңез дә мин тагы китәм, уң кулым эшкә ярый. Анда безгә әле эш күп, урыс явының исәбе-хисабы юк, кырмыска кебек үтерә-үтерә кылычларымыз тутыкты.

Хатыннар яралыларны өйләренә алалар. Капкадан әллә ничә чана төялгән ашамлык, тагы әллә ничә йөз урыс әсире китерәләр.

Әсирләрне китерүче *(Йосыфка).* Мин сигез йөз урыс әсирләре китердем, илле чана азык. Боларны кая куйыйк?

Йосыф. Әсирләрне монда керт.

Әсирләр керә.

Чаналар монда сыймас.

Китерүче гаскәр. Әле анда меңләп чана бар, кая сыйсын, әсирләрнең дә саны юк.

Йосыф. Хәлләр ничек?

Гаскәр башы. Сугыш бетте кебек, урысларның сугыш сафы калмады, башлыклары бар да качты, меңләп-меңләп гаскәр әсир төште, безнекеләр куа киттеләр. Миңа рөхсәт, ханзадә? Эшләремез күп. *(Сәлам биреп чыга.)*

Бер хатын. Боларны бәйләргә җеп җитмәс. Урыс патшасының Мәскәүдә кешесе дә калмагандыр.

Әсирләрне бәйләп озаталар. Тыштан чаналардан капчыклар, итләр, ганимәт малы[28] ташыйлар.

Капка башындагы каравылчы. Сугыш бетте, ахрысы, безнең гаскәр хан хәзрәтләре байрагы янына җыелалар.

Хатыннар. Урыс байрагы күренәме?

Каравылчы. Юк, урыс байрагы күптән юк... Безнең байрак калыкты. Хан хәзрәтләре, гаскәрләр калага кайталар. Без җиңдек.

Хатыннар. Илемез, көнемез котылды!

Балалар *(кычкырыша).* Сугыш бетте – без котылдык. Урысны җиңдек!

Карт хатыннар. Амин, Амин!

Йосыф әсирләрне йирләштереп, китергән малларны җыйнап, анда чабып, монда чабып йөри.

Каравылчы. Хан хәзрәтләре, батырлар якынлашалар.

Хатыннар. Гаскәрләремез килә, гәскәрләремез җиңеп килә!

Зур капканы ачалар. Бөтен хатыннар, ханбикәләр һәммәсе ике якка тезелгән. Хан ягында угыллары, коман-даннар һәммәсе кан эчендә капкадан керәләр.

Хатыннар *(беравыздан).* Котлы булсын падишаһым, котлы булсын батырларымыз, котлы булсын гаскәрләремез. Илемезне, көнемезне коткардыңыз! Хуш килдеңез, хуш!

Гаскәрләр арыган, хан да, команданнарның да бөтен өс-башлары кан эчендә. Гаскәрләр хатыннар арасыннан үтә, саф-саф тезелә. Хатыннар гаскәрләргә кәнди-кәнди кайнар аш бирәләр, үзара сөйләшәләр. Атлар да тирләгән, пешкән, кайберләре яраланган. Хан үзенең өенең болдырына чыга, гаскәргә каршы борыла. Янында угыллары, команданнары.

Хан. Команданнарым, төмән башларым, мең башларым, йөз башларым, угланнарым, гаскәрем! Тәңренең ярдәме берлә шул канлы сугышта үземездән ун мәртәбә артык дошманны җиңдек. Моның берлә аналарымыз, апаларымыз, хатыннарымыз, сеңелләремез, кызларымыз-ның намусын-сыен гына саклап калмадык, илемезнең, халкымызның хөрмәтен-сыен күкләргә чыгардык. Олуг Чыңгызның, безгә мирас калдырган Батый хан иленең барлыгын, зурлыгын дошманга тагын бер мәртәбә таныттык, дәүләтемезне югалып китүдән коткардык. Бу зур эшне, тарихымызда онытылмаячак каһарманлыкны, гаскәрләрем, сез башкардыңыз, сугыш сафында шәһид булган сезнең иптәшләреңез, кардәшләреңез башкарды. Дәүләтеңезгә, халкыңызга иткән бу батырлыгыңыз-дан мин – сезнең ханыңыз, Чыңгызның баласы, сездән бердән меңгә кадәр разыймын. Сездән Тәңре дә, пәйгамбәр дә разыйдыр. Ил, дин юлында түккән каныңыз бушка китмәячәктер! *(Якыннары үлгән хатыннар елыйлар).* Бикәләр, туталар, сеңелләр! Барыңыз да ирләреңезне, угылларыңызны, кияүләреңезне, туганнарыңызны югалттыңыз. Мин дә угылым кебек киявем, дустым Галибирдене югалттым, минем дә кызым сезнең кебек тол калды, минем дә туруннарым[29] сезнең балаларыңыз кебек ятим калды. Болар һәммәсе ил өчен шәһид булдылар. Йирләре оҗмахтадыр, алар өчен егламаңыз. Бу көнге шул зур шатлыклы котылу көнемездә аларның җаннары безнең берлә бергәдер, аларның хатирәләре һәрвакыт безнең күңелемезнең иң тирән йирендә яшәячәктер! Гаскәрләрем,

инде шул җиңүемезнең йимешләреннән һәммәңезгә файдаланырга Тәңре насыйп итсен, һәммәңез арыдыңыз, әлсерәдеңез, хәл җыеңыз! Бу – хакыңыздыр. Ләкин шуны да онытмаңыз, безнең бүген дошманнан куркуымыз юк, алар бүген төнәге[30] безем хәлемездә. Алай да булса, бу йир безнең илемез түгел – бөтен тирә-юне дошман халык. Тынычланыңыз, Алланың әмере берлә, үз илемезгә, бабаларымызның төп иленә – Болгар йортына китәчәкмез. Илемез, дәүләтемез мәңге яшәсен дип, тагы әле бик күп эшләр эшләргә тиешмез, шул изге байрагымызны мәңгегә илемездә салланачак хәлдә дәүләтемезне көчләндерергә тиешмез. Шат булыңыз, гаскәрләрем, сезләр ирекле!

Бөтен гаскәрләр атларыннан төшә, кардәш кабиләсе берлә күрешә. Ханның янына Йосыф килә, сәлам бирә.

Йосыф. Кала эче сау-сәламәт. Урыслар бу тарафка килмәделәр. Әсирләр бик күп, әле санау бетмәде, инде ун меңнән уздык. Өч мең кадәр ат бар, биш-алты йөз җигелгән атлы чана, бик күп ашамак-эчмәк, сугыш кораллары да шактый күп. Әсирләр арасында бояр балалары да бар. Баш команданнары тотылмаганнар, качканнар. Илче булып килгән Василий Сабакин берлә Андрей Галитаевлар да әсирләр арасында. Әсирләр хакында әмереңезне көтәм.

Хан. Бояр балаларын аерып алып берәр өйгә йирләштереңез, алар өстеннән бик нык сакчылар куеңыз, качмасыннар, урыс гаскәрләрен салам абзарларга тутырыңыз, яралы атларны суеп, үзләренә берәр кайнар аш биреңез. Кичә алар дошман гаскәре иде, бүген Алланың бәхетсез бәндәләре генә. Шәфкать берлә эш күреңез. Василий Сабакин берлә Андрей Галитаевны монда китереңез!

Йосыф янындагыларга әмер бирә. Ике ялан кылычлы углан Сабакин берлә Галитаевны хан янына китерәләр.

Хуш килдеңез, боярлар! Минем шартларымны кабул итәргә дипме килдеңез?

Боярлар калтырыйлар. Тынлык. Гаскәрләргә кайнар сөт тараткан хатынга:

Бикә! Шул боярларга берәр кәнди кайнар аш бир!

Бикә ике кәнди сөт суза, боярлар аптырап торалар.

Эчеңез! Сезнең ташыңызга без аш берлә җавап кайтарамыз.

Боярлар эчәләр.

Тәңренең гаделлеген күрдеңезме?

Б о я р л а р *(тезләнәләр).* Гафу ит, падишаһым, наданлык иттек. *(Ханның аягын үбәргә маташалар.)*

Х а н *(үбәргә ирек бирмәенчә).* Үбеләчәк минем аягым түгел, менә шул байрак. *(Күк байракны күрсәтә. Галитаевка.)* Син аны тар-мар итәчәк идең, үп шуны!

Б о я р *(күк байракны үбә).* Падишаһым, гөнаһымны багышла.

Х а н. Никадәр әдәпсез булсаңыз да, юкка кан түгәргә сәбәп булсаңыз да, качарга маташмасаңыз, һичберегезнең башын кисмим, инде качарга теләсәңез, йә фетнә чыгарырга уйласаңыз, үзеңезгә үпкәләңез. Алыңыз шуларны!

Боярлар сәҗдәгә китеп, сәлам биреп калкып китәләр.

Янындагыларыңыз һәммәңез тыныңыз!

Х а н б и к ә. Падишаһым, инде син дә бераз тын, юын. Өс-башың кан эчендә. Арыгансыңдыр, әйдә, өйгә кер.

Х а н. Ул кан – мөкатдәс кан, миңа шәһид булырга Тәңре язмады, бары шулкадәр канымны агыздым.

С ә е д. Ханым, әле сезнең илемез, дәүләтемез тугрысында бик күп эшләреңез бар. Тәңре сезне сакласын!

Я н ы н д а г ы л а р. Амин!

Хан балалары өйгә таба атлыйлар.

П ә р д ә т ө ш ә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Казан шәһәренең каршысындагы Ослан тау өстендәге бушлыкта кыш көне, бөтен тирә-юньне кар каплаган. Ерактарак кар өстендә киездән чатырлар

(киез өйләр) корылган. Берсенең өстендә Алтын Урда байрагы саллана. Хан чатыры чатырлардан бераз алда. Казанга караган бер җирдә гаскәр башлыклары, олуг түрәләр, сәедләр тупланган. Яннарында Олуг Мөхәммәд хан да угыллары берлә бергә Казан шәһәренә күндергән илчеләренең җавабын көтәләр, һәммәсе Казанга таба караган. Тынлык.

Бер түрә. Хан хәзрәтләре, теге яктан чаналарда төркем-төркем халык монда таба килә.

Икенчесе. Шулай, шулай.

Өченчесе дә. Тугры киләләр.

Бер түрә. Чаналар күбәйде, болар безне каршы алырга киләләрме, әллә моннан китеңез, безнең илдә сезгә урын юк, дияргә киләләрме?

Бер батыр. Кабул итмимез, дисәләр, сугышып керермез, без мондый гына шәһәрләрнеңме капкаларын ачтырдык!

Олуг Мөхәммәд. Казан бит урыс каласы түгел, үз шәһәремез. Үзара сугыша-сугыша бит дөнья йөзен тоткан Бату дәүләтеннән *(халыкка күрсәтеп)* менә нәрсә калды. Чыңгыз балалары урыс-дошманга сыгынуга кадәр түбән төштеләр. Әгәр Казан кабул итмәсә, күтәрелеп сахрага китәмез, казак буламыз. Илдәшләр арасы сугышларга мин сәбәп тә була алмыйм, бу сугышларда башлык та итә алмыйм.

Сәед. Сүзләреңез бик тугры, хан хәзрәтләре! Без хәзер ничек булса алай башсыз калган илләремезне бергә җыярга, бер көч итеп Чыңгыз байрагы астында берләштерергә, бабаларымыз вакытындагы илемезне бер җан, бер кан итәргә тиешлемез, шулай эшли алсак кына дошманга каршы илемез, дәүләтемезне саклый аламыз.

Хан. Тугры, сәед хәзрәтләре!

Бер түрә. Килүчеләр бик күп күренәләр, болар кемнәр?

Икенче түрә. Килсеннәр дә күрермез.

Тимер командан. Болгар иле безнең бабайлар бу илләргә килгәндә гаскәрлек ягыннан зәгыйфь булса да, бик күп эштә бабаларымызга остазлык итте, динемез мөселманлыкны без Болгар иленнән алдык, китабымыз, язуымызны болгарлардан өйрәндек, шәһәр төзү үрнәген алардан алдык, олуг

ханнарымыз заманында да акчаларымыз Болгар шәһәрендә сугыла иде. Безнең Каракорымнан, уйгыр иленнән, Себердән килгән аеры-аеры уймакларымызны[31] берләштерүдә Болгар иле җилем булды. Тәңре боерса, Болгар иле шул таркау илләремезне берләштерүдә тагы да җилем булачак.

Берничә кеше. Тугры сүзгә җан корбан!

Олуг Мөхәммәд. Тәңре ярдәме берлә тагы бабаларымызның мирасы – шул таркау илләремезне берләштереп, дошманнарымызга көчемез, куәтемезне тагы танытачакмыз, байрагымызны тагы сайдырачакмыз![32]

Тау өстенә өч төркем халык ашыга-ашыга менәләр. Монда халык тына. Һәммәсе килүчеләрне көтә. Олуг Мөхәммәд бераз алга чыга.

Килүчеләрдән бер төркем *(якынлашып)*. Әссәламегаләйкем?

Бу тарафтан. Вәгаләйкемәссәлам!

Галим бәк *(алга чыгып)*. Адымнарыңыз мөбарәк булсын, төкле аяк берлә килгән булыңыз. Туганлык, кардәшлек, тугрылык берлә бергә-бергә яшәргә Тәңре насыйп итсен! *(Ханга якын килеп)*. Мин – Казан шәһәренең бәге. Үлмәс ханның балаларыннан Галим бәк. Бу ил безнең бабаларымызның иле, ничә йөз еллар бабаларым монда ханлык сөрде, бөтен дөнья падишаһлыклары берлә алу-сату итте. Идел елгасыны дөнья сату-алуына ачык вә тыныч тотты, халыкны, гадәләт берлә идарә итеп, байлыкта, муллыкта яшәтте. Бу илдә ханлык сөрү минем хакым, ләкин урыс-дошман, илемезне туктамаенча бас-кын итә, угланнарыбызны, кызларны үз йортына алып китеп кол итә. Бу баскыннарны тотуда кайсымыз батыр, кайсымыз илнең сыены-хөрмәтене яхшырак саклый алса, байрагымызны ул тотарга тиеш. Син – Чыңгыз балаларының баласы Олуг Мөхәммәд – урыс-дошман берлә кылган авыр сугышларда илемез, йортымызның сыены сакладың, бабаларың кебек батырлык күрсәттең, илне башкару, ханлык сөрү синең хакыңдыр. Мин – Үлмәс ханнарның баласының баласы Галим бәк үземнең ханлык хакымны сиңа тапшырам. Кардәш-кабиләм исеменнән сине хан танып табуг салам.[33] *(Олуг Мөхәммәд алдында тез чүгеп, дәүләт мөһерен аңарга озата.)*

Олуг Мөхәммәд *(аны култыклап аякка калкыта, сузган мөһерен ала. Үзен кочаклый).* Синең бу олуг эшеңне мин һичбер вакыт онытмам вә балаларыма да васыять итәрмен. Син үзең, гаиләң генә түгел, бөтен нәселең, бәшәрең[34] миннән дә вә минем балаларымнан да дустлык, кардәшлек берлә каршылашырлар. Таркау илләремезне җыярга без бер-беремезгә кардәшчә, туганча сарылырга тиешмез! *(Тагы кочаклый вә Галим бәкне янына ала.)*

Галим бәк төркемендәге бөтен Казан олуглары Олуг Мөхәммәднең кулын үбеп табуг салалар (бәйгать бирәләр). Болардан соң шәһәр халкы төркеме алга чыга.

Алардан берсе. Падишаһым, мин – Казан каласының аксакалымын. Болар – шәһәрнең атаклы сатучылары, олуглары. Бабаларыңыз хан хәзрәтләре вакытында безнең Болгар, Биләр шәһәрләремез дөньяның иң зур бай шәһәрләре иделәр. Сатучы-алучымызның көймәләре бөтен Идел өстен болыт кебек каплый иде. Күрше илләрдә генә түгел, озак кяфер мәмләкәтләренә кадәр малымыз-туарымыз тарала, комачыбыз,[35] камкамыз (бөрчекле ефәк комаш), көмеш эшләремез, агач савыт, табакларымыз, олтанымыз, күнемез бөтен дөнья базарында дан тоталар иде. Ислам нуры берлә күңелләремез нурлангач, шәһәрләремез мәсҗедләр, мәдрәсәләр берлә бизәкләнгән гыйлем, белем, һөнәр үзәге булган иде. Олугларымыз арасында чыккан татусызлыктан урыс-дошман азды, сату-алу юлыбызны кисте, илемезгә баскын итте, ил эчендә тынычлык качты, бай илемез ярлылыкка төште. Без – падишаһым, Тәңрене таный, пәйгамбәренә буйсына, йолаларымызны хөрмәт итә, зурны – зур, кечкенәне кечкенә күрә торган зәгыйфь адәм балаларымыз. Гадәләтле башкаруыңызга мохтаҗмыз. Шәһәрнең бөтен сатучысы-алучысы исеменнән табуг салам. *(Тез чүгеп ханның кулын үбә. Казан каласының ачкычын бирә.)*

Хан *(аны култыгына кереп күтәреп).* Ил – барымызның да уртак малы. Дошманнарымызга дошманлык безне бүген ничек берләштерсә, арамыздагы дустлык, кардәшлек тә шулай ук берләштерелсен!

Шәһәр халкы олуглары ханның кулын үбеп табуг салалар. Өченче төркем якынлаша.

Араларыннан бер карт. Падишаһым, без – кара халык, укуымыз зур юк, сүземезне дә йирендә сөйли белмимез. Падишаһым, синең урыс-дошман берлә кылган соңгы сугышларны ишетеп, үземезне анадан яңы туган бала кебек шатландык, кара көннәремез дә бәйрәм булды. Тәңре безгә шул падишаһны кайчан башымызга кичерер икән дип белер-белмәс догаларымыз берлә Аллага ялвардык. Догамыз кабул булды. Сезне, падишаһым, дөнья күзе берлә күрәмез, без – кара халык синең тугрылыклы боерыкларыңны көтәмез *(кулында май берлә балны сузып),* тормышыгыз бал кебек татлы, май кебек көчле, сөт кебек ак, пакь булсын, падишаһым, бөтен кара халык исеменнән табуг салам, падишаһым! *(Кулын үбә.)*

Олуг Мөхәммәд (*балдан да, майдан да каба, үзе аксакалга озата*). Инде син дә минем сыемнан согын!

Карт тартынып кына алып каба.

Халкымның тормышы бал да май булса, минем дә көнкүрешем бал да май булачак. Тәңре тарафыннан миңа йөкләнгән илне тигез тоту йөген тугры юлдан алып барыр-га бөтен көчем берлә тырышачакмын. Адәм баласымын, хатам да булыр, миңа яңлышлыкларымны күрсәтеңез, туг-рылык берлә ил эшләрен башкарырга барыңыз да ярдәм итеңез.

Моның янындагы кешеләр дә бәйгать бирәләр.[36]

Сәед. Безне бу олуг көнгә ирештергән безнең кебек үк кардәшләремез, туганнарымызның җаннарын, каннарын айамаенча ил котылуы өчен шәһидлек дәрәҗәсенә ирешүләре булды, аларның батырлыклары бу карлы-боз-лы көннәрдә сезнең йылы йөрәгеңезгә безгә юл ачты. Шәһидләремезнең рухына бер дога!

Барысы да кулларын күтәрәләр, бераздан йөзләрен сыйпыйлар.

Галим бәк. Боерың, хан хәзрәтләре, боерыңыз, олуг түрәләр! Гаскәрләр, шәһәр халкы сезне күрергә җан ата.

Хан угыллары, бөекләре берлә чаналарга таба йөри. Шәһәрдән килгән музыка такымы[37] музыка уйнарга тотына. Хан, бөекләр сәхнәдән ераклашалар, алар артыннан ханбикә, бикәләр киләләр. Гаскәр маршы уйнала. Гаскәр дә үтә башлый.

Пәрдә төшә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Бер көннән соң Казан шәһәрендә хан сараенда. Сарайның зур залы, идәнгә паласлар җәелгән. Түшәмгә зур кандил[38] асылган, диварларда кечкенә-кечкенә кандилләр. Диварларда матур язулы аятьләр, хәдисләр, шәмаилләр асылган. Залның түре, берәр сөям югарырак, аның урта бер йиренә тәхет корылган. Түрдән түбәндә ике яклап берничә урындыклар тезелгән. Залы зиннәтле, тәрәзәләре зур. Сул тарафта хатын-кыз ягына бер ишек, уң тарафта зур ишек бар. Залның дивары буйларына көрпәләр җәелгән, мендәрләр куелган. Тәхеттән (түрдән) түбән йирдә берничә тәбәнәк язу өстәлләре куелган. Диварда зур бер сәгать тә шалт-шолт йөреп тора. Пәрдә ачылганда, Олуг Мөхәммәд – падишаһча киенгән (тәхет янында таҗ да тора), бер тәбәнәк өстәлнең янында аяк бөкләп утырган да өстәл өстендәге бик күп язуларны укып тора. Озын гына тынлык. Хатын-кыз ягыннан ханбикә – Гөлбикә күренә, бәйрәмчә киенгән.

Гөлбикә. Таң яхшы, падишаһым!

Олуг Мөхәммәд *(башын калдырып).* Таң яхшы! Яңы йортта ничек йокладыңыз?

Гөлбикә. Биләүсәдәге бала кебек. Күптән мондый тыныч йокы күрмәгән идем.

Олуг Мөхәммәд. Бу качаклык тормышы сезгә дә ирләрдән авыррак булды, инде тынарсыз.

Гөлбикә. Бу көнне күрермез дип уйламаган идем. Әйтергә генә җиңел, яңадан таҗ-тәхеткә кавыштык. Күңелем шатлык эчендә, падишаһым! Нинди изге эшемез Тәңрегә ярады да безне тагы үз тормышымызга кавыштырды?

Олуг Мөхәммәд. Шөкранәсен кыл. Тагы изгелек эшлә!

Гөлбикә. Бәхетемез ул кадәр зур ки, нинди изге эшкә тотынсам, аны капларлык түгел, ни эшлим икән дип, мин шуны уйлыйм. Сугышта атасыз калган берничә үксез кызны өйләндерим, дим!

Олуг Мөхәммәд. Эшлә, эшлә! Кем берлә кемне өйләндерәчәксең?

Гөлбикә. Атасыз-анасыз фәкыйрь гаскәрләр берлә.

Олуг Мөхәммәд. Өйләндер, өйләндер, үз угылларыңны да онытма! Ике угылың җитешкән. Казан олуг-ларының, бәкләренең кызлары бардыр, алар берлә кода-кодагый булырмыз.

Гөлбикә. Ул да һаман күңелемдә. Ягъкуб берлә Йосыфны күптән башлы-күзле итәргә кирәк иде, бу качак-лык мәшәкатьләрне оныттырды.

Олуг Мөхәммәд. Дәүләт эшләре мине бөтен яктан чорнап алган, өй эшләрен карарга вакытым юк, боларны син төшен.[39] Кызлар ничек, сәламәтләрме?

Гөлбикә. Әле һаман йоклыйлар, алар да бу сугыш эчендә, озын суык юлда бик йончыдылар.

Олуг Мөхәммәд. Барлыкның, байлыкның, сый-хөрмәтнең кадерен белергә сабак булыр, бала-чаганы наз-нигъмәт эчендә үстереп, бабаларымызның иске йолаларын оныттык. Безнең әбиләремез бөтен сугышларда ирләр берлә бергә булганнар, аларга авыр көннәрендә көч биргәннәр, шуның аркасында бабаларымыз ярты дөнья биләгәннәр.

Гөлбикә. Безнең балаларымызга назланырга тугры килмәде, һаман сугыш эчендә яшьлекләре кичте. Әле мин шуны диячәк идем, Казанның олугларының, мирзаларының бикәләре котларга, күрешергә килделәр, безнең хатын-кыз тарафында күп мосафир кабул итәрлек зур бүлмәләр юк, бу бүлмәдә аларны каршылый вә сыйлый алмамызмы?

Олуг Мөхәммәд. Безнең хәзер җыелышымыз бар, өйләдән соң буш булыр.

Гөлбикә. Безнең кунаклар дә өйлә ашыннан соң гына киләчәкләр.

Уң яктагы ишектән берсе башын тыгып карый.

Олуг Мөхәммәд. Бераздан керегез!

Кеше югала.

Гөлбикә. Мин артык борчымыйм, падишаһым. Өйлә ашын балалар берлә ашый аламызмы?

Олуг Мөхәммәд. Көтелмәгән кунак килеп чыкмаса, бергә ашармыз.

Гөлбикә. Балалар әтиләрен сагындылар. *(Үзе чыга.)*

Олуг Мөхәммәд (*көр тавыш берлә).* Мирза Гали!

Мирза Гали керә.

Мирза Гали *(язучы ишектән керә, бик каты иелеп сәлам бирә).* Боерыгыңызның колы фәрманыңызны көтә. *(Кулында язу бөтисе.)*

Олуг Мөхәммәд. Ул кәгазьләр нәрсә?

Мирза Гали. Төрле-төрле котлау бөтиләре, бәйгатьләр, падишаһым!

Олуг Мөхәммәд. Шәһәрнең хәле ничек?

Мирза Гали. Бөтен шәһәр бәйрәм итә. Һәрбер өй гаскәрләрне кунак итеп алды, туган өйләрендә кебек сый-хөрмәт күрәләр. Бүген һава да бәйрәм көне кебек кояшлы, җилсез, тып-тын. Аягыңыз мөбарәк булды, падишаһым, таҗыгыз, тәхетеңез мәңгелек Казанда калсын!

Олуг Мөхәммәд. Амин! Киңәш өчен чакырылган олуглар, бәкләр килделәрме?

Мирза Гали. Галим бәк, сәед Җәлил, Тимер командан вә башка олуглар әмереңезне көтәләр, падишаһым!

Олуг Мөхәммәд *(аякка калка).* Бәкләрне, команданнарны, сәедләрне монда чакырыңыз, башка килүчеләр булса, аларны көттерсеннәр, безнең олуглар берлә киңәшемез бар.

Гали мирза чыга.

Олуг Мөхәммәд таҗын киеп тәхеткә якынлаша. Ишектән олуглар керәләр, һәммәсе дә рөкугъка киткән кебек сәлам бирәләр. Олуг Мөхәммәд тә аяк өстендә.

Олуг Мөхәммәд. Боерыңыз, боерыңыз! *(Үзе тәхеткә чыга. Уң ягына Казан олугларына йир күрсәтә, сул ягына үзенең олугларын утырта.)* Хуш килдеңез, саумысез? Арумысез?

Һәммәсе дә. Аллага шөкер!

Олуг Мөхәммәд *(Казан олугларына).* Шәһәр халкы сау-сәламәтме?

Галим бәк. Һәммәсе бәйрәм итәләр, хан хәзрәтләре!

Олуг Мөхәммәд *(команданнарга)*. Гаскәрләр, угланнар саулармы?

Тимер командан. Барысы да туйда кебек сый эчендә, хан хәзрәтләре! Казанлы туганнарымыз барымыз-ны да кунак итәләр.

Казан аксакалы. Бу безнең бурычымыздыр, без сезне, хан хәзрәтләре, күптән көтә идек. Тәңре бу көн насыйп итте.

Олуг Мөхәммәд. Яр булыңыз,[40] бу кадәр зәхмәт, мәшәкатьтән соң гаскәрләрем бу сый-хөрмәткә хак казанганнармы иде, әмма сезнең юмартлыгыңыз, кардәшчә кабулыңыз безнең уйлаганымыздан да узды.

Башка бер бәк. Падишаһым, сезгә вә гаскәрләреңезгә каршы моның берлә без ил бурычымызның кечкенә генә бер өлешен үтимез. Алла кушса, тагы зурларын да үтәрмез, үтәргә хәзермез.

Олуг Мөхәммәд. Рәхмәт, рәхмәт! Бәкләр, сәедләр, гаскәр башлыклары, шәһәр башлыклары! Бүген Казан шәһәренең, Казан дәүләтенең тарихи бер көнедер, без яңа бер дәүләт корамыз, шул эштә сезнең берлә киңәшләшик дип, сезне мәшәкатьләп монда чакырттым.

Мирза Гали тәбәнәк бер өстәл янына тез чүгеп утырган да һәрбер сүзне яза бара.

Уйларыңызны ачык итеп бәян итүеңезне һәммәңездән үтенәм!

Галим бәк. Боерыгыңызга буен сыну, хан хәзрәтләре, безнең ил бурычымыз. Гаклымыз җиткән кадәр, кулымыздан килгән чаклы илемез, дәүләтемезгә, ханымызга хезмәткә һәммәмез хәзермез.

Олуг Мөхәммәд. Туганча сөйләвеңезгә рәхмәт! Һәммәңез беләсез *(казанлыларга карап),* бу илләр ничә йөз елдан бирле сезнең бабаларыңызның йире, суыдыр, бу йирләр иске-искелектән төрек балаларының тупрагыдыр, безнең бабайлар Идел буена килгәч тә бу йирләр Алтын Урда дәүләтенең бер өлеше булып яшәде, Сарай ханнарына баш иде, Сарай дәүләте дә сездән ислам динен, ислам гыйлемен алып, сезнең

гыйлемеңез, белемеңез алдында баш иде. Соң елларда хан балалары арасында чыккан тынычсызлык Болгар иленең саклануына зарар итте. Урыс-дошман безнең бөтен илемездә ат уйнатты, баскын итте, илнең тынычыны качырды. Олуг бабамыз Чыңгыз ханның варисы сыйфаты илә, Казан халкының ризасы берлә без бу илгә хан күтәрелдек. Уемыз, тынычсызлык көннәрендә аерылган, таралган илләремезне бергә җыеп, бабаларымыз вакытындагы кебек көчле бер дәүләт кору, халкымызны Тәңренең биргән нигъмәтләреннән файдаландырып, балаларымызга көчле, куәтле бер дәүләт мирас итеп калдырудыр. Мул ага торган илемезнең Идел, Ак Идел, Чулман су юлларыны алыш-биреш көймәләре өчен һәрвакыт ачык тотып, юлларымызның тынычлыгын саклау, күрше халыклар берлә дә алыш-бирешне күңел тынычлыгында йөртүдер. Сарай киң илемезнең тынычлыгын саклауны, юлларымызның каравылчылыгын үти алмас хәлгә килде. Илемезнең һәр почмагына урыс агыша башлады. Хәзер без төп тупрагымызны сак-лар өчен Чыңгыз байрагыны Казанда күтәреп, монда дошманнарга каршы кала корамыз. Казан каласы безнең кулымызда чакта һичбер урыс-дошман Идел суын үтә алмаячак. Безнең аркамыздагы илләремез – Себер, Урал, Чыгтай йорты[41] анасының кочагындагы бала кебек рәхәт итәчәк. Бу кала – Казан каласы бабаларымызның бөтен илләрен, безнең мөселман халкымызны, ислам динемезне, безнең гыйлемемезне, һөнәремезне, сату-алуымызны саклаучы, нәүбәтче булып торачак, бу кала изге кала булачактыр. Инде шул изге ниятемезне ничек тормышка куя аламыз? Менә, сәедләр, бәкләр, гаскәр башлыклары, шәһәр олуглары, сезнең шул хакта киңәшеңезне сорыйм. Уеңыз ничек, шуны ачык сөйләңез! *(Тынлык.)*

Г а л и м  б ә к. Хан хәзрәтләре, иске төрек йоласында һәрбер зур эш алдында – сугышмы, берәр яңы корылышмы, бабаларымыз, олуг ханнар заманасының олуг-ларын киңәшкә чакырып корылтай коралар иде, син дә шул иске йоламызны тотып тугры юл алдың. Әйе, без яңы дәүләт корамыз, бу – зур тарихи бер эш. Әгәр шуның нигезен нык, таза сала белсәк, бу

дәүләтемез озын еллар эшләячәк. Урыны зур сату юлы өстендә, халкы тырыш, аек. Хөкүмәтне дә тугрылык, гаделлек өстендә йирләштерә алсак, бу дәүләтне урыслар бөтен дөнья шайтаннарын җыеп килсәләр дә берни эшли алмаячаклар. Мин бу илнең эшендә, халыкның да эчендә булган кеше. Мактанып сөйләмим, халкымызны таныйм, аның теләген беләм. Әгәр хан хәзрәтләре муафикъ тапса, мондагы олуг-лар да шуны яратсалар, яңы дәүләт корылуын вә халкымызга нинди уңайлыклар төшүен вә нинди бурычлар йөкләнүен белдереп бер ярлык таратсаңыз, һәркемгә яңы дәүләтне ап-ачык танытыр иде.

С ә е д. Бу бик тугры уй. Пәйгамбәремез дә сәхабәи кирам берлә киңәшләшә иде. Хан хәзрәтләре, бу мәҗлесләрне һәрвакыт өчен ясасаңыз ничек булыр? Аннан соң бу ярлыкта бабаларымызның дине, дин исламның хөкемнәрне ригая ителәчәге[42] дә язылса иде! Соңгы елларда халык арасында дини эшләрдә башбаштаклыклар күренә башлады, мәҗүсилек, шаманилык халык арасында бетеп йитмәгән.

Т и м е р к о м а н д а н. Таралган уймакларны җыяр өчен халкыбызга яңы дәүләтнең корылуын вә хан хәзрәтләренең изге ниятләренә белдерү кирәкле эш. Ләкин бу яңы корылган дәүләтнең төп көче – безнең гаскәремездер. Гаскәрлекне иске бабаларымыз чагындагы хәлгә китерә алсак, илемезне җыеп, дошманнардан җиңел саклый аламыз. Гаскәр эшләрендә, беләсез, бер генә баш булырга, бер генә баштан боерык чыгарга тиеш. Ул да безнең олуг ханымыз, сәед хәзрәтләре дигән кебек, һәр эштә шундый киңәшләр ясасак, хан хәзрәтләренең ил каршындагы йөге җиңеләячәк, әмма гаскәр эшендә комачаулык булмасын дип куркам.

К а з а н б а ш л ы г ы. Мин мондый киңәшләрне мәмләкәтне алып бару юлында авырлыклар чыкканда гына кирәк дип аңлыйм, гаскәр эшен хан хәзрәтләре үзе дә белә, сез дә, команданнар, яхшы беләсез, бу эш иске йоламыздагы кебек хан хәзрәтләренең әмерендә генә булырга тиеш. Гаскәр башларын хан хәзрәтләре үзләре билгеләрләр. Бу эшләр Чыңгыз хан, Батый хан, Бәркә хан чакларындагы кебек йөрсен!

К а й б е р л ә р е. Тугры, тугры! *(Тынлык.)*

О л у г М ө х ә м м ә д *(халык аксакалына).* Синең уең ничек? Нинди теләкләрең бар?

А к с а к а л. Хан хәзрәтләре, без – кара халык, үземезнең ханымыз, олуг түрәләремез, дин башларымыз, сәедләр алдында ил бурычымызны түләргә тиешмез: салымымы бар, олау чабумы бар, гаскәр бирүме – болар барысы да илгә каршы, ханга каршы бурычымыз. Иске йоламыз да безгә моны боера. Илнең тынычлыгы дә ансыз булмый, кара халык моны аңлый. Аның күңеле тыныч булсын өчен, хан хәзрәтләре, кечкенә түрәләрнең халыкка тугрылык берлә эш итүләре кирәк. Олуг түрәләрне сез, хан хәзрәтләре, үзеңез, вәзирләреңез үз күз астында тота аласыз, кечкенә түрәләрнең дә тезгенене буш калдырмаска кирәк.

О л у г М ө х ә м м ә д. Аксакалның сүзләре тугры. Озак илләрдәге түрәләрне ничек тикшерү астында тотарга кирәк? Моңа ни дисез?

Г а л и м б ә к. Хан хәзрәтләре, олугларымыз тугры юлдан китсә, кечкенәләремез юлдан язмаслар, тугрылыкны бозарга батырчылык итә алмаслар. Тарих та моны ачык күрсәтә. Ханнарымыз, вәзирләремез тугры, гадел булган чакта ил-көн тугрылыктан язмаган. Олугларымыз үз бурычларын үти алмаганда, кечкенә түрәләр үз белгәннәрен кылганнар. Салым салуда, бирге бирүдә тугрылыктан аерылмаска тырышырга тиешмез.

К а й б е р л ә р е. Тугры, тугры!

Мирза Гали һаман яза.

О л у г М ө х ә м м ә д. Тагы нинди уйлар бар. Сөйләңез!

А л т ы н б ә к. Хан хәзрәтләре, бабаларымызның йоласы буенча, күрше падишаһларга ярлык язып, Сарай шәһәре йиренә Казан шәһәрендә дәүләт корылуны белдерергә кирәк. Урыс кенәзләренә дә моннан соң даньнарын[43] Казанга бирергә, кенәзлек ярлыкларын Казаннан алырга икәнен аңлатырга тиеш. Чит мәмләкәтләр берлә эш итүдә күп мәсьәләләр бар, безгә урысларга каршы һәрвакыт ләһ[44] корольләре берлә бер сүздә булырга кирәк.

К а й б е р л ә р е. Тугры, тугры!

О л у г  М ө х ә м м ә д. Уйлар шактый ачылды, файдалы фикерләр ишеттек. Зур эшләр чыкканда шундый киңәшләр ясау кирәкле булачак. Чакырган вакытта килеп уйларыңызны бирүдән моннан соң да тартынмаңыз. Илгә-көнгә зарарлы берәр эш тойсаңыз, берәр фәрманымыз йирсез[45] чыкса, һәрвакыт килеп миңа эшне аңлатыңыз. Бәндә хатасыз булмый. Аңарга кемсәгә үпкәмез булмаячак. Инде хөкүмәт төзүне мин шулай төшендем, сез ничек тапсаңыз, ачык сөйләңез. Баш вәзир итеп Тимер команданны куйсак, без гаскәргә таянган бер дәүләт булганга, баш вәзир дә, минемчә, гаскәр булырга кирәк.

Һ ә м м ә с е. Тугры, тугры, бик мөнасиб![46]

Т и м е р  к о м а н д а н. Хан хәзрәтләре, эштән тартынудан түгел, бу зур эшне мин алып бара алырмынмы дип куркам.

Х а н. Алла ярдәм итәр. Син тартынма!

Б а ш к а л а р. Тугры, тугры!

Х а н. Эчке эшләр – тынычлыкны саклау, салым салу, бирге бирү, юлларны, күперләрне таза тоту эше вәзирлегенә Галим бәкне куйсак, дим, ул бу илнең эчен, тышын белә.

Г а л и м  б ә к. Илтифатыңызга рәхмәт, падишаһым, сез юл күрсәтсәңез, кулымнан килгән кадәр тырышырмын.

Һ ә м м ә с е. Тугры, тугры!

Х а н. Чит дәүләтләр берлә, күрше халыклар берлә эшләрне алып бару өчен – Алтын бәк. Ул күп йөргән, күпне күргән, күпне белгән кеше.

Х а л ы к. Тугры, тугры!

А л т ы н  б ә к. Хәлдән килгәнчә, әмереңез баш өстемдә.

Х а н. Дин эшләремез, мәхәлләмез, мәсҗедемез, мәдрәсәмез, вакыфларымызны карар өчен – сәед Җәлил әфәнде.

Һ ә м м ә с е. Тугры, тугры!

Х а н. Шуның берлә әлегә эш башлансын. Һәммәңез бүгеннән эшеңезгә башлаңыз!

Мирза Гали яза.

Олуг Мөхәммәд. Синдә, Мирза Гали, нинди кәгазьләр бар?

Мирза Гали *(аякка калкып).* Бабаларыңыз рәхмәтлеләрнең[47] ярлыкларыннан үрнәк алып, халкымызга бер ярлык хәзерләгән идем. Күрде падишаһларга, Ләһстан[48] королендә, госманлы солтанына. Чыгтай иле хан-әмирләренә күндереләчәк ярлыклар язган идем.

Алтын бәк. Урыс кенәзләренә язылачак та хәзерме?

Мирза Гали. Аны яза алмадым, аларга фәрман улачак түгелме?

Ишектән бер углан *(керә, сәлам бирә).* Хан хәзрәтләре, чуваш иленнән, тау ягы чирмешләреннән аксакаллар килгәннәр, хозурә кабулларын үтенәләр.[49]

Олуг Мөхәммәд. Галим бәк, китеп, караңыз, илләренең чыннан олуглары булса, монда алыңыз!

Галим бәк чыга.

Сәед. Хан хәзрәтләре, бу ярлыкларны җомга көнне, җомга намазыннан соң бөтен илнең мәсҗедләрендә бер көндә, бер вакытта укылса иде.

Олуг Мөхәммәд. Өлгерә алсак, яхшы булыр. Сез, вәзирләр, берлектә бу ярлыкларны күздән кичереңез. Мин дә бүгенге тарихта мөһеремне басыйм да күрше шәһәрләргә ат чаптырырсыз. *(Тимер командангa.)* Бу чуваш, чирмеш аксакалларына, илләренең олуглары булса, берәр чикмән кидереңез, берәр иярле ат биреңез, ханның бүләге – сагынмалык, диеңез!

Тимер. Баш өсте, падишаһым!

Ишек ачыла, өч чуваш, аның артыннан дүрт чирмеш аксакалы берлә Галим бәк керәләр. Кергәннәр рөкугъка китеп сәлам бирәләр.

Галим бәк. Хан хәзрәтләре, болар чуваш иленең, болар да чирмеш иленең аксакаллары. Йөзеңез[не] күрер өчен, табуг салу өчен килгәннәр.

Олуг Мөхәммәд. Хуш килдеңез, утырыңыз!

Мирза Гали боларга йир күрсәтә, һәммәсе дә тез чүгеп утыралар.

Илеңез-көнеңез саумы, мал-туар исәнме?

Ч у в а ш  а к с а к а л ы. Барысы да сау-сәламәт, падишаһым! Халкымыз сезнең килүне ишетте, эчтән сөенде, безне сезгә коллык итәргә җибәрде. Чуваш халкы олуглары, кечекләре атыннан табуг салам, падишаһым! *(Ханның итәген үбәләр.)*

А к с а к а л. Безнең халык – кара халык, падишаһымыз гомере бал кебек татлы үтсен дип, шул кечкенә бүләкне җибәрделәр.

Бер чуваш бер тәпән бал куя.

О л у г  М ө х ә м м ә д. Рәхмәт, рәхмәт! Халкыңызга минем рәхмәтемне ирештер!

Ч и р м е ш  а к с а к а л ы. Падишаһым, безнең бабайлар сезнең бабайларга тугрылык берлә хезмәт иттеләр, соңгы елларда илемезне урыс баскыны алҗытты. Арка таяначак йиремез юк иде, сез – хан хәзрәтләренең Казанда тәхет коруыңызны ишетеп, барымыз да сөендек. Халкымыз атыннан табуг салам. *(Ханның итәген үбәләр.)* Боерыгыңызны йиренә җиткерергә, олауларыңызны вакытында чабарга, салымнарыңызны түләргә һәрчакта әзермез. Бөтен чирмеш халкы илнең тынычлыгын Тәңредән сорый. Халкымыз кечкенә генә бүләк җибәрде, шуны зур итеп алуыңызны үтенәмез! *(Бер букча берлә чигелгән киндерләр бирә.)*

О л у г  М ө х ә м м ә д. Рәхмәт, һәммәсенә зур рәхмәт, бабаларыңызның йоласын тутырып мине күрергә килүеңезгә! Чуваш, чирмеш халыкларымның безнең зур бәйрәмемезгә катышуына чын күңелдән сөендем. Мин дә бабаларымның йоласына оеп, чуваш, чирмеш халыкларымны тугрылык берлә тотарга эшләрене гаделлек берлә башкарачакмын. Тугры юлдан йөргәннәргә һәрвакыт без мәрхәмәтле булачакмыз. Искедә чувашлар, чирмешләр үзләренең гадәтләрендә, үз йолаларында, үз диннәрендә irекле булып яшәгән булсалар, минем падишаһлыгымда шулай тыныч яшәячәкләр. Халкыңызга миннән сәлам сөйләңез, урыс котыртучыларын араңызга кертмәңез. Йомышларыңызны эчке эшләр вәзирем Галим бәк берлә бетереңез. *(Тимер командангa.)* Кунакларны сыйлаңыз!

Тимер бер угланга колагына бер сүз сөйли, ул да төрле төстәге чикмәннәр алып керә.

Тимер *(әүвәлен чуваш аксакалына).* Падишаһымыз хәзрәтләренең сезгә бүләге.

Өстенә кара чикмән кидерә. Чирмеш аксакалына да шундыйны кидерә. Яннарындагыларга икенче дәрәҗәдәге, икенче төстәге чикмәннәрне кидерә. Аксакаллар чикмәнне тотып-тотып карыйлар.

Олуг көннәреңездә, бәйрәмнәрдә бу киемнәрне олуглап киеңез, падишаһка дога кылыңыз!

Чувашлар, чирмешләр рөкугъка китеп сәлам бирәләр.

Тимер *(угланга).* Кунакларны мосафирханәгә йирләштереңез, сыйлаңыз!

Галим бәк. Иртәгә иртә берлә минем яныма эчке эшләр вәзирлегенә килеңез, дәрдләреңезне[50] аңлатырсыз.

Мосафирлар чыга.

Тәшрифатчы[51] углан *(керә, сәлам биреп).* Әбүлмөхсин дәрвиш килгән, илла[52] хан хәзрәтләрен күрәчәгем, ди. Сүземезне көтәсе килми.

Вәзирләр арасында хәрәкәт.

Олуг Мөхәммәд. Бу кем?

Сәед. Хан хәзрәтләре, бу – Газыйм сәеднең угылы, мәҗнүнме[53] дим, мәхзүнме[54] дим. Дәрвиш – тугры сүзле, халыкның ышанган бер дәрвише.

Галим бәк. Дөньяда эше юк, шигырь сөйләп, илаһилар көйләп, Коръән, хәдис укып йөри. Аның килүе, хан хәзрәтләре, хәерле фал. Ул яман эшкә катышмый, начар йиргә килми, әмер биреңез, аны кабул итсеннәр.

Олуг Мөхәммәд *(тәшрифатчы угланга).* Керсен!

Углан чыга. Тиз үк искеле-поскылы киемнәрдән, керле яшел чалмалы дәрвиш керә.

Дәрвиш *(кергәч тә).* Әссәламегаләйкем, йа әмирелмөэминин![55]

Олуг Мөхәммәд. Вәгаләйкемәссәлам, йа шафигыльмөслимин![56]

Әбүлмөхсин. Минем андый олуг ләкабем[57] юк, хан хәзрәтләре, мин – Тәңренең зәгыйфь бер бәндәсе, хәзрәте Мөхәммәднең гөнаһлы бер өммәте.

Олуг Мөхәммәд. Син әйткән олуг сыйфат миндә дә юк, төнә[58] кечкенә, бүген зур, иртәгесе мәхһүл.[59] Илнең бер хезмәтчесе. Тәңре ни язмышса, шуны кылып ятамыз.

Әбүлмөхсин. Тәңре сезгә, хан хәзрәтләре, Үлмәс хан илене, Бәркә хан йортыны кара йөрәк урыслардан коткарырга, илнең яше-картының йөзене көлдерергә язган. Йөзләрчә шәһиднең җаны, каны берлә, олуг бәкләреңезнең хәләл сөттән булган шәһадәт каны берлә мөселманлыкны сакладыңыз, шуның берлә әмирелмөэминин булдыңыз.

Олуг Мөхәммәд. Тәңре кимчелекләремезне багыш-ласын, утырыңыз!

Әбүлмөхсин дәрвиш утыра.

Әбүлмөхсин. Мин, хан хәзрәтләре, сезне күрергә мөштак улып[60] килдем. Илемезгә тәшрифеңез[61] котлы булсын. Кечкенә генә бер шигырь яздым, изенеңез[62] булса, укыйм?

Олуг Мөхәммәд. Укы, укы, тыңлыйк!

Дәрвиш *(кесәсеннән бер кәгазь чыгарып укырга тотына)*.

Яман көннәр, кара төннәр күп бастылар Кабанны,
Авырлыклар, читенлекләр күп изделәр Казанны.
Дошман явы илне басты, күп түктерде күз яшен,
Ялварышны кабул итте, безгә бирде (Тәңре) ил башын.
Чыңгыз – аның бабасы, батырлыктыр – йоласы,
Тугрылыкта ханлык сөрсен, ислам булсын анасы.
Атты таң, тугды кояш туган илнең өстенә,
Бетте кайгы, китте хәсрәт дошман илнең өстенә.
*(Бу өлешен тәкрарлый.)*

Олуг Мөхәммәд. Шигырең бик һәйбәт, бу минем өчен иң зур бүләк булды. *(Шигырь кәгазен ала.)* Башка шигырьләрең дә булачакмы, диваның[63] бармы?

Әбүлмөхсин дәрвиш. Вак-төяк язуларым бар, диваннар язарга мин Фирдәүси түгелмен.

О л у г   М ө х ә м м ә д. Син түбәнчелек күрсәтәсең, әмма шигырь куәтең аннан ким түгел.

С ә е д. Хан хәзрәтләре, Әбүлмөхсин халык моңнарын җырлый, аның шигырьләре халык арасында яши. Әсәр мәйданга китерми.

О л у г   М ө х ә м м ә д. Без таралган илемезне берләштерергә тырышамыз. Менә шул вәзирләрем – мәмләкәтнең олуглары, бәкләр шул юлда миңа ярдәм итәргә сүз бирделәр. *(Кылычына күрсәтеп.)* Бу корал илне, суны дошманнан сакларга гына ярый. Дәүләт корыр өчен белем кирәк, бер-береңә ышаныч кирәк, халык арасында дустлык кирәк, халыкның төрле катлаулары арасында күңел бавы кирәк. Ул да шигырь берлә, китап берлә, тарих берлә ясала. Бу эштә, Әбүлмөхсин, синең дә ил каршысында *(вәзирләргә күрсәтеп)* боларныкы кадәр, бәлки тагы артыграк бурычың бар. Безгә халкымыз күз уңында бабаларымыз заманындагы муллык, байлык, тынычлык чакларын җанландырырга кирәк. Дошманның яшертен хәйләләренең өстен ачарга кирәк. Гаскәрләремезгә борынгы заман батырларымызның хикәяләрен күңелләренә сеңдерергә кирәк. Син дә ил кайгысы өстендә каләм уйнат! Синең өең, йортың кая?

Ә б ү л м ө х с и н. Минем өем – бөтен Бәркә хан иле, кайда кайгылар булынса, шунда минем йортым.

О л у г   М ө х ә м м ә д. Сиңа бер өй ясыйк, бер йорт корыйк, тормышыңны илгә-көнгә багышлаган кешесең, тыныч яшә!

Ә б ү л м ө х с и н. Ил тыныч яшәсә, падишаһым, кая да мин тынычлык табармын.

О л у г   М ө х ә м м ә д. Алай булса, ил тынычлыгы өчен нишлик, ни эшләргә кирәк?

Ә б ү л м ө х с и н. Аны сез, падишаһым, вәзирләреңез миннән артыграк беләсез.

О л у г   М ө х ә м м ә д. Син дә, белгәнеңне сөйләсәң, безгә илне башкарырга уңайлык итәрсең!

Әбүлмөхсин. Падишаһым, балык баштан чери. Шаһзадәләрең, вәзирләрең, бәкләрең тугры юлдан язмавын кара.

Олуг Мөхәммәд. Сүзләрең тугры. Син дә, халык арасында хаксызлык эшләнелсә, миңа белдер.

Әбүлмөхсин. Тәңре ни кушса, шул булыр.

Олуг Мөхәммәд *(Мирза Галигә).* Әбүлмөхсин сәедкә киемнәр китер!

Әбүлмөхсин *(сәләмәләренә күрсәтеп).* Минем киемнәрем бар, хан хәзрәтләре!

Олуг Мөхәммәд. Аларны илнең ялангачларына тарат! Бу киемнәрне урыс кенәзе, безнең бәкләрне, гаскәр башлыкларымызны сатып алыр өчен дип, гаскәре берлә күндергән, без аларны ганимәт алдык. Бу хәләл мал, монда гаскәрләрнең хакы булган кадәр, син мөҗаһиднең[64] дә хакы бар, син дә ил өчен тартышучы. Тугрымы?

Әбүлмөхсин. Тугрымы, түгелме – аны бер Алла белә.

Мирза Гали кием китерә, Әбүлмөхсинне киендерә.

Олуг Мөхәммәд *(Мирза Галигә).* Сакчыларга сөйлә: Әбүлмөхсин сәед ни вакыт килсә, туктаусыз минем яныма кертсеннәр! *(Әбүлмөхсингә.)* Ил кайгысы, халык эше хакында ни белсәң, йә миңа, йә вәзирләремә килеп сөйлә!

Әбүлмөхсин. Тәңре кушса, эшләрмез. *(Сәлам биреп чыга.)*

Олуг Мөхәммәд. Сәед Әбүлмөхсин гарип табигатьле[65] адәм икән.

Сәед. Шулай, падишаһым!

Галим бәк. Зур бер мәгънәви көч иясе, падишаһым!

Бер углан *(керә, сәлам биреп).* Берсе килгән. Хан хәзрәтләренең килүе кичәсендә бер төш күрдем, шуны падишаһыма аңлатыр идем, ди.

Галим бәк. Озын сакаллы, зур борынлымы?

Углан. Әйе, әйе.

Галим бәк. Ул урыны берлә изге төш, урыны берлә кара төш күрә, аның кәсебе шул. Киеме ертык-портыкмы?

Углан. Әйе.

Галим бәк. Хан хәзрәтләре, бу үзе хәлле кеше, алай да шулай йөри, кечкенә бер нәрсә бүләк итеп бирсәләр, булырмы?

Олуг Мөхәммәд. Мондый эшләрне сез тагы яхшы беләсез.

Галим бәк. Төшен язып миңа китерсен, мин хан хәзрәтләренә тәкъдим итәрмен. Үзенә, аягына бер киез итек кидереп җибәреңез.

Олуг Мөхәммәд *(аякка калка).* Инде бүгенгә шуның берлә җитәр. Вәзирлекләр өчен йирләреңезне үзеңез аерырсыз. Ярлыклар бүген кичкә кадәр хәзер булсын. Хушыңыз!

Хан хатын-кыз ягына чыга. Аягүрә сәлам биреп калалар.

Тимер командан. Без өйлә ашыннан соң җыелып ярлыкларны тикшерик!

Галим бәк. Һәммәмез безнең өйгә китеп бергә-бергә Алла ни биргән шуны ашыйк та, шунда сөйләшермез. *(Мирза Галигә.)* Син дә кил!

Тимер. Ничек мөнасиб күрәсез?

Барысы да. Муафикъ![66]

Мирза Гали. Сез ашларыңызны ашагач, мин килсәм ярамасмы? Без кечкенә кеше олуг берлә утырырга.

Тимер. Ил эшендә олуг, кечек юк. Кил, кил, ярлык-ларны да син яздың түгелме?

Мирза Гали. Әйе.

Бар да чыгалар.

Пәрдә төшә.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук зур зал. Берничә айлар үткән, тормыш үз юлын алып өлгергән. Олуг Мөхәммәднең угылы Ягъкуб Казан олугларыннан берсенең кызы берлә өйләнә. Хатыннарның бүләк багу мәҗлесләре (бирнә карау мәҗлесе). Кырык-илле хатын төрле кыйммәтле киемнәрдә залга тулганнар. Картрак хатыннар дивар буендагы тар сәкеләргә утырганнар, яшьрәк хатыннар – аяк өсте. Киемнәре төрле төстә – атлас, ефәк, чәчәк-сачаклы, бик күп тәнкәле чулпылар, сачтакмалар, хәситәләр, энҗеле-акчалы муен

аскылары. Күбесе зур калпакларда, карт хатыннар камчат бүректә, өрбәк (өрпәк) ураган карчыклар да бар. Олуг килен Хөршид бикә кунакларны каршылый. Урам ягы ишекне ике караучы хатын киң итеп ачалар. Бер хатын керә.

Караучы. Вәзир Галим бәкнең бикәсе Фатыйма бикә!

Хөршид бикә (*каршы чыгып*). Рәхим итеңез, Фатыйма бикә!

Фатыйма *(Хөршидкә баш иеп сәлам бирә, күрешә).* Саумысыз, сәламәтмесез!

Хөршид. Аллага шөкер!

Фатыйма *(түрдәге карт хатыннарга иелеп сәлам бирә, икенче якларга да сәлам бирә дә туктап тора).* Барыңыз да исәннәрме?

Тавышлар. Тәңрегә шөкер. Тәңрегә шөкер!

Хөршид. Узыңыз, Фатыйма бикә, түргә!

Фатыйма. Бик югары булмасын, ул йирләр олуг бикәләремезнең йире.

Камчатлы бер бикә. Инде сез дә, Фатыйма бикә, олыгайдыңыз, угыл җиткерденез, кыз бирдеңез.

Фатыйма. Биргәненә мең шөкер. Әле бездән дә олуг-лар барда сангысызлык булмасын, дим, яшьләнү өчен түгел, Тансык апа!

Тансык бикә. Алай димә, әле, машалла, җегәрендәсең, ирең ишетмәсен, яшь бикәч алырга башлар.

Кояш бикә. Алса, туй итәрмез. *(Көлә.)*

Алтын бикә. Тәңрем күрсәтмәсен, авызыңнан җил алсын, инде безгә угылларымыз, кызларымызның туен күрергә насыйп итсен.

Бер бикә. Тәңрегә шөкер, үз ханымыз да булды, ханзадәмезнең туен дә күрергә язды.

Фатыйма бикә *(Хөршидкә).* Котлы булсын мәҗлесләр!

Хөршид. Бергә-бергә булсын, Фатыйма бикә!

Фатыйма утырган.

Бер бикә. Ишеттеңезме, Исмәгыйль мирза хан-түрәнең кызы Миләүшәне икенчегә сораткан, ди.

Икенче бикә. Исмәгыйль мирза да кемгә күзе төште – кыз дими, тол дими, яшь дими, карт дими, сората гына бирә. Кызы кебек яшь бер кызны соратырга оялмый да.

Тансык бикә. Ирләр андый эштән бер дә оялмый ул. Аларның бу эшкә караулары бөтенләй башка.

Бер карт бикә. Алар «карт бүре яшь кузыйны[68] ашамый, диме» генә дип җавап бирәләр.

Караучы хатын *(ишекне ачып).* Баш вәзир Тимер команданның бикәсе Сылу бикә!

Хөршид *(каршы барып).* Рәхим итеңез. Сылу апа, рәхим итеңез!

Сылу бикә. Соңга калдым, Хөршид бикә, мине кичереңез, балалар берлә мавыга-мавыга, вакыт узганны да сизми калганмын. *(Түрдәге бикәләргә иелеп сәлам бирә.)* Сау-сәламәтмесез? *(Икенче якка тагы иелеп.)* Арумысыз, саумысыз? Күргән-күрешкән булсын. Мәҗлесләр котлы булсын, Хөршид бикә!

Бер бикә. Амин!

Бер бикә. Сезнең дә угылыңыз җитешкән. Сылу бикә, сезгә дә шундый туйлар итәргә язсын!

Сылу бикә *(алга атлый).* Амин. Ата-ананың, беләсез, бөтен теләге – бала-чаганы вакытында башлы-күзле ясау. Язмыш шул без теләгәнчә йөреми. Олуг угылым Мортазага Сарайда Туган мирзаның кызы Гөлсәүирне ярәшкән идек бит, никяхка вакыт калмады, качакчылык чыкты. Мортазаның да күңеле анда калды. Ни эшләргә дә белми торамыз.

Тансык бикә. Бераз сабыр итеңез. Сарайга да юл ачылыр. Күрмисезме ничек Нугай иленнән, Уралдан, Себердән илче артыннан илче килеп ханымызга табуг салалар. Сарай үзе дә баш иячәк. Казан баш кала булып калачак. Тугрысы да шулай булырга тиеш бит, бөтен олуг эшләр Болгар илендә башланган бит. Ислам динен әүвәле монда кабул иттек, Алтын Урданың бөтен малы монда йитеште, акчасы монда сугылды.

Гөлнур бикә. Элек әле шул кара урыс Мәскәүнең башыны идерергә кирәк.

Бер карт бикә. Башыны идерергә генә түгел, мәлгуньнең башыны кисәргә кирәк. Хан хәзрәтләре юкта ниләр кылындылар, бөтен тынычлыгымыз качкан иде: ай үтми – урыс баскыны.

Үлмәс бикә. Инде үзе дә сабагыны алды. Ник бер дә селкенми? Белёвта койрыгы бозга каттымы?

Бер бикә. Шулай, шулай.

Карауч ы хатын *(ишекне ачып).* Алтын бәк вәзирнең бикәсе Хәдичә бикә!

Хөршид *(каршы алып).* Рәхим итеңез, Хәдичә бикә, рәхим итеңез!

Хәдичә бикә *(бөтен кунакларга иелеп сәлам бирә).* Мөбарәк булсын мәҗлесләр, Хөршид бикә. Илемез, йортымыз шундый шатлыклы туйларда вакыт кичерсен! *(Уңга, сулга.)* Саулармысыңыз, арумысыңыз?

Бикәләр. Тәңрегә шөкер. Тәңрегә шөкер!

Хөршид. Түргә узыңыз, Хәдичә бикә!

Хәдичә. Йауас, йауас! *(Алга атлый. Тансык бикәгә.)* Тансык апа, Тәңрегә шөкер, нинди шатлыклы көннәргә ирештек. Беләмсең, синең берлә бергә бер урыс бас-кыныннан качып чирмеш авылында ничек яшәгән идек?

Тансык бикә. Шөкер Тәңрегә. Хан хәзрәтләре аларны оныттырды, Тәңре гомерен озын итсен, гаскәрләремезнең кылычыны үткен итсен.

Үлмәс бикә. Ул урыс баскыны көннәрен хәтерләсәм, хәзер дә йөрәгем шу итеп китә, бөтен тәнемнән суык су кебек бер суыклык йөгерә. Минем Сорур апамны беләсез, шул көннәрдә урыслардан качканда юлда баласын төшереп вафат итте, әле дә күз алдымда.

Алтын. Инде кайгы-хәсрәт урыс иленә булсын, без туй ясыйк, сөенечтә яшик.

Хатын-кыз ягыннан хәрәкәт килә, аяк тавышлары ишетелә.

Карауч ы хатын. Ханбикә килә, ханбикә!

Бөтен хатыннар аякка калка. Парча киемнәрдә, зур энҗеле калфакта,
каймалы читекләрдә Г ө л б и к ә ишектән керә.

Х ө р ш и д *(каршы килеп).* Бөтен кунаклар килделәр, әнкәй, рәхим итегез!

Г ө л б и к ә *(залның уртасына җиткәч туктап, әүвәле түргә, аннары уңга, сулга иелеп сәлам бирә).* Хуш килдегез, бикәләр! Саумысыз, сәламәтмесез, минем баламның туен зур итеп килүегезгә зур рәхмәт! Яңы илемездә бу – беренче туемыз. Белёв сугышында иң сөйгән киявемне югалтканнан бирле үзем көлсәм дә, күңелем сыкрый иде *(күзеннән яшьләрен сөртә),* бүген беренче мәртәбә күңелем дә сөенә, үзем дә сөенәм. Бергә-бергә туй иткән кебек, бергә-бергә илемез, йортымызда тыныч яшик, бикәләр, яр булыгыз! Тәңре озын гомер бирсен, шатлыклы көннәрне күбәйтсен һәммәмезгә, һәммәмезгә! *(Түргә утыра. Күршеләре берлә баш иеп сәламләшә, Хөршидкә.)* Киленбикә, бүләкләрне китерсеннәр!

Хөршид караучы хатыннарга ишарәт итә. Гөлбикә күрше хатыннары берлә акрын гына сөйләшә. Караучы хатыннар берсе артыннан берсе ике атлас букча күтәреп ханбикә алдындагы тәбәнәк өстәлгә куялар. Аның артыннан тау кадәр катырган, как берлә каплаган как-төшне[69] икенче өстәлгә куялар.

Г ө л б и к ә. Бикәләр, угылымыз Ягъкубка Казан бәкләреннән Мамай бәкнең кызы Гөлчәчәкне, угылымыз Йосыфка Казан бәкләреннән Апакай бәкнең кызы Маһинурны ярәштек. Яшьләргә Тәңре бәхетле гомер бирсен, дип бер дога кылыйк. Бүген Ягъкубның бүләген багамыз.

О с т а з б и к ә *(кулын күтәреп).* Яшьләргә Тәңре Йосыф-Зөләйха мәхәббәтен багышласын, бәхет-шатлык эчендә гомерләре үтеп, илгә, йортка файдалы балаларның ата-аналары булырга насыйп итсен!

Һәммә хатын кулын күтәрә, авызыннан[70] дога кылып:
«Аллаһы әкбәр!» Йөзләрен сыйпыйлар.

У р т а я ш ь л е к б е р х а т ы н *(бер букчаны ачып.)* Мамай мирзаның кызы Гөлчәчәкнең каенишләренә бүләге: каенатасы хан хәзрәтләренә ука берлә чигеп эшләгән бер букча эчендә алтынлы җилдле[71] бер Коръән. *(Хатын бүләкне кулына алып күрсәтә.)*

Бикәләр. Сансыз көннәр, исәпсез төннәр шул Коръән Шәрифнең хөкемнәрен йөртергә насыйп итсен!

Хатын *(бер бүләкне алып).* Каенанасы ханбикәгә камчат бүрек. *(Күрсәтә.)*

Бикәләр. Сөенә-сөенә озын еллар кияргә язсын!

Хатын. Каенагасы шаһзадә Мәхмүдкә алтын берлә, көмеш берлә эшләнгән бер ук букчасы. *(Күрсәтә.)*

Бикәләр. Дошманнарның котыны алырга, урыс явын җиде көнлек юлда тотарга язсын!

Хатын. Килендәше – олуг килен бикә – Хөршид бикәгә парчадан чуклы-сачаклы күлмәк. *(Күрсәтә.)*

Бикәләр. Яшьлеге, матурлыгы көн-төн артсын!

Хатын. Кайнигәче – хан хәзрәтләренең олуг кызы Алмас солтанга төрле җәнлекләр тиресеннән тегелгән ефәк тышлы тун. *(Күрсәтә.)*

Бикәләр. Авыру, кайгылары онытылсын, тормышы җылы, күңеле тыныч булсын!

Хатын. Каенсеңлесе Гөлсолтанга энҗе берлә эшләнгән калфак. *(Күрсәтә.)*

Бикәләр. Яз чәчәге кебек тормышы чәчәк атсын!

Хатын. Каененесе Йосыф шаһзадәгә чигелгән аяк чолгаулы читек-кәвеш. *(Күрсәтә.)*

Бикәләр. Үз туена кадәр сөя-сөя кисен!

Хатын *(икенче букчаны ача).* Бусы кияве Ягъкуб шаһзадәгә *(күрсәтә)*: чигелгән күлмәкләр, эшләгән аяк чолгаулары, көмеш берлә эшләнгән камзул, атлас бер җилән, алтын-көмешле, сәдәфле-ташлы кылыч кыны.

Бикәләр. Сөешә-сөенә озын яшәсеннәр!

Сөкүт.[72]

Гөлбикә. Миннән дә, баш киленем, кечкенә генә бер бүләк. *(Эшләнгән бер букча эченнән чыгарып, бер агач савытны ачып хатынга бирә.)*

Хатын. Энҗе муен асмасы, киемлек бер хәтфә.[73] *(Күрсәтә.)*

Хөршид бикә. Миннән дә шул бүләк. *(Эшләнгән бер савытны хатынга бирә.)*

Хатын *(ачып күрсәтеп).* Алмаслы[74] беләзек, бер парча[75] ефәк. Үлмәс солтаннан алмаслы алкалар. Күңел солтаннан алтын тәнкәле такыя.

Карт бер бикә. Бездән дә шул кечек бүләк. *(Бер парча ефәк өстәл өстенә куя.)*

Аның артыннан башкалар йөзекләр, беләзекләр, муен асмалары, сачтәнкә, хәситә, парчалар, ефәкләр бирәләр. Өстәл өсте бүләк берлә тула.

Карт бер хатын. Яңез бер дога кылыйк. Яшьләр көлә-көлә яшәсеннәр, якыннарын сөендерсеннәр, алтын төбе кебек балаларга ата-ана булсыннар!

Бикәләр. Амин!

Гөлбикә. Туемызны олуглап килүеңезгә һәммәңезгә бик зур рәхмәт!

Бер бикә. Сөенә-сөенә килдек, ханбикә.

Икенче бер бикә. Бу безнең өчен олуг бер сайгы,[76] зур бер хөрмәт.

Өченче бикә. Олуг ханымызның беренче туен күрү, туйда бергә булу һәммәмез өчен зур бер бәхет.

Гөлбикә. Рәхмәт, рәхмәт. Тәңре илне-көнне сау-сәламәт итсен!

Бикәләр. Амин, ханбикә!

Гөлбикә Хөршидкә ишарә итә. Ул да караучы хатыннарга куша. Бер хатын зур как-төшне кисәргә башлый, икенчеләре, өченчеләре шуларны, савытларга куеп, кунакларга өләшәләр. Ике хатын матур агач кәндиләрдә ширбәт тарата.

Гөлбикә. Рәхим итеңез, бикәләр!

Бикәләр как-төш ашарга, ширбәтләр эчәргә тотыналар. Бер-берсе берлә сөйләшәләр.

Бер бикә. Нугай иленнән илче килгән, хан хәзрәтләренә табуг салам дигәннәр, диләр, дөрестме?

Икенче бикә. Уралдан килгәннәрен ишеттем. Нугай иленнән килү-килмәүләрен белмим. Андагы башкортлар хан хәзрәтләренә табуг салганнар.

Ү л м ә с  б и к ә. Сура елгасы мукшыларыннан табуг саламга килгән мукшы илчеләрен үз күзем берлә күрдем. Ханлыкымыз, борынгы чакта бабаларымыз вакытындагы кебек, бөтен урыс илен баш идерәчәк.

Б е р н и ч ә  б и к ә. Амин!

Б е р с е. Авызыңа бал да май!

Т а н с ы к  б и к ә. Һәр йирдән хан хәзрәтләренең гас-кәрендә хезмәт итәр өчен меңәр-меңәр угланнар-егетләр Казанга агалар, хан хәзрәтләренең аяклары җиңел булды, шәһәргә халык сыймый башлады, бу гаскәр берлә Казан бөтен кардәш илләрне үзенә муен сындыра[77] алачак.

Ф а т ы й м а  б и к ә. Казанның зураюы, дәүләтләрнең көчәюе хан хәзрәтләренең кодрәтенең олыгаюыдыр, илемез-йортымызның бәхетедер.

Г ө л б и к ә. Без хатыннар дәүләт эшләрен белмимез. Хан хәзрәтенең, аның олуг вәзирләренең ни теләвен дә белмимез, әмма хан хәзрәтләре кардәш илләрен кылыч көче берлә алу ягында түгел. Туган илләр дустлык, кардәшлек берлә берләшсен, ди. Кардәшкә кардәш кылыч күтәргәч, дәүләтемез Сарай ханлыгы кебек булачак, моннан дошманнарымыз файдаланачак, ди. Күрше төрек илләренең теләкләре уртак, ул да Чыңгызның мирасы – Идел буе, Урал тауларының көчле берләшкән бер дәүләт булуы. Телемез – бер, динемез – бер, йоламыз – бер, дип бер-беремездән аерылмыйча, уртага дошман кермәсә, сөешә-сөенә берләшәчәкмез, көчләнәчәкмез.

Ф а т ы й м а  б и к ә. Ханбикәнең сүзләре бик тугры, арамызга дошман фетнәсе кермәсен.

Б и к ә л ә р. Шулай, шулай!

К а р т  б и к ә. Хан хәзрәтләре динемезнең хөкемнәрен, бабаларымыздан калган йолаларымызны нык тоттырса, эшләремез ал да гөл булачак. Яшьләрдә искедәге кебек олугларга хөрмәт, сайгы азайган. Киленнәр – каенаналарына, угланнар аталары, бабаларына падишаһка муен сынган кебек муен сынса, аларның сүзеннән чыкмаса, өемез нык булачак, һәрбер өй, һәрбер йорт берәр кала кебек булачак. Бәкләремез, мирзаларымыз,

сәедләремез, угланнарымыз хан хәзрәтләрен аталары кебек күрәчәкләр, ни дисә, аның фәрманына хәзер булачаклар. Безнең карт халык тугрылыкны күрсә, җанын фида итә, мин яшьләргә артык ирек бирүдән куркам.

Сылу бикә. Балаларымызны ата-анага, олугларымызга сайгы, хөрмәттә йитештерү, аларны ил сөяргә өйрәтү – без аналарның бурычлары, без барымыз да моны эшли алсак, дәүләт тә, ил дә үзеннән-үзе ныгыячак, куәтләнәчәк.

Бикәләр. Тугры! Тугры!

Шул арада хатын-кыз ягыннан бер төркем музыкачы, җырчы хатыннар, кызлар чыгалар. Ишек янына басып, бик иелеп сәлам бирәләр. Музыкачылар курайдан, думбрадан, кәманнан, скрипка, балалайкадан уйнарга тотыналар. Озын бер көй уйныйлар, башкалары аларга җыр берлә кушыла. Бикәләр бик ихлас берлә тыңлый-тыңлый ашыйлар, эчәләр. Бер көй бетә, туктыйлар.

Бер бикә. Яшәңез! Яшь вакытларымны хәтерләттеңез.

Икенче бикә. Тавышлары бик матур.

Музыка тагы уйный, тагы хор берлә кызлар катыша. Бикәләр бик ихлас берлә тыңлыйлар. Тагы музыка туктый.

Бер бикә. Мин бу көйне беренче ишетәм.

Икенче бикә. Барымыз да шулайдыр.

Хөршид. Бу Сарайдан килгән көй.

Бикәләр. Бик моң, бик матур көй.

Гөлбикә. Кунакларның хушына китте, тагы берәр көй җырлаңыз. Уенсыз, җырсыз туй ул бит майсыз ботка кебек була.

Бикәләр. Дөрес, дөрес!

Музыкачылар җиңел бер көй уйныйлар, кызлар җырлыйлар. Хезмәтче хатыннар бикәләргә ширбәтләр тараталар, как-төшләр китерәләр. Хөршид ишарәт итә. Музыкачылар бию көен уйныйлар. Берничә кыз каршы-каршыга биергә тотыналар, башкалары бию җырларын җырлыйлар (мәсәлән, «Әпипә»). Мәҗлес җанлана.

Бикәләр *(биючеләр туктагач)*. Яшәңез, яр улыңыз!

Икенче бию көе уйнала (мәсәлән, «Баламишкин»), тагы биюләр, тагы җырлаулар. Кунак хатыннар һәрбер көйдән соң: «Яшәңез!» – дип

кычкыралар. Бер өченче бию көеннән соң Гөлбикә уенчылар, биючеләргә алтын акчалар сибә, аның артыннан Хөршид сибә, аның артыннан кунакларның күбесе көмеш акчалар сибәләр. Идән алтынлы-көмешле акча берлә тула, ләкин беркем дә аны җыймый. Соңыннан музыкачылар бер көй уйный.

Х о р: Ничек килдеңез сез безгә, батмаенча диңгезгә,

Сый-хөрмәт күрсәтә алмадык, гаеп итмәңез
сез безгә.

Бик иелеп сәлам бирәләр. Чыгалар.

Б е р к а р т б и к ә. Рәхмәт, ханбикә, безгә әбиләремез хикәя итеп сөйли торган борынгы ханнарымызның туй бәйрәмнәрен ясаттыңыз, яр булыңыз!

Г ө л б и к ә. Туй бит яшьләрнең гомерендә бер генә була, без барымыз да моны үткәрдек. Ил-көн тынычлансын да һәммәмез бала-чагасының туен күрергә насыйп булсын.

Б е р б и к ә. Тәңре кушса, шулай булыр!

Б е р к а р т б и к ә. Ханбикә, безне санга санап зур мәҗлесеңезгә чакыруыңызга мең-мең рәхмәт, инде безгә рөхсәт биреңез. *(Аякка калкырга тели.)*

Г ө л б и к ә *(аякка калка, барысы да торалар).* Барыңызга да бик зур рәхмәт. Беләсез бит, әле яңы йирләшәмез, зур мәҗлес ясый алмадык, бик күп яшь бикәләрне чакыра алмадык, безне кичерсеннәр, һәммәсенә бездән сәламнәр сөйләңез!

Х а т ы н н а р иелеп-иелеп сәлам биреп чыгалар. Хөршид бикә ишек төбенә кадәр барысын да озата. Залда ханбикә, Хөршид бикә, Сарай хатыннары гына калалар.

Г ө л б и к ә. Уенчы кызлар акчаларны җыйсыннар!

Б е р н и ч ә я ш ь к ы з кереп идәннән алтыннар, көмешләрне җыялар.

*(Гөлбикә караучыларга.)* Мәҗлесне бик яхшы алып бардыңыз, барыңызга да рәхмәт! *(Алтыннар тарата. Хөршидкә.)* Казандагы бер мәҗлесемез бик матур үтте түгелме?

Х ө р ш и д. Сез ничек таныдыңыз,[78] әнкәй?

Гөлбикә. Мин бик сөендем. Барыңызга да рәхмәт!

Ханбикә чыга.

Хөршид бикә *(караучыларга).* Тиз җыештырыңыз, эткәйләрнең эшефәләне булыр.

Үзе чыга, хатыннар өйне җыештыралар.

Бер карауч ы хатын. Бу бүләкләрнең йөздән берсе миңа булса, бояр кебек гомер сөрер идем.

Икенче карауч ы. Язмыш һәркемгә үз өлешен аерып-аерып биргән. Агачларның берсе тәмле алма бирә, берсе әче алма, берсе балан бирә, берсе әкәлә генә бирә. Адәм баласын да Тәңре шулай аерып яраткан. Берсе ханбикә, берсе мирзабикә, берсе безнең кебек кара халык. Тамагың тук, өстең-башың бөтен, тагы ни телисең?

Беренче карауч ы. Тәңрегә шөкер. Бу бикәләрнең өсләрендәге киемнәр, таккан зиннәтләрнең бәясе (бәһасе) безнең авылның бөтен йортыйире, малы-туары, каралтысыннан артык. Тәңре ник адәм баласын тигез яратмаган?

Икенче карауч ы хатын. Бармакларыңа кара, ник берсе дә тигез түгел? Урманга кара: берсе нарат – өй салалар, берсе каен – урындык, утыргыч ясыйлар, берсе имән – күпер сугалар, берсе усак – мичкә ягалар. Без дә адәм баласының усагы.

Картрак өченче карауч ы. Бик күп сөйлисез, эшеңезне караңыз. Шөкер итеңез, ханбикә дә, киленбикә дә, солтаннар да һәммәмезгә кеше итеп карыйлар, бу безнең бәхетемез. Нинди-нинди тиле, тәкәббер бикәләр була. Тәңре күрсәтмәсен.

Икенче. Болар бик зур авырлыклар күргәннәр дә күңелләре йомшаган.

Беренче карауч ы. Нидән булса булсын, алтын күңелле кешеләр. Зур шаһзадә Мәхмүд кенә каты йөрәкле.

Икенче. Кешеләр һәммәсе бер төсле булмый шул.

Җыештырып бетерәләр, кирәксез нәрсәләрне алып чыгалар. Сәхнә буш кала.

Бераздан йорт ягыннан аяк тавышы ишетелә. Ишектән Мирза Гали керә. Кулында язу букчасы.

Мирза Гали *(тәбәнәк бер өстәл янына утыра, кәгазьләрен тарата).* Боларның барысына да җавап язарга кирәк. Өлгереп кенә җит. Халык безне, сарай хезмәтендә булынганнарны, бал-май эчендә генә йөзә дип уйлый, төннәр йокламаенча язганнарны һич исәпкә алмый. Хан хәзрәтләре килгәнче эшләремне бераз юлга куйсам. *(Язарга тотына, камыш каләм шыгырдавыннан башка тавыш юк. Бераздан.)* Берсе бетте. *(Тагын яза, тагын тынлык. Бераздан.)* Тагын берсе бетте. *(Тагын яза, тагын каләм тавышыннан башка бер тавыш та юк.)* Тагын берсе бетте. *(Тагын язарга тотына).*

Йорт ягыннан аяк тавышлары килә. Ишек ачыла. Олуг Мөхәммәд керә. Мирза Гали сикереп торып сәлам тора. Олуг Мөхәммәд язучының янына килә.

Олуг Мөхәммәд. Бу ни бу бик күп кәгазьләр, мирза?

Мирза Гали. Хан хәзрәтләре, кайсылары ханлыкны котлау, кайсылары бәйгать бирү кәгазьләре, һәммә-сенә җавап языңыз, дип боердыңыз, шуларга җавап язам.

Олуг Мөхәммәд. Болар бик күп икән, йитешә аламсың соң?

Мирза Гали. Илемезнең бөтен почмагыннан кот-лау-лар килә, бөтен ил сөенеч эчендә, хан хәзрәтләре.

Олуг Мөхәммәд. Сөенеч эчендә, диең! Безне, падишаһ балаларын, бөтен ил, бөтен халык безнең өчен үләргә хәзер дип тәрбия итәләр, һәрбер кылган эшемезне халык сөенеп каршы алды, диләр. Мин җанымны, балам-чагамны коткарыр өчен Сарай шәһәреннән качканда халыкның ничек сөенеч эчендә булуын үз күзем берлә күрдем. Көчең, куәтең булса, халык баш ия, эшләреңә ялганнан сөенеч күрсәтә, аз гына төштеңме, сине мәсхәрә итү аңа берни тормый.

Мирза Гали. Кара халык – кара сарык, диләр. Бу – дөрес. Ләкин, хан хәзрәтләре, Сарай берлә Казан арасында аерма бик зур. Монда халык, хан хәзрәтләре, сезне урыс баскынынннан, урыс явыннан коткаручы батыр дип

карый, сезнең аркада үзенең мал-туарын, йорт-йирен сәламәтлектә дип карый, шуңарга сөенә, чын күңеленнән сөенә, хан хәзрәтләре!

Олуг Мөхәммәд. Башка сәбәбе юкмы?

Мирза Гали. Үзенең ханлыгы корылуына, үз иленә үзе баш булуына сөенә.

Олуг Мөхәммәд. Моны аңларлык гакылы, уе бармы?

Мирза Гали. Гакыл берлә түгел, күңеле берлә, йөрәк берлә аңлый, хан хәзрәтләре!

Олуг Мөхәммәд. Бу – күңелле эш, бераз көтик, синең эшең бик күп. Мирза, үзеңә бер ярдәмче ал.

Мирза Гали. Хан хәзрәтләре, миңа зур бер ышаныч берлә мине шул эшләргә баш иттеңез, минем кулымнан котлау бөтиләренә җавап кына түгел, дәүләтнең бөтен язулары кичә, болар арасында дәүләтнең серләре дә була. Ярдәмчем үзенең ил бурычын, сезнең алдындагы бурычын аңлый алса ярый ла, югыйсә... Мин көн җитмәсә, төн язам.

Олуг Мөхәммәд. Сүзең тугры, мирза, әмма арырсың, кечкенә кәгазьләрне яза торган берсен ал. Сынарсың, тугры кеше чыкса, ышанычыңны киңәйтерсең, дөрес адәм чыкмаса, башкасын алырсың, беләсең, илемез зур, эшемез күп.

Мирза Гали. Боерык сезнең, хан хәзрәтләре, ул чакта мин таныдык-белдекләремнән берсен алыйм.

Олуг Мөхәммәд. Ал, ал, вәзирләр килсә, миңа хәбәр бир! *(Хан хатын-кыз ягына чыга.)*

Мирза Гали һаман яза. Тынлык. Бераздан йорт тарафы ишегеннән баш вәзир Тимер командан керә. Мирза Гали сикереп торып сәлам бирә.

Тимер. Синең бу котлауларың һаман бетмәдеме, мирза Гали?

Мирза Гали. Яңыдан-яңысы килеп тора.

Тимер. Мин аңламадым моны. Безне үз илемез Сарайдан кудылар. Сарай үзенең олугларына хезмәт иткән үз ханын – чын Чыңгыз баласын куды, монда, чит илдә безне сөя-сөя каршылыйлар, безне котлыйлар. Моның

мәгънәсе нәрсә? Мин аңламадым. Син халык берлә катнашасың, бу – нәрсә бу, бу бер хәйлә генә түгелме? Мин бераз шөбһәләнәм.

Мирза Гали. Халык алдында булган нигъмәтнең кадерен белми, аны югалттымы – кайгырырга тотына. Сарай да сезнең кадерегезне белмәде. Мондагы халык башсызлыктан җәфа чиккәнгә, урыс явыннан җаны өшегәнгә, хан хәзрәтләренең килүен шул башбаштаклыктан, шул баскыннан котылдым дип бәйрәм итеп каршы алды, сөенде, хәйлә-фәлән юк, эчтән килгән бер ышаныч бар. Тагы мондагы халык – бездән бик күп йөз еллар элек үзенең дәүләтен корган, уку-язу белгән, динен-дөньясын юлга салган бер халык. Алар аны югалтканнар, хәзер шул дәүләтне яңыдан кордык дип уйлыйлар, алар тапты да.

Тимер. Безне моннан кумаячакланрмы?

Мирза Гали. Эшегез, кылганыгызга карар. Хан хәзрәтләрен халык чын күңеленнән сөя, аны коткаручы дип карый. Вәзирләр, түрәләр дә тугрылыкта булса, Казан ханлыгы Сарайдан куәтле булачак, халык берлә хөкүмәт арасында берлек булачак.

Тимер. Син – китап өстендәге кеше, күп укыган, күп укыганны күргән. Бу берлекне ничек ясыйк, сөйлә! Мине хан хәзрәтләре баш вәзир ясады. Мин дәүләт эшләрен белмим, мин – гаскәр, мин сугыша гына беләм. Минем белмәвемнән шундый яхшы ният берлә башланган Казан ханлыгы да Сарай ханлыгы кебек дуст-дошман арасында мәсхәрә булмасын дип куркам, кай төннәрне шуны уйлый-уйлый күземә йокы керми.

Мирза Гали. Димәк, команданым, сездә яхшы, тугры булуга ният бар, Алладан курку, бәндәдән оялу бар, гакылыгыз да йирендә. Тәңренең ярдәме берлә сез илне яхшы башкара беләчәксез. Эш башында булган адәмгә һәрнәрсәне үзем беләм дигән уйда булырга гына ярамый. Чыңгыз хан һәрбер эшне бүлеп-бүлеп остасына тапшыра торган булган, сез дә шулай итегез. Яныгызга тугры түрәләр алыгыз. Адәм хатасыз булмый, эшегезне яратмасалар, ачуланмагыз, үземнән яңлышлык булды, күрәсең, дип яңлышны эзләгез. Тар күңелле булмагыз!

Тимер. Тугры сөйлисең, хаталарымны күрсәң, миңа ачык сөйлә!

Мирза Гали. Фәрман сезнең, команданым!

Ишектән эчке эшләр вәзире Галим бәк килеп керә, аның артыннан Алтын бәк керә. Мирза Гали икесенә дә аякка калкып сәлам бирә.

Хан хәзрәтләре «вәзирләр килгәч миңа хәбәр бир» дигән иде, мин хәбәр бирим.

Тимер. Бераз тор әле. Без бераз үзара сөйләшик.

Мирза Гали утыра, үзенең язуына башлый.

Вәзирләр, эшләр ничек бара?

Галим бәк. Бүген хан хәзрәтләре шул хакта сөйләшергә чакырды түгелме?

Тимер. Анысы шулай. Беләсез, мин читтән килгән кеше, моңынча гаскәрлектән башка бер эш кылмадым. Халкым алдында, хан хәзрәтләре алдында йөгем авыр, берәр төрле яңлышлык эшләмим, дим.

Алтын бәк. Бу яңлышлык ясаудан курку, команданым, үзе сезне аеры адымнар атлаудан тыеп калачак. Барымызның да йөгемез зур, бер-беремезгә ярдәмләшлектә ул йөкне күтәрә аламыз.

Тимер. Мин сугыш эчендә үстем, сугыш эчендә зурайдым. Сугыш та бәхет эше, әмма аның да гыйлеме бар, ул яктан, үземне мактау булмасын, беләм дип уйлыйм. Мәмләкәт эшен карауда мин сезнең барыңызның да сүзеңезгә, гакылыңызга ышанам.

Галим бәк. Ачык сөйләвеңез арамыздагы пәрдәләрне ертты, мине дә ачык сөйләргә куша. Без – Болгар ханнарының балалары, бәкләре, мирзалары, түрәләре – бу илдә мең елдан артык падишаһлык сөрдек. Ислам динен кабул итеп, ислам дөньясы эченә керүемезгә дә биш йөз ел көннән үтте. Дәүләт коруның, дәүләт эшен йөртүнең юлларын беләмез. Дөнья сату-алуының олуг юлы безнең мәмләкәттән үткәнгә, анда да тәҗрибәмез бар. Халкымыз укыган, белгәнемез күп, тупрагымыз бәрәкәтле, шәһәрләремез бай, су юлларымыз күп. Ләкин соңгы йөз елларда без үз байлыгымызны, үз илемезне сакларлык гаскәр башлыклары җитештерә алмыймыз. Ник? Моның

сәбәбен мин бик күп уйладым, таба алмадым. Бәлки, сатучы халык моны эшли алмый торгандыр. Күрше дошманымыз урыс та көннән-көн зурайды, дуңгыз кебек балалады, артты, күзе ач, килде, илемезне, шәһәрләремезне баскын итте, малымыз-туарымызны гына түгел, кызларымызны, егетләремезне үзе берлә алып китте. Халык җончыды, без аптырадык. Хан хәзрәтләре берлә сез килгәч, без сезне илемезне, йортымызны дошманнан саклаучы, безне коткаручы дип сөенә-сөенә каршыладык, сез гаскәремезне җитештерсәңез, илемезне урыс дошманнан саклый алсаңыз, ил эшләре үзеннән-үзе яхшы китәчәк, безнең бер-беремезгә ярдәмләшүемез шунда булачак.

Т и м е р. Бу эштә бөтен гакылымны, бөтен белемемне илемә, халкыма бирү минем өчен бер бәхет, ул яктан икеләнү булмасын!

Г а л и м б ә к. Илне башкаруда да без дә кулымыздан килгәнне кызганмаячакмыз, ул яктан да икеләнү булмасын!

Т и м е р. Алай булгач минем күңелем тынычланды.

С ә е д Җ ә л и л керә. Һәммәсе берлә сәламләшә.

М и р з а Г а л и. Хан хәзрәткә хәбәр биримме?

Т и м е р. Бир, бир!

М и р з а Г а л и *(хатын-кыз ягындагы ишекне кага. Ишекне ачкан караучы хатынга).* Хан хәзрәтләренә сөйләңез, вәзирләр һәммәсе килделәр.

Т и м е р. Нихәл, сәед хәзрәтләре, эшләр ничек бара?

С ә е д Җ ә л и л. Мондагы халык безнең Сарай халкыннан тагы динлерәк, Алладан курку, олугларга хөрмәт монда тагы көчле, уку, язу белү, китап. Коръән уку тагы күбрәк. Ләкин монда мөселманнар берлә мәҗүсиләр бергә яшиләр, уртак эш итәләр, бергә сату-алу итәләр, бергә иген чәчәләр, үзара дуст булалар. Мин моны яратмадым, мәҗүси – безнең китапларда нәҗестер.[79]

Ишектән х а н чыга. Барысы да аякка калкалар.

Х а н. Көн яхшы!

В ә з и р л ә р. Көн яхшы, падишаһым!

О л у г  М ө х ә м м ә д *(түргә чыгып утыра. Вәзирләргә дә).* Утырыңыз! *(Алар да йирле-йиренә утыралар.)* Ил эшләре ничек бара дип сорашырга, сөйләшергә сезне чакырдым. Ил тынычмы?

В ә з и р л ә р. Һәрьяктан тыныч!

О л у г  М ө х ә м м ә д *(Галим бәккә).* Сез эшләреңезне ничек башкардыңыз?

Г а л и м  б ә к. Әүвәл вәзирләр мәҗлесендә сүз беректергәнчә, ил эчендәге бөтен түрәләргә йирләреннән аерылмаулары, моңынча булган кебек эшләрен алып барулары хакында боерыгыны сезнең исемнән ат чаптырып белдерттем. Халыкны, бу яңалыкны ничек каршы алуларын өйрәнер өчен, халыкның теләген белсен өчен кай йирләргә ачык, кайбер йирләргә яшерен түрәләр күндердем. Күп улыстан хәбәрләр дә килде. Халкымыз хан хәзрәтләренең Казанда тәхеткә чыгуын, Казан шәһәренең баш кала булуын бик яхшы каршылаганнар. Урал буе башкортларының аксакаллары табуг салам күндергәннәр. Төрле чуваш, чирмеш, мукшылар кабиләләреннән дә бәйгатьләр килде. Мәмләкәтнең һичбер йирендә каршылык юк, шуңарга, хан хәзрәтләре, яңы дәүләтнең корылышы уңышлы бара дип уйлыйм. Инде бүгенге мәҗлестә шул йирдә булган түрәләрне, кайбер йирләргә яңы түрәләрне билгеләү хакында ярлык чыгарырга кирәк дип уйлыйм.

О л у г  М ө х ә м м ә д. Беттеме?

Г а л и м  б ә к. Әлеге шулкадәр.

О л у г  М ө х ә м м ә д *(Алтын бәккә).* Сезнең эшләр ничек?

А л т ы н  б ә к. Әүвәлге мәҗлесемездә боердыгыңыз кебек, күрше илләргә, Нугай йортына, Себер улысына, Кырымга, Сарайга, Чыгтай иленә, Госманлы угылларына, Иранга, Ләһстанга Казан ханлыгы корылуы вә сезнең олуг хан булып Казан тәхетенә чыгуыңызны белдереп бөтиләр яздым. Нугай иленнән, Себердән җаваплар алдым, икесе дә илемезгә, ханымызга дустлык сәламнәрен күндерәләр, ерак илләрдән әле хәбәр ала алмадык. Сарайдан яшерен рәвештә алынган хәбәрләргә караганда, анда бу вакыйга төрле-төрле уйлар уятуын белдерәләр. Халык хан хәзрәтләренең Сарайдан китүенә

кайгыда икән. Бәкләр, мирзалар ике-өчкә аерылып бер-берсе белән җәнҗал итәләр икән. Бер өлеше Казанга гаскәр җибәрүне уйлыйлар, бертөрлесе хан хәзрәтләрен Сарайга яңыдан чакыруны төшенәдер икән. Урыс иленнән килгән яшерен хәбәрләргә күрә, анда зур курку баскан. Василийның дошман кенәзләре Казанга килеп хан хәзрәтләреннән Мәскәү олуг кенәзлегенә ярлык алырга уйлыйлар икән, әмма поплар, халыкны димләп, татарга баш имимез, дип үгетләп яталар икән. Минем уемча, хан хәзрәтләре, күрше мөселман илләренә дустлык, кардәшлек тойгыларымызны белдереп илчеләр күндерергә хәзерләнергә кирәк. Хәзергә шулкадәр.

Олуг Мөхәммәд *(сәед Җәлилгә).* Сезнең эшләр ничек?

Сәед Җәлил. Хан хәзрәтләре, монда дин эшләре Сарайдан яхшы корылган. Шәһәрләрдә генә түгел, авылларда да мәсҗедләр бар, имамнары бар, күп йирдә мәдрәсә бар. Халык уку-язуга өйрәнгән. Гыйлемнең, белемнең хөрмәте, сые зур. Халык динле, бозыклык бик аз. Мин зуррак шәһәрләрдә берәр мөфти билгеләүне кирәкле табам. Казанның үзендә мәдрәсәләр булса да, алар дин әһелен җиткерерлек үк түгел, аларны зурайтырга, яңы мөдәррисләр куярга кирәк дип уйлыйм, бу хосуста вәзирләрнең уена, сезнең боерыгыңызга мохтаҗмын.

Олуг Мөхәммәд. Бу эшләр сезнең белә торган эшләр, минем тарафымнан тоткарлык юк, вәзирләр ни фикердәдер, белмим. Ялгыз[80] бу мәдрәсәләрне алып барыр-га җитәрлек вәкыфлар бармы?

Сәед Җәлил. Вәкыфлар бар, ләкин аларның килерләре генә җитешми, шуларга бу эштә хәзинәдән ярдәм көтәм.

Олуг Мөхәммәд *(вәзирләргә).* Сез бу хосуста ни фикердә?

Галим бәк. Хан хәзрәтләре, хәзинәмезнең килеренең зур өлеше тамгадан[81] иде. Соң елларда урыс баскыны Идел юлының тынычлыгын боздылар. Иран, Кавказ иле, Чыгтай иленең сатучы-алучысының килүе-китүе бик сирәкләнде вә шуңарга тамга килеремез дә азайды. Язга таба су ташуларыннан соң су юлларымызны сакларга аерым көчләр куярга вә Идел юлының тынычлыгын яңадан кайтарырга кирәк булыр.

Т и м е р. Казанның көймәләре бармы?

Г а л и м б ә к. Дәүләтнең көймәләре юк түгел, ләкин күбесе сату-алу көймәләре, шуларны сакларлык гаскәр ташый торган көймәләремез, өйрәтелгән гаскәрләремез юк. Хәзинәмезнең килүе тар булса да, дин эшемез бөтен халкымызның эше булганга, сәед Җәлил хәзрәтләренең эшләренә ярдәмне бирүне мин тиешле табам.

О л у г М ө х ә м м ә д. Сезгә күпме акча кирәк булыр?

С ә е д Җ ә л и л. Хан хәзрәтләре, әле хисабын ясата алмадым, бер сөйләшеп үтик дидем, сез мөнасиб күргәч, хисабын чыгартырмын.

О л у г М ө х ә м м ә д. Мәдрәсәләрне зурайт, укуларын киңәйт, дәүләт хәзинәсеннән каршылыгын бирермез. Беттеме?

С ә е д Җ ә л и л. Хан хәзрәтләре, монда без, дин әһел-ләре, яңы бер хәл берлә каршылаштык. Халкымыз арасында мәҗүсиләр яши һәм дә бер-берсенә катышып яши. Ислам дине безгә әмре мәгъруф вә нәһи мөнкәрне[82] әмер итә, без боларның каранлыкта[83] яшәүләренә разый була алмыймыз. Боларны мөселман итәргә ярлык чыга--рыңыз!

Г а л и м б ә к. Сәед хәзрәтләре, бу мәҗүси дигәннәрең шул безнең чувашлар, чирмешләр, арлар, мукшылар – алар бу илнең балалары, безнең бабаларымызга буен сынып килгәннәр, хан хәзрәтләренә табуг салдылар, салым түлиләр, олау чабалар, гаскәр бирәләр. Ничек без боларның диннәренә карышыйк?

С ә е д. Без, әлхәмдүлиллаһ, мөселманнармыз, болар мәҗүси, болар нәҗес, боларның суйган итене безгә ашау хәрам. Халкымыз алар берлә катышып йөри, моны дин кабул итми. Тагы боларның диннәре башка булгач, урыс явы килгәндә болар урыс ягына да чыга алалар, боларны мөселман ясасак, динемез, телемез бер була да кала, халык үзеннән-үзе берләшә.

О л у г М ө х ә м м ә д. Сәед хәзрәтләренең фикерләре тугры, ләкин көчләп үз динеңә кертү Чыңгыз ханның ясасына[84] каршы. Чыңгыз һәрбер дингә, һәрбер дин әһеленә каршы хөрмәт итәргә боерган. Безнең шәригатемездә дә

көчләп дингә кертү тугры булмаса кирәк. Тагы мин боларның табуг салуларын кабул иттем, үз йолалары, үз диннәрендә торуларына ирек бирдем. Ул сүзне бүген бозсам, хан сүзенең бәясе ни калыр?

Сәед. Хан хәзрәтләре, сүзеңез тугры, ханнар кием алыштырган кебек сүзен алыштырса, үзенең дә, сүзенең дә хөрмәте кача. Коръәндә «Ля икраһа фиддин» диелгән диюен, «Көчләп дингә кертмәңез» дигән сүз. Ләкин минем бу эштә күңелем тыныч түгел, ни булса да боларга каршы бер тәдбир[85] кертергә кирәк.

Алтын бәк. Бер вакытлар без барымыз да мәҗүси булганмыз, безне димләп, ислам диненең артыклыгын аңлатып, безне мөселман ясаганнар, сез дә, сәед хәзрәтләре, дин хезмәтчеләре, аларга ислам динен аңлатыңыз, димләңез, үзләре теләп мөселман булсыннар. Әмма хан хәзрәтләренең ярлыгы берлә көчләп мөселман ясау хәзер генә корылып килә торган дәүләткә зур комачаулык тудырыр, урысларның аларның араларына керүенә сәбәп булыр.

Олуг Мөхәммәд. Алтын бәкнең сүзләре тугры. Сез димләп мөселман ясарга тырышыңыз, ятим балаларны тәрбиягә алыңыз, үз араларыннан дин галимнәре җитештереңез!

Сәед. Тырышып карыйк!

Олуг Мөхәммәд *(Тимергә)*. Сезнең эшләр ни хәлдә?

Тимер. Хан хәзрәтләре! Илнең бөтен почмагыннан, хан хәзрәтенең байрагы астында гаскәр булам дип, бәкләр, мирзаларның угланнары, халыкның батыр егетләре су кебек Казанга ага. Шуларны йирләштереп бетерерлек йиремез юк, коралымыз җитми, боларны гаскәрлеккә өйрәтерлек йөз башларымыз җитешсезлек итә. Барысы да, урыс берлә сугышырга килдем, дип җавап бирә. Халыктагы гаскәрлеккә бу омтылышны мин гомеремдә беренче мәртәбә күрәм. Дөресен сөйлим, хан хәзрәтләре, мин бу эштән бераз өркә башладым. Беләсез, гаскәрне буш калдыру – гаскәрне башбаштаклыкка өйрәтү дигән сүздер. Боларны нишлик?

О л у г  М ө х ә м м ә д *(көлә).* Бу, командан, сөенеләчәк эш. Ник без куркыйк, дошманнар курыксыннар. Синең бу хакта фикерең ни?

Т и м е р. Шәһәрләремезнең кечкенәлеге-зурлыгына карап, төмән башы, мең башы, йөз башы кебек гаскәр башлыкларының әмерендә, гаскәрне илемезгә таратыйк, урыс чигенә. Иделнең кичү йирләренә калалар корып, анда төмәннәр йирләштерик.

Ш а һ з а д ә  М ә х м ү д ишектән күренә.

О л у г  М ө х ә м м ә д. Мәхмүд, кил, кил, синең сүзлә-рең сөйләнә.

Мәхмүд сәлам биреп, яннарына утыра.

Г а л и м  б ә к. Командан хәзрәтләре, хәзер никадәр гаскәремез бар?

Т и м е р. Утыз мең, ике атнадан илле меңгә дә чыгуы бик якын, егетләр су кебек ага.

Г а л и м. Боларны ничек туйдырырмыз, ничек киендерермез, бу гаскәрләрне чикләргә ярамыймы?

Т и м е р. Юк, юк, халык агымына каршы булырга ярамый, без аны Сарайда күрдек. Ул качак гаскәр тудыра. Аннары мәмләкәт эчендә юлбасарлык киңәя, тынычлык бетә.

М ә х м ү д. Миңа да бер сүзгә рөхсәт бирсәңез?

О л у г  М ө х ә м м ә д. Сөйлә, сөйлә.

М ә х м ү д. Без бу гаскәрләр берлә урыс иленә салдырыйк, гаскәрләргә эш булыр. Кием-салым, мал-туар китерермез, илгә байлык булыр, Василийдан үчемезне алырмыз, уңышлы чыкса, Мәскәүне дә даньга бәйләп, Алтын Урданы монда – Казанда корган булырмыз.

О л у г  М ө х ә м м ә д. Бу уйга ни дисез?

А л т ы н  б ә к. Хан хәзрәтләре, шаһзадә хәзрәтләре туг-ры уйлый, ләкин дәүләтне яңы корамыз бит әле, ныгып беткәнемез юк, сугыш уңышлы бетсә ярый да, уңышсыз чыкса, бөтен илемез, яңы дәүләтемез, хан хәзрәтләре, һәммәмез хәтәрдә. Илемез берничә вакытлар тыныч яшәсен, дәүләтемез ныгысын. Аннан соң урыска хәзерлек берлә салдырыйк! Хәзер Тимер

командан сөйләгәнчә, чикләремездә калалар корып, илемезне саклау өчен гаскәрне йирләре йиренә йирләштерик!

М ә х м ү д. Безнең хәзерлегемезне көтмәенчә Василий баскын итсә?

А л т ы н  б ә к. Ул вакыт, әлбәттә, сугышырмыз, илемезне саклау – барымызның да бурычы, сугышның башлаучысы ул вакыт без булмамыз.

О л у г  М ө х ә м м ә д. Тугры. Әле гаскәрнең коралын тутырырга, калалар корырга кирәк, хәзер булгач, теләгән чакта урыс иленә баскын итә алырмыз.

Т и м е р. Миңа ни боерык, хан хәзрәтләре?

О л у г  М ө х ә м м ә д. Гаскәрләрне син дигәнчә Казаннан озаклаштыру,[86] яңа калалар кору, урыс чигендә зур куәт тоту!

М ә х м ү д. Мине шул урыс иле чикләренең гаскәренең башы ясаңыз!

О л у г  М ө х ә м м ә д. Моны без Тимер командан берлә бергә сөйләшеп сүз беркетермез. *(Мирза Галигә.)* Башка эшләр бармы?

М и р з а  Г а л и. Юк, хан хәзрәтләре!

О л у г  М ө х ә м м ә д *(вәзирләргә).* Башка сүзләреңез бармы?

В ә з и р л ә р. Юк.

Г а л и м  б ә к. Алай булгач, илнең төрле йирләренә куелачак түрәләрнең исемнәрен билгеләү кала, моны вәзирләр мәҗлесе эшләмиме?

О л у г  М ө х ә м м ә д. Мәмләкәт эчендәге эшләргә сезне вәзир иттек, сез үзеңез хәзерләңез, мин ярлыкка кул куярым, мөһер басарым. Шуның берлә тәмам.

Б а р ы  д а  к а л к а. Чыгарга торганда у г л а н кереп
сәлам бирә.

У г л а н. Хан хәзрәтләре, чуваш иленнән атчабар килгән, аксакалларның бөтисен[87] китергән. Урыс явы чуваш йортына баскын итә икән!

О л у г  М ө х ә м м ә д. Утырышыңыз әле! *(Угланга.)* Атчабар керсен!

М ә х м ү д. Василий тыныч торамы соң?! Еланның башын измәенчә, аннан котылып буламы?

Ч у в а ш  а т ч а б а р ы *(керә, бик иелеп сәлам биреп.)* Мине аксакалларымыз җибәрде, хан хәзрәтләренә белдер, диде. Безнең илгә урыс явы керде. Урман

асты авылын басты, мал-туарны талады, ирләр, хатыннарны әсир алды. Түбән Кичү авылы каршы торды, авылга ут салды, бөтен авыл янды, халыкның кача белгәне урманга качты. Песәй авылының Пичә батыры янына тирә-юньнең егетләре тупланып, урыс явы берлә сугышка кереште. Урыслар күп, кораллары яңы, безнекеләр аз, кораллары – кылыч берлә балта. Аксакалларымыз хан хәзрәткә шуны белдерергә, көч бирүен сорарга кушты. Ике көн, ике төн йокы йокламадым, дүрт ат алыштырдым, көчкә Казанга килеп җиттем. Бөтен чуваш иле хан хәзрәттән ярдәм үтенә. *(Бик иелеп сәлам бирә.)*

Олуг Мөхәммәд. Урыс явы җәяүлеме, атлымы?

Чуваш. Күбесе җәяүле, атлылары да бар.

Олуг Мөхәммәд. Урыслар күпме, йөзләпме, меңләпме ир-ат?

Чуваш. Мин күрмәдем, аксакаллар, яу зур, меңнән артык урыс бар, диделәр.

Олуг Мөхәммәд. Пичә батырның никадәр кешесе бар?

Чуваш. Йөз-йөз илле кеше берлә каршы чыкты. Юлда үткән чуваш авылларының аксакалларына сөйләдем, алар да егетләр җибәрергә булдылар.

Олуг Мөхәммәд. Башка сүзең бармы?

Чуваш. Аксакаллар тизлек берлә ярдәм сорадылар, хан хәзрәтләре!

Олуг Мөхәммәд. Урыс яулары талаган йирләргә тугры юлны беләсеңме?

Чуваш. Урман астына ике юл бар, берсе Даруга юлы – олуг юл, берсе Урман арасы юлы. Чанага Урман арасы юлы авыр булыр, ат атланганга ул юл тагы кыска.

Олуг Мөхәммәд. Беттеме?

Чуваш. Миңа аксакаллар, җавап ал да тиз кайт, диделәр, атым җончыды, миңа җавабын сөйләсәңез, ат бирсәңез, мин тиз китәр идем.

Олуг Мөхәммәд. Сиңа аты да булыр, ярдәм дә булыр, бүген гаскәрләр берлә бергә юлга чыгарсың, аларга кыска юлны күрсәтерсең. Мирза Гали! Атчабарны кунак итсеннәр, сыйласыннар, аны күздән озак тотмасыннар.[88]

*(Атчабарга.)* Хәбәр китерүең өчен рәхмәт! Арыгансың, аша-эч, хәл җый, кичкә юлга чыгарга хәзер бул!

Ч у в а ш сәлам биреп чыга, аның берлә бергә
м и р з а  Г а л и дә чыга.

Х а н *(Галим бәккә).* Бу Урман асты дигән авыллар Казанга никадәр ераклыкта?

Г а л и м  б ә к. Ике йөз илле, өч йөз чакрым чамасында.

М и р з а  Г а л и дә керә.

Т и м е р. Юллар яхшымы?

М и р з а  Г а л и *(букчасыннан зур бер кәгазь алып, ханның уңына куя).* Менә, хан хәзрәтләре, бу – безнең Казан иленең сурәте. Менә Казан шәһәре, менә Идел суы, менә Чабаксар, менә Чуваш иле, менә Алатыр суы, менә урысларның Муром шәһәре, бу яу шул Муромнан килгәнгә ошый. Менә олуг юл, менә атчабарның сөйләгән урманы.

Т и м е р. Бу урманлык юлында авыллар бармы? Ат азыгы, кеше азыгы табылырлыкмы?

Г а л и м  б ә к. Урман эчендә күмер яндыручы, дегет чыгаручы чувашлар, чирмешләр яшиләр, зур авыллар юк, аерым-аерым өйләр бардыр, аз-маз ашамак-эчмәк булыныр, урманда ау хайваны күп, кошы-корты да иксез-чиксез, печән, салам, солы булынырмы – аны әйтә алмыйм.

Т и м е р. Хан хәзрәтләре, без бу урыс явыннан берсен дә исән качырмаска тиеш, аларга бер сабак булсын!

Х а н. Тугры, Тимер! Шуның өчен без берникадәр гас-кәрне олуг юлдан азык берлә күндерик, икенче бер атлы гаскәрне урман эченнән җибәреп аркаларына төшик!

Т и м е р *(харитадан бармагы берлә йөртеп).* Монда азыгы табылса, безнең атлылар өч көндә боларның аркасына чыга алалар.

А л т ы н  б ә к. Шәһәрдә бу урман юлларын үзенең биш бармагы кебек белгән әллә никадәр ямчы[89] бар, шулардан кыйлавыз алсын.

Т и м е р. Бу фикер тугры!

Мәхмүд. Урман юлына хәзер үк бер йөз башы командасында күпләп атлар җибәрик, алар ярты юлдамы, якынракмы, мөнасиб бер йирдә арттан килгән гаскәрләрне атларын ашатып, хәл җыйдырып көтеп торырлар, гаскәр дә барып җитәр-җитмәс, алҗыган атыннан төшеп, хәл җыйган атларга атланып юлына китә бирер. Шулай итеп вакыт югалтмамыз.

Хан. Бу фикер дә тугры!

Тимер *(харитадан карап).* Мондагы елгалар хәзер һәммәсе туңганмы? Урман эчендәге юлда җылулыклар, яшерен батаклыклар юкмы?

Галим бәк. Без ул кадәресен белмимез, аны ямчылардан сорашып белешерсез, сез гаскәрләр юлын хәзерләңез. Без, хан хәзрәтләре боерык бирсә, кыйлавыз була беләчәк ямчыларны чакырыйк.

Олуг Мөхәммәд. Тугры, тугры, сез шулай итеңез!

Вәзирләр сәлам биреп чыгалар. Олуг Мөхәммәд, шаһзадә Мәхмүд, Тимер командан, язучы мирза Гали калалар.

Олуг Мөхәммәд. Күпме гаскәр күндерик дисез?

Тимер. Барлыгы мең кешедән ким булмасын.

Мәхмүд. Ул аз, без дошманның никадәр булуын белмимез, бәлки аркасында сакта да көче бардыр? Минемчә, урман эченнән мең атлы, биш йөз җәяүле – җәяүле гаскәр дә чаналарда ямчылар берлә китсен. Олуг юлдан да сигез йөз-мең кешелек бер алай[90] китсен.

Тимер. Гаскәр никадәр эстәсәң, шулкадәр бар. Ялгыз шәһәрдә зур куәт чыгуы шау-шуга сәбәп булмасын.

Олуг Мөхәммәд. Гаскәр күндерүне төнлә эшләңез! Инде кемне бу куәткә командан итеп җибәрәмез?

Мәхмүд. Мине күндереңез. Мин атлылар берлә урман эченнән йөрим, мең башы Дәүләттугдыны олуг юлдан күндерик. Бүген үк йөз башы Карабаш берлә урман эченә азык берлә атлар күндерик.

Олуг Мөхәммәд. Бу сүзләрең, Мәхмүд, игътибарга алынырлык. Ләкин минем тагын бер шөбһәм бар: бу урыс көченең алдагылары гына булып, безнең бу аз гаскәремезгә урысларның аркадагы зур куәте берлә

каршылашырга тугры килеп гаскәремез һәлак булмасын. Дәүләт ныгып бетмәс борын андый авырлыкка төшсәк, халык бездән йөз чөерүе дә бар.

Т и м е р. Бу да уйланылачак эш, ләкин, хан хәзрәтләре, без дә монда йоклап ятмамыз, хәзерлегемезне күрер-мез, шымчыларымызны җибәрермез. Минемчә, хан хәзрәтләре мөнасиб күрсә, шаһзадә Мәхмүднең баш булып китүе халык күзендә хан хәзрәтләренең гаиләсенең исемен тагы күтәрер иде.

О л у г  М ө х ә м м ә д. Мин дә шул фикердә, ләкин анасы ни диер?

М ә х м ү д. Сугыш эшендә хатыннар сүзе берлә йөрелерме? Анам ни дисен, беренче мәртәбә сугышка китүемме?

О л у г  М ө х ә м м ә д. Алай булса сез бөтен хәзерлек-лереңезне тәмамлаңыз, мин ханбикә берлә сөйләшим, алар хатын бит, бик курыкмасыннар. *(Мирза Галигә.)* Мирза, килгән чувашка чикмән кидереңез, берәр кирәге булса, бүләк биреңез! Вәзирләргә дә сөйләргә оныттым, бу эшне гаскәрне башка шәһәргә күчерәмез төсендә эшләсеннәр, шау-шуга сәбәп булмасын!

Үзе чыга. Мәхмүд берлә Тимер харита өстендә маташалар, Мирза Гали дә аларга әллә ниләр күрсәтә. У г л а н керә.

У г л а н *(сәлам биреп).* Ямчылар килделәр!

Т и м е р. Гаскәрлек өенә алыңыз, хәзер барамыз.

У г л а н чыга, аякка калкалар.

*(Мирза Галигә.)* Син дә кил, алардан юлны сорашканда син дә кәгазьгә төшерерсең, бәлки, урман эчендә авыллар дә бардыр, булса аларны дә тамгаларга онытма!

Ө ч е с е дә чыгалар. Сәхнә буш кала. Бераздан х а н берлә х а н б и к ә чыгалар.

Х а н б и к ә. Тагы сугыш, тагы кырылыш, кайчан соң без бераз тыныч яшәрмез? Бу сугышның да очы-кырые юкмыни? Мин үземне белә башлаганнан бирле бетмәде шул сугыш!

О л у г  М ө х ә м м ә д. Бу сугыш түгел, урыс баскынын куар өчен генә, берничә йөз урыс талаучысы чуваш иленә кергән дә мал-туарын сөреп

киткән. Без илне-йортны сак-ларга сүз бирдек, урыс явын куу – безнең бурычымыз.

Ханбикә. Анысы шулай, илнең башы үзенең бурычын эшләмәсә, халыктан үзенең бурычын ничек эшләтә алыр? Ләкин шул сугыштан башым тына алмаганга йөрәгем әрни. Әле генә тынычлыкка кавыштык дип, угылларымның туен ясарга тотынган идем, каршыма тагы сугыш чыкты, тагы угылым сугышка китте. Мәхмүднең җеназасы кайтса, бу ил дә миңа тәмуг булачак.

Олуг Мөхәммәд. Андый кара уйларга чумарлык бернәрсә дә юк, бу берничә көнлек бер сәфәр генә, угылың дошманны җиңеп сау-сәламәт, батыр булып кына кайтачак.

Ханбикә. Амин! Авызыңа бал да май. *(Тынлык.)* Язмышың шулай булгач, күтәрми хәлең юк. Тәңрем, угылымны сакла!

Олуг Мөхәммәд. Кечкенә эшне зурайтма, бала-чагага курку салма! Киленбикә дә бар, ул синең болайлыгыңны күрсә коты чыгар. Без халык алдында һичбер дошманнан курыкмый торган, дию пәрие берлә кылычка-кылыч килә торган батыр булып көрәшергә кирәк, батырлык үрнәген халык бездән алырга кирәк.

Ханбикә. Беләм, беләм. Әле бит – ана, бала-чага дәрте берлә янасың. Хәерле юл булсын!

Олуг Мөхәммәд. Бала-чагага «гаскәрне икенче шәһәргә күчерәмез генә» диеңез.

Ханбикә. Диярмез диюен дә, ышансалар, аларның да сугыштан җаннары өшегән.

Олуг Мөхәммәд. Кичке ашны бала-чага берлә бергә ашармыз, барысы да хәзер булсыннар, киленбикәгә дә сөйлән.

Ханбикә. Ярый. Тәңре балам-чагамны сау кылсын!

Олуг Мөхәммәд. Тәңре илем-йортымны сау кылсын, диең, син бер өйнең генә анасы түгелсең, бөтен илнең анасысың, син – ханбикәсең!

Ханбикә. Сүзең тугры, падишаһым! Тәңре илем-йортымны, падишаһымны, якыннарымны, ил хезмәтчеләремне, гаскәрләремне, бала-чагамны сау кылсын! *(Күзеннән яшьләрен сөртә.)*

Мәхмүд килеп керә.

Мәхмүд. Әни, мин гаскәр башы булып урыс дошманга каршы китәм. Шул имансыз, кара йөрәк Василийдан үч алырга китәм. Шул көнне мин никадәр көттем, никадәр көттем! Әни, миңа фатихаңны бир! *(Анасының кулын үбә.)*

Ханбикә. Мин сине илне саклар өчен дип үстердем. Илең-йортың, падишаһлыгың сәламәт-тынычлыгы өчен кулыңнан ни килсә, шуны кызганма! Урыс дошманнарны җиңеп, илне коткарып, батыр булып илгә кайт, угылым! *(Мәхмүдне үбә, күзеннән яшьләре ага.)*

Углан *(керә).* Хан хәзрәтләре, Әбүлмөхсин дәрвиш сезне күрергә рөхсәт эсти!

Хан. Керсен.

Углан чыга. Ханбикә йөзен яулык берлә сөртә. Әбүлмөхсин кереп сәлам бирә.

Олуг Мөхәммәд. Рәхим ит, сәед! Саулык-сәламәтлекме?

Әбүлмөхсин. Җан тәндә, хан хәзрәтләре, күңелем генә тыныч түгел.

Олуг Мөхәммәд. Ни булды? Берәр уңайсызлык чыктымы? Әллә бер яңлышлык эшләделәрме?

Әбүлмөхсин. Юк, хан хәзрәтләре, үзем генә яңлышлык эшләдем. Сезнең мәрхәмәтеңездән файдаланып, вакытында үземне гаскәрлеккә яздыра алмадым.

Олуг Мөхәммәд. Син гаскәрлек берлә ни эшлисең?

Әбүлмөхсин. Ил дошманы, дин дошманы берлә сугышыр идем.

Олуг Мөхәммәд. Ил дошманы, дин дошманы берлә гаскәр генә сугышмый, син сүзең берлә, вәгазең берлә, үзеңнең тугры тормышыңда халыкка үрнәк булуың берлә һәр көн, һәр сәгать ил дошманы, дин дошманы берлә сугыш алып барасың. Гаскәр дошманның тәнен генә үтерә, син аның

җанын үтерәсең, бер дошманның гына түгел, мең дошманның юлына киртә саласың! Моннан да зур сугыш булырмы?

Әбүлмөхсин. Сез бу сүзләреңез берлә, хан хәзрәтләре, минем кебек кечкенә, Алланың бер гөнаһлы бәндәсен урынсыз йирдә зур итәсез. Мин сездән орышка каршы шул сугышка мине дә җибәрүеңезне үтенәм!

Олуг Мөхәммәд. Андый зур сугыш юк, сәед! Урыслар чуваш илен баскын иткәннәр дә, шуларны куарга гына бераз гаскәр җибәрәмез.

Әбүлмөхсин. Мине дә шул гаскәрләр эченә алыңыз!

Олуг Мөхәммәд. Синең сугыш сафың монда, ил эчендә. Чуваш илендә урманлык, сазлыкта синең ни эшең бар? Аннан ни эстисең?

Әбүлмөхсин. Минме? Мин йә гази,[91] йә шәһид булырга телим, илем өчен, динем өчен мин дә каным, җаным берлә дин дошманына каршы сугышырга телим. Мин бит бу илнең баласы, мин дә илемә каршы бурычымны үтисем килә. Халык миңа дәрвиш дисә дә, мин үз файдамны белми торган дәрвиш түгелмен. Үлсәм шәһид була, сау калсам гази була торган изге эштән мине ник мәхрүм итәргә телисең, ил өчен канны түгеп гази булу, шәһид булу сезнең генә хакыңызмыни?

Олуг Мөхәммәд. Аңлата алмадым, сәед! Сезнең мондагы эшеңез, илгә хезмәтеңез тагы кыйммәтле димәкче булдым.

Әбүлмөхсин. Бөтен куркаклар, гаскәрлектән качар өчен, минем мондагы хезмәтем илгә тагы файдалы, диләр, мин куркак түгел, хан хәзрәтләре, рөхсәт итеңез, гаскәр берлә бергә мин дә сугышка китим!

Олуг Мөхәммәд *(Мәхмүдкә).* Син сәед хәзрәтләрен үзең берлә бергә ала аламсың?

Мәхмүд. Сөенә-сөенә. Ләкин сугыш арасында сәед хәзрәтләренә кирәк кадәр хөрмәт итә алмам дип кенә куркам.

Әбүлмөхсин. Мин хөрмәт эстәмим, мин башкалар кебек сугышчы гына булырга телим!

Ханбикә. Сәед хәзрәтләренә рөхсәт итеңез, аның күңеле эсти, хәтерен кырмаңыз!

О л у г  М ө х ә м м ә д. Рөхсәттә сүз юк, сугышка да бара беләсез, ләкин шундый кечкенә бер эшкә зур көчне исраф итү булмасын дип кенә куркам. Мәскәүгә таба барачак зур сугышымызда мин үзем сезне, сәед, бергә сугышка барырга чакырачак идем.

Ә б ү л м ө х с и н. Шәһид булмасам, анысына да сөенә-сөенә барачакмын, хан хәзрәтләре!

Х а н *(угланга).* Сәедкә гаскәри киемнәр, кирәкле кораллар, иярле ат бирегез!

У г л а н. Әмер сезнең, хан хәзрәтләре!

М ә х м ү д. Сез, сәед хәзрәтләре, иртәгә минем берлә бергә юлга чыгасыз.

Ә б ү л м ө х с и н. Фәрман сезнең, шаһзадә!

Тышта гаскәр быргысы чалына.[92] Әбүлмөхсин Мәхмүдкә сөальле карый.

М ә х м ү д. Йөз башы алдан атларны, азыкларны хәзерләп куяр өчен юлга чыга.

О л у г  М ө х ә м м ә д. Изге юл!

Х а н б и к ә. Изге юл! Тәңре ярдәмчемез булсын! *(Күзеннән яшен сөртә.)*

Ә б ү л м ө х с и н. Ак юл! Миңа да шәһидлек юлы булсын!

Быргы тавышы дәвам итә.

П ә р д ә  т ө ш ә.

## БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ

Х а н  с а р а е. 1445 елның 1 октябрь көне. Көн ачык, кояшлы һәм йылы. Сарайның тәрәзәләре ачык. Урамнан халык һәм музыка тавышы ишетелә. Халык, бертуктамаенча: «Хан хәзрәтләремез саг улсын, саг улсын[93] шаһзадә, саг улсын гаскәрләремез!» Урамда гаскәри марш уйнала. Залга ханбикә – Г ө л б и к ә, с о л т а н н а р, с а р а й  х а д и м н ә р е[94] тулалар. Һәммәсе дә тәрәзәләргә яклашалар.

Ханбикә. Пәрдә арасыннан гына караңыз. Халык безне түгел, хан хәзрәтләрен көтә.

Алмас солтан. Әни, халыкны кара, меңнәр-меңнәр, төмәннәр! Болар кайдан җыелып җиткән?

Күңел солтан. Урысны җиңүне, гаскәрнең кайтуын бәйрәм итә.

Ханбикә (Гөлбикә). Көне дә нинди матур, яз көне дип белерсең, тәмам бәйрәм көне!

Тышта халык «Саг ул!» дип кычкыра.

Бер сарай хатыны. Бу көннәр – Казан тирәсендәге алма җыю көннәре күп елны шулай матур була. Авылда да инде кыр эше беткән, авылдан-авылга, кардәш-кабиләгә кунакка йөрү башлана...

Икенче бер хатын. Кыз сорау, егет өйләндерү чагы килә.

Ханбикә. Бу ел игеннәр дә уңды, умарталарда бал да бик күп, бал яса да туй ит. Мал-туар да симез, ел – муллык. Өстенә гаскәрләремез урыс дошманны да йөз өсте белән җибәрде. Халык сөенеч эчендә, тиресенә сыя алмый.

Халык *(кычкыра).* Саг улсын хан хәзрәтләре! Саг улсын шаһзадәләремез! Саг улсын гаскәрләремез!

Ханбикә *(Алмас солтанга).* Әтиеңә сөйлә – халык чакыра, халык көтә, тиз килсеннәр. Мәхмүд кая, Ягъкуб кая? Хәбәр биреңез!

Караучылар хәбәр бирергә чыгалар.

Ханбикә. Халыкны көттерергә ярамый.

Тышта тавыш куәтләнә. Олуг Мөхәммәд залга чыга,
үзе гаскәри киемдә.

Ханбикә. Халыкны кара, халыкны, бөтен дөнья тулган!

Олуг Мөхәммәд. Мәхмүд берлә Ягъкуб кайдалар? *(Караучыларга.)* Тиз килсеннәр.

Бер караучы чыга.

О л у г  М ө х ә м м ә д. Моннан җиде ел гына элек без дошманнарымыз тарафыннан илемездән куылып, урыс кенәзе Василийның мәрхәмәтенә сыгынган идек. Ул да безнең ялваруларымызга карамаенча, безгә тын алырга да ирек бирмәенчә, карлы-бозлы суык көннәрдә безне сыгынган йиремездән куа иде. Бүген шул ук Василий, таҗыннан, тәхетеннән мәхрүм ителеп, безгә әсир төшкән, аяк астымызда җанын коткарыр өчен ялына, ялвара. Тәңренең хөкеменә кара!

М ә х м ү д берлә Я г ъ к у б гаскәр киемнәрендә залга керәләр.

Һичбер вакыт хәзерге көчеңә таянып дустыңа, дошманыңа золым итәргә ярамый. Көч-куәт бүген бар, иртәгә юк, болар барысы да Тәңренең кулында.

Халык кычкыра.

Х а н б и к ә. Халык бик көтә, хан хәзрәтләре, халыкка чыгыңыз!

О л у г  М ө х ә м м ә д *(угылларына).* Икеңез ике тарафымда булыңыз!

Акрын гына балконга таба йөриләр. Хезмәтчеләр балкон ишеген ачалар. Хатыннар пәрдә аркасына тәрәзәләргә җыелалар. Урамда халык бердән тына.

Х а л ы к *(бераздан).* Саг ул, хан хәзрәтләре, саг улсын шаһзадәләремез, саг улсын гаскәрләремез!

Музыка уйный, тавыш музыкага катыша. Бераздан Олуг Мөхәммәд кулы берлә туктарга ишарәт итә. Музыка тора, халык туктый, тына.

О л у г  М ө х ә м м ә д. Җәмәгать! Барыңыз да шатлык, сөенеч эчендә бәйрәм итәсез. Итеңез, бу сезнең хакыңыз! Бу сөенеч, бу шатлыкны сезгә, сезнең берлә бергә безгә кем китерде?

Х а л ы к *(кычкыра).* Сез, хан хәзрәтләре, шаһзадәләр, гаскәрләремез! Аягыңыз җиңел булды, хан хәзрәтләре!

О л у г  М ө х ә м м ә д. Бу шатлыкны безгә ару-талуны белмәгән батыр гаскәрләремез китерде, бу сөенечне безгә шул авыр сугышта җаннарын кызганмаган шәһидләремез китерде. Бәйрәм корбансыз булмый, бу бәйрәмнең корбаннары шул газиз шәһидләремез булды. Сез, җәмәгать, этиләреңезне, агаларыңызны, угылларыңызны, мин дә үземнең авыр көннәрдә иптәшләрем, бәкләремне, мирзаларымны, сөйгән якыннарымны

югалттым, ил юлында шәһидләр бирдем. Аларның җан-кан корбаннарына каршы Тәңре безгә бу җиңүне насыйп итте, дошманнарыбызны һәлак итте. Шул шатлыклы бәйрәм эчендә газиз шәһидләремезне онытмаңыз, һәркемнең бер сөенеч эчендә бәйрәм иткән чагында ирләрен, угылларын күрмәенчә күз яшьләрен агыза торган шәһидләремезнең аналарын, тол хатыннарны, үксез балаларны хәтереңездән чыгармаңыз, аларның ил өчен биргән корбаннарының кадерен онытмаңыз. Бу бәйрәмнәрне үткәргәндә элеккеге кара көннәрне, куркулы төннәрне дә хәтереңездән озак тотмаңыз. Ул кайгылар, ул куркуларны мәңгегә илемездән озак тотар өчен һәрвакыт җан-кан фидакярлеге кирәк икәнен онытмаңыз. Саг улыңыз, ил, йорт саг улсын! Казан ханлыгы көчле, куәтле булып мәңгегә дошманнарына курку салып яшәсен!

Х а л ы к. Саг улыгыз, саг!

Музыка башлана. О л у г  М ө х ә м м ә д,  ш а һ з а д ә л ә р залга керәләр. Халык тавышы. Музыка акрын-акрын озаклаша. Олуг Мөхәммәд вә шаһзадәләрне х а н б и к ә, к ы з л а р ы, с а р а й  х а т ы н н а р ы чолгап алалар.

Г ө л б и к ә *(Олуг Мөхәммәдкә).* Нинди зур бәхеткә ирештек!

О л у г  М ө х ә м м ә д. Бәхетемез озын сөрсен, шөк-ранәсен кылыңыз!

Г ө л б и к ә. Мең-мең шөкер. Тәңре илемезне яудан сакласын!

О л у г  М ө х ә м м ә д. Монда хәзер вәзирләр, гаскәрләр килерләр.

Г ө л б и к ә. Шуны әйтим дигән идем: мин шәһид гас-кәрләремезнең аналарын, хатыннарын, балаларын ашка чакырам, сезгә комачаулык итмәсме?

О л у г  М ө х ә м м ә д. Эшлә, эшлә, яхшы булыр. Илнең шатлыгы да бергә булган кебек, кайгысы-хәсрәтен дә безгә бергә бүлешергә тиеш.

Г ө л б и к ә. Без чыгыйк.

Икенче якка чыгалар. Сәхнәдә Олуг Мөхәммәд, шаһзадәләр генә кала. Өчесе бер нәрсәдер сөйлиләр, ишетелми. Ишектән м и р з а  Г а л и керә.

М и р з а  Г а л и *(сәлам бирә).* Хан хәзрәтләре, шаһзадә хәзрәтләре, олуг бәйрәмеңез котлы булсын!

О л у г  М ө х ә м м ә д. Бу барымызның да бәйрәме, мирза Гали, Тәңре озын гомерле итсен! Вәзирләр килделәрме?

М и р з а  Г а л и. Килделәр, хан хәзрәтләре, сездән бое-рык көтәләр.

О л у г  М ө х ә м м ә д. Килсеннәр!

М и р з а  Г а л и чыга. Бераздан берсе аркасыннан берсе в ә з и р - л ә р керәләр, алардан соң төмән башы А р с л а н, мең башы Е л к ы б а й керәләр. Барысы да иелеп-иелеп сәлам бирәләр.

Боерыңыз, боерыңыз! *(Үзе тәхетенә чыга, аның бер тарафына ике шаһзадә, алардан соң гаскәр башлыклары, икенче тарафына вәзирләр утыралар.)* Вәзирләрем, команданнарым, бүген шул урыс эшен бетерергә кирәк дип сезне киңәшкә чакырдым. *(Алтын бәккә.)* Бикәч мирзадан хәбәр юкмы?

А л т ы н  б ә к. Хан хәзрәтләре, бүгенгә кадәр Бикәч мирзадан һичбер хәбәр юк. Димитрийдан да һичбер тавыш чыкмады. Муром юлына каршысына дип ат чаптырттым, һичбер хәбәр ала алмаенча кире кайттылар, Димитрий Бикәчне үтерттеме, башка төрле берәр казага очрадылармы, белә алмадык.

О л у г  М ө х ә м м ә д. Ни булса да башларына көтелмәгән бер эш чыкты.

С ә е д  Җ ә л и л. Бабаларымыз: «Урыс атаң булса, билеңдә балтаң булсын!» – дигәннәр. Димитрий Бикәч мирзаны үтерткәндер, аны Сарайда вакытта олуг кенәз ясатмады дип үпкәсе дә бар иде.

Г а л и м  б ә к. Ни булса да бар. Димитрийның үзеннән дә илче килеп, хан хәзрәтләренә баш иеп, олуг кенәзлек ярлыгын сорарга тиеш иде!

Т и м е р. Бу эштә бер аңлашылмау бар. Урыс эшен дә озын сузу тугры булмас. Мәскәүгә кемне булса да олуг кенәз итеп ярлык бирергә кирәк, хан хәзрәтләре, Василийның да, боярларның да язмышын өзәргә кирәк.

О л у г  М ө х ә м м ә д. Без Димитрийны олуг кенәз итсәк, биргән сүзен тотып, ике йорт арасында дустлык башлар дип уйлаган идек, шуңарга күрә Бикәч мирзаның теләген кабул итеп, аны Димитрийга җибәргән идек.

А л т ы н  б ә к. Хан хәзрәтләре, урыс иле эше – безнең мәмләкәтнең иң зур эше. Үзеңезгә мәгълүм: шул урыс иле эшеннән Сарайда да аңлашылмаулар чыккан, хан хәзрәтләре тәхетене ташларга кирәксенгән иде. Ул эштә дә

Василий – Димитрий көндәшлеге зур урын тоткан иде, хәзер дә шундый авырлыклар чыкмасын дип саклык берлә эш кылыйк.

Галим бәк. Сарайда булган кебек йә Василий, йә Димитрий тарафын тоткан боярларымыз, Тәңрегә мең шөкер, Казанда юк, без һәммәмез илемез файдасы ягыннан гына шул эшне карыймыз.

Тимер. Бу сүзләр тугры, ләкин урыс халкы үзе бик хәйләле халык, безнең кебек беркатлы түгел, поплары шайтаннан сабак алалар, шундый эштә акча түгүне дә бернигә саймыйлар.[95] Казанда да акчага, мәртәбәгә алданучы булмас дип әйтә алмыйм.

Галим бәк. Ашлык кибәксез булмый, әлбәттә, Казанда да төрле халык булыныр, ләкин хәзергә, Тәңрегә шөкер, андый эшкә батырчылык кылырлык беркем дә күренми. Тагы урыс бәласе безнең үзәгемезгә үткән.

Мәхмүд. Бу урыс эше – безнең бөтен дәүләт эшләремезне чуалтып килә торган бәлале эш. Василий үзе дә һичбер биргән сүзен тотмый торган хәйләле бер елан. Хәзер Василий зур боярлары берлә кулымызга төшкән икән, шуларны юк итәргә кирәк тә, Мәскәүгә үземездән берсен ясакчы җибәреп кенә тотарга кирәк. Ярты-йорты эшләр берлә генә урыс йортын тынычландырып булмый.

Сәед Җәлил. Мин дә шаһзадәнең уендамын. Илемезгә, башымызга бу кадәр бәлаләр тудырган шул Василийны исән калдыру урыс илендә безнең көчсезлегемездән эшләнгән эш дигән уйны тудырачак. Шул кяферләрнең башын кисәргә кирәк. Мәскәү иленә гаскәр күндереп, ясакчымыз ашасыннан аның эшләрен алып барырга кирәк.

Тимер. Урыс иле хәзер безнең бабайлар Идел буена аяк баскан чактагы кебек ата угылын, ана кызын белми торган, арпа камыры кебек оешуны белми торган хайван көтүсе[96] түгел, аларны берләштергән хәзер дин башлыклары бар. Болар бөтен көчләре берлә урыс халкын бергә оештырырга тырыша. Шул уйны алга сөргән боярлары да юк түгел. Ул чактагы кебек һәрбер шәһәрләрендә үз башына гына эш күрә торган кенәзләре юк хәзер аларның. Вә олуг кенәзлеге янында бары да берләшкән. Тагын бу кадәр күп

шәһәрләре, авыллары бар. Урыс илен хәзер без ясакчы берлә генә башкарырлык түгелмез, безнең моңарга көчемез җитми.

Мәхмүд. Безнең бабайлар Мәскәүдә бер олуг кенәзлек ясап, урысларны берләштереп яңлышлык иткәннәр, безнең башымызга бәла тудырганнар. Бабаларымызның шул хатасын төзәтмәсәк, киләчәк буынымызга, илемезгә зур бер бәла мирас калдырачакмыз.

Сәед Җәлил. Шулай, шулай! Ул вакытлар урыс-ларның нә диннәре бар иде, нә попларының рәте-чираты бар иде, нә аларның дин башлары – патриархлары бар иде. Һәр шәһәр үзенә бертөсле гыйбадәт итә иде. Алар ул вакытта рәтләп христиан да түгел – мәҗүси иделәр, шуларны мөселман итү берни түгел иде. Ул вакытның дин әһелемез бу хәлне күрә алмаган да инде – без бәласен чигәмез. Хәзер дә урыс илен хак дингә күчерергә кич түгел, [97]
урыс эшен тирәннән бетерсәк, бөтен халкымыз бер Тәңрегә, бер пәйгамбәргә, бер ханга баш иячәк, илдә-көндә тынычлык булачак.

Галим бәк. Хан хәзрәтләре! Шаһзадәнең сөйләгән сүзләре, сәед Җәлил хәзрәтләренең уйлары барысы да бик дөрес, әгәр аларның уйларын барлыкка чыгара алсак, нинди зур уңышлы эш булыр иде, нинди бәхетле ил булыр идек. Без хәзер бу эшләрне барлыкка чыгарырлык хәлдә түгелмез. Дөрес, гаскәрләремез батырлык күрсәтте, Василийны тоткын итте. Шуны белергә кирәк ки, сугыш эше – бәхет эше, бәхет кошы һаман бер илнең башында очмый. Икенче сугышта җиңмәсәк, хәлемез ни булыр, урыслар безне көчләп чукындырырга тотынмасслармы? Без әле җиде-сигез еллык бер дәүләт. Хан хәзрәтләренең тугры башкарлыгы аркасында илемез көч алды, баеды, халкымыз күбәйде. Шул юлдан барсак, егерме-утыз ел тынычлык эчендә илемезне бер юлдан, халкымызны бүлми, аермый бер эздән алып бара алсак, шаһзадә хәзрәтләренең дә теләкләрен дөньяга китерә алырмыз. Хәзерге көндә без урыс илен басып тотарлык көчтә түгелмез.

Алтын бәк. Мин чит илләр берлә эш күрәм. Күрше илләремездә мөселманнар булган кебек, христианнар да бар. Элеккеге Болгар базарын хәзер Казанга күчердек, безгә алучы-сатучы булып ләһе, нимече, маҗары, [98]

латины киләдер-китәдер, безгә мал, дәүләт калдырадыр. Без йортымызны мөселман илләре берлә христиан илләре арасында мал алыштыру йире ясарга тырышамыз. Зур су юлларымыз, халкымызның сату-алу эшен аңлавы моңарга зур уңайлык ясыйдыр. Минем уемча, чит илләр берлә сату-алуның киңәюе, зураюы хәзинәмезгә зур файдалар китергәне кебек, киләчәктә тагы зур дәүләтләр агызачактыр, дәүләт ягыннан да безнең урынымызны олуглатачак, күршеләр арасында сыемызны арттырачактыр. Христиан халыклары безнең сату-алуда тугрылыгымызны гына түгел, бөтен диннәргә хөрмәт итүемезгә дә бик зур бәһа бирәләр. Шуңарга күрә мин урыс илен дә үз халкының кулында, үз динендә калдыру яхшы булыр дигән уйдамын.

Олуг Мөхәммәд. Бүгенге сөйләшүләрне мин зур сөенеч берлә тыңладым. Уйларда аерма бар кебек күренсә дә, илемез, дәүләтемезне көчле итүдә барымыз да берләшәмез, аерма моның юлларында гынадыр. Сәед хәзрәтләренең, Мәхмүднең теләкләре моннан йөз ел элек башкарылган булса иде, безнең, бәлки, баш каламыз Казан булмаенча, Мәскәү булган булыр иде. Ләкин бүген Мәскәү үзенә бер тормыш берлә, Казан үзенә аеры бер тормыш берлә яши. Бабаларымызның Мәскәү олуг кенәзлеге ясау-ларының да бер сәбәбе булгандыр, таркау булса да бу кадәр киң йирләргә утырган күп урыс халкын бер үзәктән (мәркәздән) башкара алуларына ышанмаганнар булырга кирәк. Беләсез, Идел буена без егерме төмән берлә генә килдек. Бүген без бергә утыра торган болгар халкы берлә без – килгәннәр арасында ул вакытлар аңлашылмаслык[99] бар иде. Чыңгыз бабамызның һәр йирдә, һәрбер төрле динне хөрмәт итүе, дин әһелен түләүдән азат итүе урыс динен дә хөрмәтле итүгә сәбәп булгандыр. Болар үткән эшләр. Хәзер, Тәңрегә мең шөкер, без килгәннәр берлә, Болгар илендә меңнәрчә ел утырган халык берлә бер бөтеннән чыкканымызны аңлап, берлек нигезендә яңы бер дәүләт кордык, аны Алтын Урданың варисы дәрәҗәсенә җиткерергә зур адымнар аттык. Ләкин әле үземез теләгән кадәр куәтләнеп җиткәнемез юк, шуның өчен урыс илен үз башына калдырып, безнең сүземезне тотардай бер олуг кенәзне Мәскәү тәхетенә утыртырга тиешмез. Урыс иленең эченә кадәр

үземезнең ясамызны[100] кертеп, мирзаларымызны, түрәләремезне урыс иленең зур шәһәрләренә йирләштереп, Казан дәүләтенең күз-колагы ясарга, шул эшне урыс олуг кенәзенең үз кулы берлә эшләтергә, акрын-акрын урыс илен сәед хәзрәтләре, Мәхмүд теләгән хәлгә китерергә тиешмез. Бу эшләр бер адымда була торган эш түгел, бу – зур эш, озын еллар тели торган эш. Алдымызда кемне Мәскәү олуг кенәзе ясау каладыр. Димитрийны олуг кенәз ясаса идек, Василийны бу кадәр хыянәтләре өчен җәзасын чиктергән булыр идек, урыс илендә дә икелек яратып, аны эченнән зәгыйфьләндергән булыр идек. Ләкин Димитрийдан нә илче бар, нә хәбәр, шуңарга күрә Василийның аягымызга егылып ялваруын тыңла[рга], үз теләкләремезне аның ашасыннан эшләтергә тырышырга тиешмез. Мирза Гали, Василийның ялварышын укысаң?!

Тынлык. Мирза Гали букчасыннан бер кәгазь чыгара.

Укы!

Мирза Гали *(укый).* «Олуг хан хәзрәтләре, шаһзадәләр, вәзирләр, сәедләр, бәкләр, мирзалар, гаскәр башлыклары, бөтен Казан олуглары! Мин ки, элекке Мәскәү олуг кенәзе Василийның вә аның боярларының ялварышы шулдыр: Тәңрене таныкк куеп, сез хан хәзрәтләренә биргән сүземне шайтан коткысы берлә тотмавымның җәзасын бүген күреп ятам. Минем сезгә каршы кылган начарлыкларым минем башымны кисәргә, тәнемне этләргә ашатырга сезгә хак бирсә дә, сез, хан хәзрәтләре, колыңыз миңа вә минем боярларыма каршы шәфкать, мәрхәмәтеңезне кызганмадыңыз. Мине исән калдырдыңыз, моның берлә миңа үземнең яңлыш эшләремне уйларга вакыт бирдеңез. Мин үз гөнаһларымның ачысын чигеп, газап эчендәмен. Озын көннәр, уйкусыз төннәрдә уйлый-уйлый, бу кара бәхетемнең сәбәбен үземнең Тәңрене таныкк куеп биргән сүземне тотмау, сезгә каршы хаксызлык итүем икәнлеген аңладым. Моннан соң үлгәнчегә кадәр биргән сүземнән чыкмаска үземә үзем ант иттем, бу антымны үлгәнче тотачакмын.

Хан хәзрәтләре! Сез берничә мәртәбә урыс иле берлә Болгар иле арасында күршелек нигезендә дустлашуны вә бер-беремезнең йортына-суына баскын

итүне бетерү кирәклегене белдерденңез. Сезнең бу тугры уйларыңыз-ны мин, наданлык берлә, янымдагы боярлар, попларның коткысы берлә, кабул итмәдем, иленңезгә вә Сезгә каршы дошманлык өстенә дошманлык эшләдем. Хәзер күрәм ки, Болгар иленең дә, урыс иленең дә йире-суы үз-үзенә җитәрлек вә ике күрше дәүләт дустлык берлә сату-алу ясап яшәсә, икесе өчен дә тынычлык вә рәхәтлек туачак вә шул юлда сезнең фәрманыңызны булдырырга, эшкә ашырырга миңа куәт бирсәңез, бөтен гөнаһларымны оныттырырлык хезмәтеңезгә хәзермен.

Хан хәзрәтләре! Урыс иле өч айдан бирле башсыз хәлдә. Моннан башбаштаклык туды, юлбасарлар күбәйде, болар бүген булмаса, иртәгә сезнең иленңезнең дә рәхәтен качырырлар, баскынлыклар ясарлар вә сезгә зур мәшәкатьләр тудырырлар. Беләсез, хан хәзрәтләре, безнең урыс халкы камчы астында яшәргә өйрәнгән. Камчы тоткан кул киселдеме, урыс илен башбаштаклык каплый. Бу борынгы чакта да шулай булган, хәзер дә шулай, киләчәктә дә шулай булачак. Шуның өчен урыс иленә бер олуг кенәз билгеләп, уң кулына камчы бирү – хан хәзрәтләре, сезнең бурычыңыздыр. Бу урынга теләсәңез Димитрийны, теләсәңез урыс кенәзләреннән башка берсен билгеләүдә сез тулы ихтыярлысыңыз. Әгәр минем күктәге йолдызлар, диңгездәге балыклардан күп гөнаһларымны кичереп, мине гафу итеп, Мәскәү олуг кенәзе ясасаңыз – Тәңрене таныk куеп, муенымдагы крестны үбеп, үлгәнче үзгәрми торган сүземне бирәм. Бабаларымыз сезнең бабаларыңызны ничек үзләренең баш ханы, падишаһсы дип баш игән булсалар, мин дә хан хәзрәтләрен үземнең башым, падишаһым дип таныячакмын вә хан хәзрәтләренең бөтен фәрманнарын, боерыкларын тутырачакмын, бабаларымыз сезнең бабаларыңызга ясак түләгән кебек, мин дә хан хәзрәтләренә вә аның бабаларына ясак түләячәкмен. Үзем Мәскәү олуг кенәзлегендә булган чакта иленңезгә баскын итүдән урыс халкын тыячакмын, үзем үлгәндә балаларыма да шул юлда йөрүне васыять итеп үләчәкмен. Дустыңыз берлә дуст, дошманыңыз берлә дошман булачагыма бу сүзләремне Тәңренең исеме берлә ант итеп ныгытачак вә янымда боярлар үзләренең

кулларын куячактыр. Тәңредән сезгә вә нәселеңезгә озын еллар гомер берлә саулык-сәламәтлектә дәүләт башында булуыңызны сорап, шәфкать, мәрхәмәтеңезгә сыгынган әсиреңез – Мәскәү олуг кенәзе Василий».

Олуг Мөхәммәд. Василийның ялварышын тыңладыңыз. Уйларыңызны сөйләңез!

Тимер. Василий гакылга килгән.

Мәхмүд. Ул мондый сүзләрне беренче мәртәбә сөйләми. Сарайда шул ук сүзләрне сөйләмәгән идеме? Аның сүзләре моннан киткәнче – Мәскәүгә җиткәнче.

Тимер. Була бирсен, бу юлы без дә аны йөгәнсез ат кебек башын буш җибәрмәмез, тышаулармыз.

Галим бәк. Василий урыс илендә башбаштаклык дигәне тугры, чуваш иленә дә кечкенә булса да баскыннар булган, бу эшләрнең алдын алыр өчен тизрәк Мәскәүгә олуг кенәз билгеләргә кирәк, башкасы булмагач, үз кулымыздагы, үземезнең шартларымызны кабул итәргә хәзер Василийны шул урынга куярга кирәк. Ләкин, Тимер командан әйткәнчә, Мәскәүгә аны тышаулап, өстеннән карап торырга гаскәр берлә берәр шаһзадәне күндерергә кирәк.

Олуг Мөхәммәд. Тагы нинди шартлар куйыйк?

Алтын бәк. Урыс илендә безнең сәүдәгәрләремезнең тамгасыз[101] сату-алу хакларын танысын вә Мәскәүнең хәзинәсеннән безгә алтын-көмеш берлә үзенең боярларының баш бәһасен түләсен.

Тимер. Мәскәү олуг кенәзе янына илче-киңәшче итеп антлашуны тутыруны карар өчен җибәрелгән шаһзадәмезгә хан кебек хөрмәт ителеп, аның янындагы гас-кәре үз илендә кебек яшәсен, урыс түрәләре аларга катыша алмасын.

Вәзирләр. Тугры, тугры!

Олуг Мөхәммәд *(Мәхмүдкә).* Синеңчә, угылым?

М ә х м ү д. Мин урыс илен аерым бер ил дип танымаенча, аны чуваш иле кебек дәүләтемезнең бер өлеше итү ягындамын. *(Ягъкубка.)* Син ни фикердәсең?

Я г ъ к у б. Мин әтием ничек тиешле күрсә, шулай булсын дигән уйдамын.

О л у г  М ө х ә м м ә д. Сәед хәзрәтләре, сез?

С ә е д  Җ ә л и л. Бу кара йөрәк бик курыккан, ни дисәк, шуны кабул итәргә хәзер, боярлары берлә бергә мөселман булсын!

Вәзирләр «Юк, юк!» дигән кебек башларын селкәләр.

М ә х м ү д. Без урыслар кулына төшсәк, болар шул чукыну, чукындырудан башлаячаклар. Ник без аны эшли алмыймыз, мин аңламыйм?

О л у г  М ө х ә м м ә д. Без, угылым, дөнья падишаһлыгы корган Чыңгызның балалары, безгә дустның, дошманның диненә катышу ваклык, без аннан өстен, безнең динемез дә көчләп мөселман итүгә каршы, бабаларымыз-ның ясасы да, йоласы да кемнең булса да күңел эшенә, Тәңре берлә бәндә арасында гына була торган эшләргә катышудан тыя. Урысларга карама, алар укусы-язусы юк бер урман халкы, аларда әхлак эшләнмәгән. Үзеңнән түбәннән һичбер вакыт үрнәк алырга ярамый.

С ә е д  Җ ә л и л. Бусы тугры, хан хәзрәтләре, әмма шул урыс иле мөселманлыкка чыкса, безнең илемез генә түгел, Кырымы да, Сарае дә бер тынычлыкка кавышыр иде.

В ә з и р л ә р д ә н  б е р с е. Сүзеңез тугры, әмма күңел дә тели, дәрт бар, дәрман юк.

Т и м е р. Хан хәзрәтләре! Кыйналган эт хуҗасыннан куркучан була, Василий җелегенә үтәрлек кыйналды, инде сезнең бер күз карашыңыздан коты очачак. Сөйләдекемез шартларны кабул итсә, Василийны олуг кенәз ясыйк, урыс эшен бетерик, гаскәрләрне дә өйләренә таратыйк, ил-көн тынычлык сизсен.

О л у г  М ө х ә м м ә д. Тугры!

В ә з и р л ә р  д ә. Тугры, тугры!

Олуг Мөхәммәд *(мирза Галигә).* Василийны бөтен боярлары берлә бергә монда китерсеннәр.

Мирза Гали торып, ишектәге угланга сөйли, ул чыгып китә.

*(Мирза Галигә.)* Син шул сөйләнгән сүзләрне язып кәгазь хәзерлә, Василийдан шуңарга кул куйдырырмыз.

Урамнан халык тавышы килә. Ишектән углан керә.

Углан. Хан хәзрәтләре! Гаскәрләремезнең дошманны җиңеп кайтуы берлә хан хәзрәтләрен котлар өчен шәһәр башы, кәрван башы, халык аксакалы, чуваш, чирмеш олуглары килгәннәр, рөхсәт сорыйлар. *(Олуг Мөхәммәдкә, вәзирләргә карый.)*

Вәзирләр. Кабул итеңез, хан хәзрәтләре, Василийны китергәнче шактый вакыт бар әле.

Олуг Мөхәммәд. Мирза Гали язуыннан аерылмасын. *(Галим бәккә.)* Сез кунакларны каршы алыңыз!

Мирза Гали бер почмакка китеп язуын яза. Галим бәк ишек төбенә китә.

Керсеннәр!

Нәүбәтче углан ишекне ача. Башта голямалар утызлап кеше берсе аркасыннан берсе кереп, иелеп сәлам бирәләр, ишек янында басып торалар.

Хуш килдеңез, түргә узыңыз!

Галим бәк йирләр күрсәтә, ханнар мәҗлесенә якынрак килеп басалар.

Араларыннан шәһәр башы. Хан хәзрәтләре, шаһзадәләр, гаскәр башлыклары! Шәһәрнең бөтен халкы гаскәремезнең урыс дошманны җиңеп кайтуын бәйрәм итә. Казан арты авыл халкы шәһәрнең бөтен урамын тутырганнар. Бөтен ил-көн гомерендә беренче мәртәбә күргән шул зур җиңүнең шатлыгы, сөенече эчендә. Казанның шул олыгаюына, илемезнең шул баюына, тынычлыгына, дәүләтемезнең шул ныгуына сезләр – хан хәзрәтләре вә шаһзадәләр, вәзирләр, гаскәрләремез сәбәп булдыңыз. Шул олуг көннең сагынмалыгы итеп сезгә, хан хәзрәтләре, Казан халкы

бабаларымыз тарафыннан шул мөкатдәс Коръәнне бүләк итте, кабул итеп алуыңызны үтенәбез!

Олуг кулда кын эчендә ефәк букчадагы Коръәнне ханга суза. Хан Коръәнне үбеп, аны башына куеп ала.

Олуг Мөхәммәд. Рәхмәт, бөтен халыкка рәхмәтемне сөйләңез!

Халык сүзчесе *(алга чыгып).* Шаһзадә Мәхмүд, шаһзадә Ягъкуб! Казан халкы халкымызның йөзен көлдергән шул батырлыгыңызның бер ядкяре булсын дип, иске Болгар ханнарымыздан калган шул кылычны шаһзадә Мәхмүд, шул хәнҗәрне шаһзадә Ягъкуб хәзрәтләренә түбәнчелек берлә бирергә миңа кушты. Шул кечкенә бүләгемезне зур итеп алуыңызны үтенәм!

Иелеп, икесенә дә бирә. Шаһзадәләр берәм-берәм алалар, баш иеп рәхмәт укыйлар.

Килгән голямадан берсе *(алга чыгып).* Илемезнең тынычлык, муллык эчендә яшәве гаскәрләремезнең батырлыгы, вәзирләремезнең тугры хезмәт итүләре аркасында килгән Тәңренең зур нигъмәте икәнен һәммәсе беләләр вә барыңызга да рәхмәтләрен укыйлар. Тәңре Тәгалә һәммәңезгә озын вә тыныч гомер бирсен, саг булыңыз!

Олуг Мөхәммәд. Утырышыңыз!

Галим бәк. Менә монда, менә монда! *(Барысын да утырта.)*

Олуг Мөхәммәд. Бу бәйрәм – бездән артык илемезнең, халкымызның бәйрәме. Бу җиңүләремез халкымызның угыллары – гаскәремезнең җиңүе. Без халкыбызның изге теләкләрен тугры юлдан йөртергә генә тырышамыз, бу эштә миннән артык вәзирләрем, түрәләрем, гаскәрләрем эш күрәләр. Шәһәр халкының миңа сагынмалык итеп биргән шул Коръән Шәрифне сөенә-сөенә алдым, шул Коръән Шәриф хөкеме берлә ханлык сөрергә Тәңре ярдәм итсен! Һәммәңезгә рәхмәт!

Мәхмүд. Миңа бүләк иткән шул кылычыңызны дошманның дошманлыгын кисәргә, изәргә кулланачакмын, авыр сугыш көннәренең авыр чакларында бу кылыч халкымның минем берлә бергә булуына танык булып, миңа көч, куәт бирәчәктер. Рәхмәтләр, һәммәңезгә рәхмәтләр!

Ягъкуб. Бу җыңудә минем хезмәтем бик аз, мин атам хан хәзрәтләре кушканны тоттым, агамның бөтен боерык-ларына бер углан кебек муен сындым. Бу хәнҗәрне, минем йөрегән шул юлымның тугрылыгына, халкымның да тугры күрүенә бер дәлил белеп, тугры эшләрдә генә кулланачакмын. Һәммәңезгә рәхмәтләр!

Олуг Мөхәммәд. Кунакларны сыйлаңыз!

Караучылар Галим бәккә киләләр, ул бер сүз сөйли. Бераздан эчке яктан алган кечкенә-кечкенә агач кәндиләрдә һәммәсенә кымыз тараталар. Ханга, шаһзадә, вәзирләргә, аннан соң кунакларга бирәләр. Барысы да акрын гына кымызларын эчәләр.

Олуг Мөхәммәд *(чуваш аксакалына).* Ил-көн исәнме, тормышыңыз тынычмы?

Аксакал. Тәңрегә шөкер, хан хәзрәтләре, бу ел муллык, ил тыныч: кыз бирә, килен ала, туй итә. Халык сезгә догада, хан хәзрәтләре!

Олуг Мөхәммәд. Исән булсыннар! *(Чирмеш картына.)* Сездә ничек, бала-чага, мал-туар исәнме, ил-көн тынычмы?

Чирмеш карты. Барысы да исән-сау, хан хәзрәтләре, моннан атна-ун көн элек урыс явы килеп, бер авылымызның мал-туарын талап киткән иде, безнең егетләр, артларыннан барып, мал-туарны кайтардылар, үзләрен урыс иленә эченә кадәр кудылар. Урыс илендә башбаштаклык бар, дип хәбәр китерделәр.

Олуг Мөхәммәд. Без дә хәбәр алдык.

Шул арада урам ягы ишек төбендә аяк тавышлары ишетелә. Нәүбәтче углан, әмер көтеп, Олуг Мөхәммәдкә карый.

Урысლармы? Керсеннәр!

Тынлык. Барысы да ишеккә карыйлар. Ишек ачыла, аннан алда Мәскәү кенәзе Василий, аның артыннан җиде-сигез урыс бояры коралсыз гаскәр киемнәрендә керәләр. Урыслар сакаллы, өс-баш керле, аркаларыннан сакчы угланнар керә. Василий бераз алда, аның артыннан саф берлә боярлар. Василий, ханга карап, йиргә ятып, сәҗдәгә китә, аның артыннан боярлар сәҗдәгә китәләр.

Василий. Олуг ханым, минем гөнаһымны кичер!

Б о я р л а р. Хан хәзрәтләре, гөнаһларымызны ба-гышла!

О л у г  М ө х ә м м ә д. Олуг Тәңре гөнаһларыңызны кичерсен! Без мөселманнарда, Василий, Тәңредән башкага сәҗдә итү юк. Калык!

Василий акрын гына башын калкыта, боярлар да шулай итәләр.

В а с и л и й *(тагы бер сәҗдәгә китеп).* Безнең кимчелекләремезне кичер, хан хәзрәтләре!

Б о я р л а р. Безне кичер, хан хәзрәтләре!

О л у г  М ө х ә м м ә д. Калкыңыз!

Акрын гына калкалар, түбәндә тез чүгеп утыралар.

О л у г  М ө х ә м м ә д. Василий, мин сине башка урыс кенәзләреннән зур итеп, сиңа дошман бөтен урыс кенәзләрен сиңа буен идереп, сиңа урыс иленең олуг кенәзлеге ярлыгын биргән идем вә сине Мәскәү тәхетенә чыгарган идем. Минем бу сыема каршы син миңа – синең ханыңа вә минем балаларыма, бәкләремә, халкыма нинди каршылык күрсәттең?!

В а с и л и й *(сәҗдәгә китеп).* Олуг хан хәзрәтләре, минем гөнаһларымның исәбе-хисабы юк, синең мәрхәмәтең минем гөнаһларымнан мул дип сиңа сыгынам. Мине кичер!

Б о я р л а р  д а *(сәҗдәгә китеп).* Безне кичер, хан хәзрәтләре!

О л у г  М ө х ә м м ә д. Тәңре кичерсен! Сиңа төрле чакта бөтиләр язып, биргән сүзеңне тотарга чакырдым. Дошманнарымнан качып, синең иленә сыгынган чагымда миңа, балаларыма, бәкләремә, гаскәрләремә каршы нинди сый, нинди хөрмәт күрсәттең? Безне ук берлә, кылыч берлә каршыламадыңмы? Минем гөнаһсыз юлдашларымны, якыннарымны, бәкләремне, гаскәрләремне үтертмәдеңме? Безнең ул чактагы авыр хәлемездә, безнең зәгыйфьлегемезне күреп, безне бетерергә, безнең байрагымызны индерергә касд итмәдеңме?[102] Син Тәңренең көчле ягында түгел, халкы ягында икәнен онытттың. Тәңрене танык итеп үз ихтыярың берлә биргән антыңны боздың. Инде Тәңренең хөкеме сине вә боярларыңны бу хәлдә безгә тапшырды. Сине үтерү, боярларыңны юк итү безгә чебен

үтерүдән җиңел! Син – безнең йиремездә, без дә синең йиреңдә булса идек, без ни эшләр идек?

Василий. Хан хәзрәтләре! Шаһзадәләр мине әсир иткән көндә дә, бүген дә мине үтерергә тулы хаклы идеңез, миңа мәрхәмәт иттеңез, минем җанымны сакладыңыз. Шул озын көннәр, уйкусыз төннәрдә мин сезгә каршы, Тәңрегә каршы кылган гөнаһларымны күз яшьләре берлә уйлый-уйлый үзем үлдем. Бүген сезнең алдыңызда сезгә каршы килгән вә падишаһлык сүзен тотмаган Василий түгел, ул үзенең гөнаһларының авырлыгы астында буылып үлде, ул юк. Мәрхәмәтеңез булса, сез икенче Василийны яңадан тудырачаксыңыз, аның керле җаны йиренә пакь җан бирәчәксеңез, аңа яңы боерыкларыңызны боерачаксыңыз вә күрәчәксеңез ки, хан хәзрәтләре, бу яңы туган Василий – иске Василийның гөнаһларын юарга бөтен гомерен сарыф итәчәктер!

Боярлар *(сәҗдәгә китеп).* Олуг хан, безне кичер!

Олуг Мөхәммәд. Сине кичереп, ярлыгымызны биреп, икенче кат Мәскәү тәхетенә чыгарсак, вакыты килгәндә тагы гаскәр җыеп, безнең илемезгә тагы сугыш ачачак, тагы кан түгәчәкмесең?

Василий *(муеныннан крестын чыгарып, шуны үбеп).* Крестымны үбеп ант итәм, хан хәзрәтләре, сезнең бөтен фәрманнарыңызны тотачакмын вә сезгә каршы килмәячәкмен!

Боярлар. Без дә ант итәмез, хан хәзрәтләре, ни боерсаңыз – кабул!

Олуг Мөхәммәд. Син, Василий, сез, боярлар, бабаларымыз заманасындагы кебек урыс иленең олуг ханы итеп Казан ханлыгын кабул итәсезме?

Боярлар *(алдан).* Кабул!

Василий да *(уйланып).* Кабул.

Олуг Мөхәммәд. Бабаларымыз заманасындагы кебек безгә ясак түләүне кабул итәсезме?

Боярлар. Кабул, кабул!

Василий да. Кабул.

Олуг Мөхәммәд. Илемезгә каршы баскын итмәскә, дустымыз берлә дус, дошманыбыз берлә дошман булуны кабул итәсезме?

Боярлар. Кабул, кабул!

Василий. Кабул.

Олуг Мөхәммәд *(вәзирләргә, шаһзадәләргә).* Сез ни дисез бу эшкә?

Тимер. Хан хәзрәтләре, Василий үзенең биргән падишаһлык сүзе берлә балалар уйный торган ашык кебек уйнады, тагы шундый уеннар уйный башласа, хан хәзрәтләренең ярлыгын алыр-алмас Мәскәү тәхетеннән үзе җиңелүгә ант итсен вә боярлар да шул сүзгә танык булсын!

Василий. Кабул!

Боярлар. Кабул!

Олуг Мөхәммәд *(мирза Галигә).* Килешү кәгазен хәзерләдеңме?

Мирза Гали. Хәзер, хан хәзрәтләре!

Олуг Мөхәммәд. Укы! *(Василийга, боярларга.)* Яхшы тыңлаңыз!

Мирза Гали. «Ханнарның ханы вә хан баласы вә хан тәхетендә ханлык итүче Олуг Мөхәммәд хан хәзрәтләренең Сарай шәһәрендә миңа биргән ярлыгы берлә урыс иленең олуг кенәзлегенә мендерелгән вә Мәскәү тәхетенә утыртылган Василий, Тәңремне таных итеп биргән сүзләремне тотмавым, олуг ханга вә аның йортына, гаскәрләренә каршы баш калдырган өчен, Тәңренең хөкеме берлә хан хәзрәтләренә әсир төштем. Мәскәү олуг кенәзлегемне югалттым. Олуг ханның мәрхәмәте берлә яңадан урыс иленең таҗы, тәхете миңа кайтарылса, Мәскәүнең хәзинәсен хан хәзрәтенең ихтыярына бирергә, һәр нә боерса, олуг ханның боерыгын тутырырга, Казан иленә баскын итмәскә, яу җибәрмәскә, бабаларымыз вакытындагы кебек Сарайга түләгән ясагымызны Казан ханлыгына түләргә, хан хәзрәтенең илчесенә ханнарга күрсәткән сый-хөрмәтне күрсәтергә, хан хәзрәтләре тарафыннан урыс иленә куелган бөтен татар түрәләренең эшләренә каршы килмәскә, Казан иленең дусты берлә дус, дошманы берлә дошман булырга, Казан иле сатучысы-алучысының урыс иленең һәр почмагында тамгасыз сату-алу итүенә киртә куймаска, ике ил арасындагы күршелекне дустлык

нигезендә алып барырга Тәңре исеме берлә ант итәм вә кулымны куям». *(Мирза Гали туктый).*

Мөхәммәд. Кабулмы?

Василий. Кабул, хан хәзрәтләре!

Боярлар. Кабул, кабул!

Василий. Бер сүзем генә бар, хан хәзрәтләре! Мәскәү хәзинәсе хан хәзрәтләренең ихтыярына бирелер, диелгән. Мәскәү хәзинәсе сугышта да беткән хәлдә иде, аннан соң Мәскәү янды, анда башбаштаклык башланды, хәзинәдә хәзер ни калды – билгесе юк. Анда берни булмаса, йә бик аз булса, тагы Василий сүзен тотмады дияргә юл ачар. Шуңарга күрә, шул сүзне чикләп язылса, хәзинәдә алтын-көмеш булмаса да, халыктан туплап бирер идек. Мин, хан хәзрәтләре, сезнең мәрхәмәтеңездән шуны сорыйм!

Олуг Мөхәммәд вәзирләргә карый.

Галим бәк. Василийның сүзе тугры, без бу акчага бер үлчәү куйыйк.

Тимер. Ярты миллион алтын.

Василий. Боерык сезнең, хан хәзрәтләре, ул чикле алтынны урыс иленнән ун елда да җыеп ала алмамыз. Безнең халык сезнеке кебек сатучы-алучы түгел, беләсез, игенче, аучы.

Алтын бәк. Ике йөз алтын, диик, хан хәзрәтләре!

Вәзирләр. Тугры, тугры!

Олуг Мөхәммәд *(Василийга).* Ике йөз алтын, кабулмы?

Боярлар. Кабул, кабул!

Василий. Бу да безнең илгә бик зур акча, табарга тырышырмыз, кабул.

Олуг Мөхәммәд. Бу килешүдәге бөтен сүзләрне аңлап, тыңлап, кабул итәсезме?

Василий. Кабул!

Боярлар. Кабул!

Олуг Мөхәммәд. Кул куеңыз!

Василий акрын гына мирза Гали өстәле янына килә. Ханның итәген үбә. Калтыранган кулы берлә кәгазьгә авыр-авыр кул куя, аның аркасыннан

боярлар берсе аркылы берсе бармакларын басалар. Мирза Гали һәрбер бармак иясенең исемен яза, алардан соң вәзирләр, гаскәрләр кулларын куялар. Мирза Гали хан хәзрәтләренең мөһерен китерә. Хан кулын куя вә мөһерен баса.

Олуг Мөхәммәд *(аякка калка).* Бу сәгатьтән башлап Мәскәү кенәзлеге берлә Казан ханлыгы арасында сугыш бетте, килешү булды. Василий Казан ханлыгының бөтен теләкләрен эшкә ашырырга сүз биреп, яңадан Мәскәү олуг кенәзе ярлыгын алды вә янындагы боярлары берлә бергә азат ителде.

Василий килеп ханның кулын үбә, урыс боярлары ханның итәген үбәләр. Мәскәү олуг кенәзе вә аның боярлары бүгеннән безнең кунагымыздыр. Аларга йир биреңез!

Мирза Гали аларга йир күрсәтә, урыслар җирләренә утыралар вә чукыналар.

Олуг Мөхәммәд *(караучыларга).* Кунакларга сый китереңез! *(Вәзирләргә.)* Дәллял[103] чыгарыңыз – халыкка белдереңез, сугыш бетүен белдереңез, халык өч көн, өч кич бәйрәм итсен!

Караучылар һәркемгә кымыз тараталар.

Тимер *(аякка калкып).* Хан хәзрәтләре, рөхсәт биреңез, мин халыкка аңлатыйм!

Хан. Аңлат!

Тимер балконга чыга. Бу арада караучылар һәркемгә кымыз тараталар.

Тимер *(зур тавыш берлә).* Җәмәгать, җәмәгать! Мәскәү Казанга вә хан хәзрәтләренә муен сынды. Василий Казан ханлыгына ясак түләргә вә хан хәзрәтләрен үзенең башы итеп таныргa ант итте вә яңадан Мәскәү олуг кенәзе ясалды. Хан хәзрәтенең фәрманы – бөтен ил өч көн, өч кич бәйрәм итсен!

Халык *(кычкыра).* Саг улыңыз, яшәңез, яшәңез! Җиңдек, урысны җиңдек!

Урамда гаскәри музыка уйнарга тотына.

Василий *(кымызлы кәндине күтәреп).* Хан хәзрәтләре, Сезнең саулыгыңызга!

Олуг Мөхәммәд. Ил-көннең саулыгына. *(Кымыз эчә.)*

Агач аяклы дәрвиш *(керә, калтыранган тавыш берлә).* Сугыш бетте, мин тагы шәһидлектән мәхрүм булдым. Инде нишлим?

Олуг Мөхәммәд. Сине игълане хикмәтулла[104] өчен чуваш-чирмеш илләренә дин башы иттек. Син үлмәячәксең, үлтермәячәксең, яңыдан-яңы мөселманнар тудырачаксың!

Ягъкуб. Син олуг кенәзне Мәскәүгә алып барып тәхеткә чыгарачаксың! Хәзер килешү котлы булсын!

Урамда музыка дәвам итә.

Пәрдә төшә.

**Аңлатмалар һәм искәртмәләр:**

**Олуг Мөхәммәд**. Драма басылып чыкмаган. Гарәп язулы кулъязмада барлыгы 83 бит. Аерым кәгазьдә түбәндәге сүзләр язылган: «Языла башланды 1 гыйнвар, 1944 сәнәсендә Истанбулда. 22 март 1944 сәнәсендә беренче тасхихы бетте, Сирасервиләр, 95. Икенче тасхихы башланды 9 декабрь 1946 да, Әрен көйдә, Истанбул. Тәмам булды 1947, 2 нче декабрь, Иске Чәчәкле сокагы 40, даирә 4 тә. Асыл нөсхә бу булачак».

Шунысы игътибарга лаек: драманың беренче вариантын язып тәмамлаганнан соң, икенче тапкыр редакцияләргә тотынганга кадәр бер ел да сигез ай вакыт узган. «Нигә алай?» дип сорау куйсак, әдипнең үзен-нән үк җавабын табарбыз. Г. Исхакыйның 1951 елда үз кулы белән төзегән исемлектә (библиографиясендә) без мондый юлларны укыйбыз: «Русчадан Истанбул төрекчәсенә тәрҗемә ителгән «Казан ханлыгы тарихы» (Худяковтан), 1945, Истанбул». Димәк, әдип драманы бер кат язып чык-каннан соң, рус тарихчыларыннан беренчеләрдән булып Казан ханлыгы тарихын объектив яктыртырга тырышкан М. Г. Худяковның 1923 елда Казанда басылып чыккан «Очерки по истории Казанского ханства» дигән китабын җентек-ләбрәк өйрәнергә тотынган һәм төрекләргә тәкъдим итәр өчен аны тәрҗемә дә иткән*.Һәм шуннан соң гына «Олуг Мөхәммәд» драмасын яңадан эшкәртергә керешкән.

Тышына «Олуг Мөхәммәд» пьесама даир яздык – тарихи мәгълүматлар» дип язылган аерым конвертта драманың 8 биттән торган планны хәтерләткән язмасы саклана. Язучының әсәре өстен-дә ничек эшләвен күзаллау өчен бу язманы беркадәр кыскартулар белән укучыга тәкъдим итәбез:

*Беренче пәрдә. [Беренче сәхнә].* Белёвта. Олуг Мөхәммәд ханның гаскәр мәйданы. Боз диварлары берлә әйләндергән чатыр-лар. Берсенең өстендә Алтын Урда байрагы

асылган. Гаскәрләр киткән, атлар иярләнгән хәлдә. Хан чатырында диван корылган. Рус гаскәрләренә башлыктан рус байрагы күндерелергә әмер бирелә. Илчеләрне көтелә. Сөйләш, ялварыш. Рус илчесе бирелүне таләп итә. Куркыта.

*Икенче сәхнә.* Шул ук чатыр эчендә. Хан башлыклар берлә киңәшләшә. Гаилә, балалары. Хан... карар бирә алмый. Рус гаскәре бик күп, татар гаскәре аз һәм арыган... Хан, мәҗлесне кисеп, чатыр тышына чыга. Анда халык тупланган, карарын көтә... Хан: «Дәүләт диваны бер сүзгә килә алмады. Хәлемез авыр, юлымыз караңгы...

Бөек Тәңре тугры юл күрсәтсен дип, ил юлында шәһид булган батырларымыз юлбашчы булсын дип, ике рәкәгать намаз укыймыз. Теләгәннәреңез килеңез. Ireклегә ирек», — [ди].

*Өченче сәхнә.* Кар өстендә намазга тезләнәләр. Хан — имам. Ерак-тан урысның уйнау, көлү, җыры, музыкасы ишетелә. Хан но-тык сөйли: «Мин үләргә карар бирдем. Намуссыз яшәүдән намуслы үлү артык. Кем намуссыз яшәүдән намуслы батыр үлемен артык күрә — минем берлә!» Капкалар ачылып, һөҗүм ителә. Сугыш дәвам итә.

*Дүртенче сәхнә.* Хан чатыры. Ханбикәләр. Хатыннар сугышны карыйлар. Нәтиҗәне көтәләр. Берсе артыннан берсе төрле хәбәр килә. Курку белән өмет эчендә. Татарлар, җиңеп, урыс гаскәр-ләренең башлыкларын әсир итеп киләләр. Араларында яшь илче дә бар. Хан — канлы, җәрәхәтле. Батырлар да җәрәхәтлеләр. Диван корыла. Әсирләрдән сорашалар. Урыс байрагыны хатыннар өзгәләп ташлыйлар. Хан әсирләрне үтермәскә хөкем итә. «Урыс иленең эчендәмез, үз илемезгә китәргә», — дип карар бирә. Казанга китәләр.

*Икенче пәрдә. [Беренче сәхнә].* Ослан тавы өстендә. Иделнең теге ягында Иске Казан күренеп тора. Иртә берлә кояш чыккан чак. Хан чатыры: хан гаиләсе, батырлар. Ханны кабул итү-итмәү хакында илчеләр[не] көтәләр. Батырларның кайберсе: «Кабул ит-мәсәләр — сугышып керәмез!» — диделәр. Хан: «Ул бит урыс каласы түгел. Үзара сугыша-сугыша бит Чыңгыз дәүләтеннән менә шул калды. Чыңгызның балалары урыс этләренә сыгынырга кадәр төште. ...Юк, күтәрелеп китәмез... сахрага китәмез, казак була-мыз... Мин илдәш сугышында башлык була алмыйм», — ди. Шул арада Идел өстендә бик күп халыклы каеклар, саллар күренә. Зур Казан каласының ачкычыны бер [бәк] тәкъдим итә. Шәһәр исе-меннән бәйгать бирәләр. Болгар асылзадәләреннән берсе Болгар иле исеменнән бәйгать бирә. «Бу ил — безнең бабайларның иле, мин дә Үлмәс ханның балаларыннан... Ләкин дошман илемезне яулар [бе-лән интектерә]. Илемез байрагыны кайсымыз батыр, шул тотарга кирәк. Синең дошман берлә сугышта батырлыкларыңны [беләбез].

*Икенче сәхнә.* Казан шәһәрендә кечек бер сарайда. Сәедләр киләләр, алар да бәйгать бирәләр. Халык музыка берлә килә. Бар да бәйгать бирәләр. «Илне коткар, синең әмереңдә!» — дип, чуваш-лардан вәкилләр килә. Ханга ант эчәләр. Хан нотык сөйли... Зур бәйрәм башлана... Шулвакыт Тау ягы чирмешләреннән бәкләр ки-леп, рус гаскәренең илләрне талап, ханны куа килүләрен белде-рә-ләр... Урысларга каршы Болгар асылзадәсе берлә вәли гаһед Мәхмүд күндерелә. Бәйрәм дәвам итә.

*Өченче пәрдә.* Казанда дәүләт корылышы. Төрле исляхат. Һәр йиргә муаффәкыятьне аңлатып, берлеккә дәгъвәт берлә мәктүбләр. Һәр йирдән бәйгатьләр килә. Дәүләт корыла. Сәфирләр.· Араларында Ләһстан сәфире дә бар. Русларны — мәгълүб итеп· [китерәләр]. Ара-ла-рында Мәскәү олуг кенәзе дә бар. Олуг Мөхәммәд хыянәтнең һәр-ва-кыт начар нәтиҗә чыгаруын сөйли. Мәскәү кенәзе тезләнә, гафу тели.

*Дүртенче пәрдә.* Ханның Ягъкуб берлә Йосыф исемле угыллары Казанның олуг бәкләреннән кызлар алалар. Сарайның залында бирнә багу мәҗлесе, хатыннар өчен.

***

Бу кәгазьләрдә шулай ук *«ук букчасының исеме?»*, *«Һади Атласи* [дан]: *«торак тоту»*, *«хач» — тәре* мәгънәсендә, *«илекмән» — манара* мәгънәсендә, *«маш» — башта, башня* кебек кыска гына язулар да теркәлгән.

Күренгәнчә, Г. Исхакый әсәрнең планын шактый киң күз ал-ды-на китергән. «Атлар иярләнгән хәлдә», «Идел өстендә бик күп ха-лыклы каеклар, саллар күренә», «Кар өстендә намазга тезлә-нә-ләр» яки «Бөтен гаскәрләр атларыннан төшә» (соңгысы текстка да кер-гән) кебек гыйбарәләр кинофильм өчен язылган сценарийны хәтер-ләтә. Һәм, чыннан да, «Олуг Мөхәммәд» драмасы киң панора-ма-да — кинофильмда күрсәтелергә лаек әсәр.

Г. Исхакыйның «Асыл нөсхә бу булачак» дигән сүзләрен искә төшерик. Чыннан да, кулъязмада язып-сызылган урыннар бик аз. Әмма язучы сәхнә әсәрен дә, проза әсәре кебек итеп, юлны шыплап тутырып язарга ярата. Бу, бәлки, күп яза торган әдипнең кәгазьне әрәм-шәрәм итмәү максатыннан да эшләнгәндер. Персонажларның юл башында гына язылмыйча, язып барганда юлның кай төшенә туры килә, шунда беркетеп китүләр бер күз ташлаганда гына, текстның драма әсәре икәнлеген аңлау-ны кыенлаштыра. Шуңадыр, күрәсең, Төркиядә кулъязманы тотып кына караган кайбер чит ил галимнәре бу әсәрне «роман» дип яздылар. 1988 елда «Азатлык» радиостанциясеннән дә «Г. Исхакыйның тарихи темага язылган «Олуг Мөхәммәд» дигән романы бар» дип игълан иткәннәр иде. Рево-люциягә кадәр язылган һәм басылып чыккан драма әсәрлә-рен-дәге кебек үк, «Олуг Мөхәммәд»тә дә бер үк персонажның рәттән бер-ничә тапкыр кабатлануы һәм, киресенчә, персонаж үзе күрсәтел-мичә, әйткән сүзләре генә язылу — пьесаның эчтәлеген төшенүне шактый читенләштерә. Персонажларның күрсәтелгәннәрен дә, текстта күрсәтелмәгәннәрен дә ачыкларга, аларның һәркайсына үз сүзләрен «бүлеп чыгарга», автор сүзләрен аерырга кирәк булды.

Г. Исхакыйның язуын тану да җиңел түгел. Бик кызу язуы сәбәпледер, кайчагында хәрефләр кәгазьгә төшеп үк бетми, ишарәләре генә калып бара, аерым язылаcы хәрефләр дә кушылып китә. Шуңа күрә кулъязманы укыр-га маңгай күзең генә җитми, бик озак

өйрәнеп-чамалап, эчке бер сиземләү күзеңне дә эшкә җигеп, һәр җөмләне ребус өстендә эшләгән кебек өйрәнергә-укырга туры килә. Әдип үзенең язуын «кытай язуы» дип атый, бер авто-би-о-г-рафик әсәрендә «Ничек таныйлар бу язуны?» дип сораган туташка ул: «Аптырыйлар, йөдиләр дә таныйлар инде», — дип җавап бирә. Әмирхан ага Еники, әдипнең язуын Казанда бер генә хәреф җыючы (наборщик) таныган икән дип ишеткәнем бар иде, ди. Гарәп язулы текстта тыныш билгеләрен кую тәртибе күзәтелми. Бу да кулъязманы укуны авырлаштыра төшә.

Әсәр мөмкин кадәр хәзерге заман кагыйдәләренә — драма-лар-ны техник яктан кору тәртипләренә туры китереп әзерләнде. Төрле урыннарда «төшеп калган» персонажлар «торгызылды». Әмма ки-тап битен чуарлатмас өчен, текстта, кагыйдәдән чыгарма буларак, алар янында квадрат җәяләр куелмады.

[1]*Голяма* – галимнәр, укымышлылар.
[2]Әтраф – тирә-як.
* Оригиналда «Алтын Урду» дип язылган.
[3] Озактарак – ерактарак.
[4] Инү – бу урында: төшү.
[5]Гаскәр – солдат.
[6] Нәүбәттә – чиратлашып, тезелешеп.
[7] Сәлам тору – «смирно» тору.
[8]Капучы – капкачы.
[9] Башларын алалар – бу урында: баш киемен салалар.
[10]*Ялан кылыч нәүбәт саклыйлар* – ялан кылыч тотып сакта торалар.
[11]*Җөда булган* – аерылган.
[12]*Мәзһәб* – бу урында: дини агым, секта.
[13]*Бирге* – ясак, салым.
[14]*Гадәләтсезлек* – гаделсезлек.

[15]*Ялгыз* – бары тик.

[16]*Сукты* – бирде.

[17]*Хитаб* – мөрәҗәгать.
[18]*Дошманга салдыру* – дошманга һөҗүм итү.

[19]*Забит* – хәрби чин, хәрби башлыклардан берсе; офицер.

[20]*Харита* – карта.

[21]*Ташыган* – йөрткән.

[22]*Хазыйрләр* – шунда булучылар.

[23]*Сөлялә* – ыруг, нәсел-нәсәп.

[24]*Сөзә* – җентекләп карый, күзәтә.

[25]*Төмән* – ун мең.

[26]*Гайне* – шул ук.

[27]*Баглау* – бу урында: бәйләү.

[28]*Ганимәт малы* – кулга төшерелгән дошман малы.

[29]*Турун* – онык.
[30]*Төнәге* – кичәге.

[31]*Аеры-аеры уймаклар* – бу урында: «таралып яшәгән төркем-нәр» мәгънәсендә.

[32]*Сайдыру* – бу урында: күтәрү; исәпләшергә мәҗбүр итү.

[33]*Табуг салу* – берәүнең хакимиятен тану.

[34]*Бәшәр* – кеше, кешеләр.

[35]*Комач (комаш)* – кызыл мал, тукыма.

[36]*Бәйгать бирү* – сүз бирү.

[37]*Такым* – төркем.

[38]*Кандил* – лампа, фонарь.

[39]*Төшенү* – уйлау.

[40]*Яр булу* – ярдәмче булу
[41]*Чыгтай йорты* – үзбәк иле.

[42]*Ригая итү* – олылау, хөрмәтләү.

[43]*Дань* – ясак.

[44]*Ләһ* – поляк.

[45]*Йирсез* – урынсыз.

[46]*Мөнасиб* – яраклы.

[47]*Рәхмәтлеләр* – хөрмәтлеләр.

[48]*Ләһстан* – Польша.

[49]*Хозурә кабулларын үтенәләр* – алдыгызга килеп, кабул итүегезне үтенәләр
[50]*Дәрдләр* – бу урында: борчыган мәсьәләләр.

[51]*Тәшрифатчы* – килүче.

[52]*Илла* – бу урында: зинһар.

[53]*Мәҗнүн* – дивана.

[54]*Мәхзүн* – уйлы, моңлы кеше.

[55]*Әмирелмөэминин* – мөселман иле патшасы, ханы.

[56]*Шафигыльмөслимин* – мөселманнарда арадашлык итүче.

[57]*Ләкаб* – кушамат.

[58]*Төнә* – кичә.

[59]*Мәхһүл* – билгесез.

[60]*Мөштак улып* – омтылып, ашкынып.

[61]*Тәшриф* – бу урында: хөрмәт, олылау.

[62]*Изен* – рөхсәт.

[63]*Диван* – җыентык.

[64]*Мөҗаһид* – дин өчен көрәшүче.

[65]*Гарип табигатьле* – бу урында: үзенчәлекле табигатьле.

[66]*Мөнасиб* – яраклы.

[67]*Муафикъ* – урынлы.

[68]*Кузый* – бәрән.

[69]*Как-төш* – чәкчәк.

[70]*Авызыннан* – авыз эченнән.

[71]*Җилд* – бу урында: китапның катыргы тышы.

[72]*Сөкүт* – бераз тынлык.

[73]*Хәтфә* – бәрхет.

[74]*Алмас* – алмаз.

[75]*Парча* – бу урында: төргәк.

[76]*Сайгы* – ихтирам.

[77]*Муен сындыру* – буйсындыру.

[78]*Тану* – бу урында: кабул итү, бәяләү.

[79]*Нәҗес* – әшәке.

[80]*Ялгыз* – бу урында: тик.

[81]*Тамга* – таможня салымы.

[82]*Әмре мәгъруф вә нәһи мөнкәр* – «яхшылыкны хуплау, начарлыкны тыю» мәгънәсендә.

[83]*Каранлык* – караңгылык.

[84]*Яса* – сәясәт, тоткан юл, закон кагыйдәләре.

[85]*Тәдбир* – тиешле чара.

[86]*Озаклаштыру* – ераклаштыру.

[87]*Бөти* – бу урында: хат.

[88]*Күздән озак тотмасыннар* – күздән еракта тотмасыннар.

[89]*Ямчы* – ям чабучы: хәбәр таратучы.

[90]*Алай* – гаскәр.

[91]*Гази* – дин өчен сугышта җиңүче, батыр.

[92]*Чалына* – бу урында: ишетелә.

[93]*Саг улсын* – сау булсын.

[94]*Хадим* – хезмәтче, хезмәткәр.

[95]*Саймыйлар* – санамыйлар.

[96]*Көтүсе* – көтүе.

[97]*Кич түгел* – бу урында: соң түгел.

[98]*Маҗар* (мадьяр) – венгр.

[99]*Аңлашылмаслык* – аңлашмаучылык.

[100]*Үземезнең ясамыз* – үз тәртипләребез.

[101]*Тамга* – бу урында: таможня.

[102]*Касд итү* – теләү, ниятләү.

[103]*Дәллял* – арадашлык итүче.

[104]*Игълане хикмәтулла* – белем тарату.

Чыганак: Исхакый Г. “Ике йөз елдан соң инкыйраз”.
Татарстан китап нәшрияте. 2019.

Текстларны,  искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүче

**Гайнанова** Лена Рәшит кызы